*Үзем үлсәм дә,*
*газиз исемем үлмәсен, югалмасын;*
*Минем тырышлыгым һәм эшләрем*
*бушка китмәсен*

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

# РУХИ МИРАС
## эзләнүләр һәм табышлар

1 нче чыгарылыш

Казан
2016

Институт языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

# ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ

## поиски и открытия

Выпуск 1

Казань
2016

УДК 801.82(082)
ББК 63.2:80я43
Д 85

*Печатается решением Ученого совета*
*Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова*
*Академии наук Республики Татарстан*

Проект реализуется Центром письменного и музыкального наследия
Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук РТ – Мирасханэ

**Руководитель проекта и ответственный редактор – *И.Г. Гумеров***

**Редакторы-составители:**
***Ф.Г. Файзуллина, Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова, Л.Ш. Давлетшина***

**Д 85** **Духовное наследие: поиски и открытия** / под ред. И.Г. Гумерова. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – Вып. 1. – 276 с.
ISBN 978-5-93091-195-5

Серия сборников «Духовное наследие: поиски и открытия» продолжает традицию публикации малоизвестных письменных источников; изучения произведений, составляющих основу духовного наследия татарского народа; знакомства читателей с новейшими исследованиями в изучении татарских текстов. Издание охватывает вопросы археографии, палеографии, кодикологии, текстологии, эпиграфики и др.

Первый выпуск посвящен жизни и творчеству Г. Тукая в честь 130-летия со дня рождения поэта. В сборнике сделана попытка осветить, интерпретировать материалы, помогающие понять личность Тукая, расширить научный взгляд на его творчество.

ISBN 978-5-93091-195-5

© Институт языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2016

# КЕРЕШ

# ПРЕДИСЛОВИЕ

Халыкның тормыш-яшәештәге ролен билгеләүдә аның тарихи мирасы, рухи байлыгы мөһим роль уйный. Бөек каләм әһелләре, сәнгатькәрләребез иҗат итеп калдырган әсәрләр – халкыбызның бәһа биреп бетергесез рухи көзгесе. Бүгенге буынның төп бурычы – әлеге бай хәзинәнең кыйммәтен аңлап, төкми-чәчми саклап, киләчәк буыннарга җиткерү.

Гасырлар дәвамында тупланып килгән рухи хәзинәбезне барлау, өйрәнү һәм фәнни әйләнешкә кертү юлында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан күп еллар дәвамында игелекле эшләр башкарылып килә. Институт галимнәре тырышлыгы белән Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Г. Камал, Х. Туфан, М. Җәлил кебек мәшһүр классикларыбызның күптомлыклары, аерым дәвергә караган әдәби үрнәкләрне үз эченә алган китап-җыентыклар басылып чыкты. Татар халык авыз иҗатының күптомлы басмасы, Кол Галинең

Миропонимание народа, его место и роль в мировом культурном пространстве определяют историческое наследие, духовное богатство этноса. Произведения писателей, поэтов, художников, композиторов и др. являются зеркалом, где отражается духовное богатство народа. Основная задача ныне живущих – осознавая всю ценность этого наследия, приумножить его и сохранить для последующих поколений.

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан вот уже в течение нескольких десятков лет ведет планомерную работу по поиску, изучению и введению в научный оборот произведений, составляющих основу духовного наследия татарского народа. Благодаря деятельности ученых института были составлены и опубликованы многотомные издания произведений Г. Тукая, Ф. Амирхана, Г. Ибрагимова, М. Гафури, Г. Камала, Х. Туфана, М. Джалиля и других классиков татарской литературы; сборники

мәшһүр «Кыйссаи Йосыф»ы, Мөхәммәдьярның «Нуры содур»ы, XVIII йөз татар прозасы ядкәре «Мәҗмугыл-хикәят» һ.б. дөнья күрде. Галимнәребез, милли җанлы фидакарьләр, тырышлыгы белән, Г. Исхакыйның мирасы Ватанына кайтарылды, әсәрләренең 15 томлыгы әзерләнеп, халкыбызга барып иреште.

Укучыларны яңа табылган язма чыганаклар яки аз билгеле булган исемнәр белән таныштыру җәһәтеннән дә институтыбызда максатчан эш алып барылды: «Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш», «Язучы биографиясенә яңа чыганаклар», «Әдәби мирасның яңа катламнары», «Әдәби мирас: эзләнүләр, табышлар», «Әдәбият чыганаклары» исемле басмалар нәшер ителде. Аларның дәвамы буларак, берничә ел дәвамында «Әдәби мирас һәм текстология» җыентыклары дөнья күрде. «Яшь галимнәр һәм аспирантлар эшләре җыентыгы»ның һәр чыгарылышында да әдәби мирас, археография һәм текстология мәсьәләләре яктыртылып барылды. Татарстан китап нәшрияты әзерләгән «Әдәби мирас» сериясендә дә институт галимнәре актив катнашты.

Милли мирасыбызны барлау һәм фәнни өйрәнү эше бүген дә эзлекле рәвештә дәвам итә. Галимнәребез халкыбызның тарихи хәтерен саклау, өзелгән чылбырларны ялгау, мәдәниятебез та-

произведений, относящихся к отдельным историческим эпохам; многотомное издание произведений татарского устного народного творчества, «Кисса-и Йусуф» Кул Гали, «Нуры Содур» («Свет сердец») Мухаммадьяра, памятник татарской литературы XVIII века «Мажмугыл хикаят» и другие. Благодаря усилиям наших ученых состоялось возвращение на родину имени и творчества Г. Исхаки: был подготовлен и издан 15-томник его сочинений.

Институт вел плодотворную работу в направлении знакомства читателей с малоизвестными или новыми письменными источниками. К примеру, были подготовлен и изданы такие сборники, как: «Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш», «Язучы биографиясенә яңа чыганаклар», «Әдәби мирасның яңа катламнары», «Әдәби мирас: эзләнүләр, табышлар», «Әдәбият чыганаклары». В течение нескольких лет издавался сборник «Әдәби мирас һәм текстология». В сборнике «Яшь галимнәр һәм аспирантлар эшләре җыентыгы» в каждом выпуске размещались материалы, относящиеся к литературному наследию, археографии и текстологии. В серии «Әдәби мирас», готовившейся Татарским книжным издательством, ученые института также принимали самое активное участие.

рихындагы ак тапларны бетерү юнәлешендә зур тырышлык куялар. Классик язучыларыбызның академик басмалары, татар әдәбияты тарихы томнары, халык авыз иҗатының яңа басмалары дөнья күрү – болар барысы да шул изге юлдагы гамәлләрнең күркәм нәтиҗәсе.

Милли хәзинәләрне барлау юлында институт хезмәткәрләре ел саен Татарстанның төрле районавылларына, шулай ук татарлар күпләп яшәгән чит төбәкләргә археографик экспедицияләргә чыгалар. Анда табылган яңа материаллар турында 2010 елдан алып, аерым төбәкләргә багышланган «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе үз эшен алып бара. Абруйлы белгеч, филология фәннәре докторы, профессор Марсель Әхмәтҗанов 2013 елдан алып бүгенге көнгә кадәр кульъязма мирас һәм эпиграфик ядкәрләрне тикшерү, археографик экспедицияләргә йомгак-нәтиҗә рәвешендә «Татар археографиясе» исемле аерым бер цикл нәшер итеп килә.

Институтыбызның Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондлары ел саен яңа табылган кулъязмалар, сирәк очрый торган иске китаплар, тарихи документлар, әдипләребезнең шәхси архив материаллары белән тулыланып бара. Мәсәлән, соңгы елларда гына язучы, тәрҗемәче Ә. Хәсәни (1883–1934), тарихчы, этнограф

Изучение национального духовного наследия продолжается и сегодня. Ученые-патриоты стараются сохранить историческую память народа, связать разорвавшиеся было цепи между поколениями, стереть белые пятна на культурной и исторической памяти народа. Академические издания писателей и поэтов классиков, тома истории татарской литературы, новое издание свода произведений татарского устного народного творчества – все это результат кропотливого труда наших ученых.

В поисках свидетельств прошлого татарской литературы, истории книжного дела татар сотрудники института ежегодно выезжают на археографические экспедиции в районы Татарстана, места компактного проживания татар в других регионах Российской Федерации. Материалы экспедиций отражаются в сборниках, начиная с 2010 г. публикуемых институтом в серии «Из сокровищницы научных экспедиций». Доктор филологических наук, именитый ученый Марсель Ахметзянов, начиная с 2013 г., издает цикл сборников «Татарская археография» как результат изучения письменных и эпитафических источников, собственных археографических экспедиций.

Центр письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства

Ф. Вәлиев (1918–2010), язучы һәм тәрҗемәче Ә. Исхак (1905–1991) фондлары, галим-археограф Сәид Вахидинең (1887–1938) шәхси коллекциясеннән сирәк фотолар, аерым кешеләрдән төрле эчтәлектәге кульязма һәм басма китаплар кабул ителде.

Электән яшәп килгән күркәм традицияне яңартып, татар рухи мирасын өйрәнү юлында алып барылган фәнни эзләнүләрне чагылдырган, аның мөһим мәсьәләләрен яктырткан «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» исемле яңа серия тәкъдим итәбез. Бу серия археография, палеография, кодикология, текстология, эпиграфика һәм мәдәни мирасны өйрәнү белән бәйләнеше булган башка юнәлешләрнең актуаль мәсьәләләрен яктырткан, фәнни эзләнүләргә һәм ачышларга корылган, даими рәвештә нәшер ителәчәк басмалардан торыр дип уйланыла. Җыентык алда искәртелгән фән тармакларында эшләүче барлык галимнәрне берләштерердәй гыйльми мәйдан булыр дип өметләнәбез.

Беренче чыгарылыш, олуг шагыйребезнең тууына 130 ел тулу мөнәсәбәте белән, Габдулла Тукай иҗатына багышлана.

Габдулла Тукайның тормышы, иҗади эшчәнлеге һәрвакыт әдәбият галимнәренең күз уңында булып, төрле яклап өйрәнелде. Шагыйрьнең күптомлыклары, академик басмалары дөнья күрде.

им. Г. Ибрагимова АН РТ – Мирасханэ – ежегодно пополняется новыми находками: документами, редкими книгами, в том числе рукописными, историческими источниками, личными коллекциями писателей и ученых. К примеру, только в последние годы в Мирасханэ поступили фонды писателя, переводчика А. Хасани (1883–1934), этнографа Фуата Валеева (1918–2010), писателя и переводчика Ахмета Исхака (1905–1991), редкие фотографии из коллекции археографа Саида Вахиди (1887–1938), рукописные и печатные книги разного содержания.

Возобновляя прекрасную традицию публикации источников, отражения новейших исследований в изучении редких текстов, предлагаем новую серию «Духовное наследие: поиски и открытия». Издание планируется на регулярной основе и будет посвящено археографии, палеографии, кодикологии, текстологии, эпиграфики и другим вопросам изучения и введения в научный оборот культурного наследия татарского народа. Надеемся, сборник объединит усилия работающих в вышеназванных направлениях науки ученых не только Казани, но и России в целом.

Первый выпуск серии посвящен жизни и творчеству Г. Тукая в честь 130-летия со дня рождения поэта.

Тиздән, татар әдәбияты тарихында беренче тапкыр, Тукай энциклопедиясе дә үз укучысына барып ирешер. Бик күпләр өчен илһам чыганагы булып торган Тукай иҗаты төрле буын галимнәре тарафыннан никадәр генә тирәнтен өйрәнелгән булмасын, шагыйрьнең тормышына кагылышлы кызыклы фактлар, иҗатын баетучы яңа материаллар әле һаман табыла тора. Әлеге җыентыкта Тукайның шәхесен, аның иҗатын төрле яклап өйрәнүгә хезмәт итүче, фәнгә аз билгеле материалларны тупларга, шәрехләргә омтылыш ясалды.

Китап Тукай шигырьләре белән ачыла. Алар киң җәмәгатьчелеккә аз мәгълүм, шагыйрь вафатыннан соң басылып чыккан «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре»ннән (1914) алынды.

Галимҗан Шәрәф тарафыннан тупланган «Тукаев сүзләре» (1913) исемле җыентык та Тукай иҗатының матурлыгын һәм бөеклеген күрсәтергә омтылган хезмәтләрнең берсе. Биредә әлеге җыентык беренче тапкыр тулы күләмдә укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә шагыйрьнең шәхси фонды саклана. Җыентыкта әлеге фондның тасвирламасы китерелә, укучы ничә еллар дәвамында зур авырлыклар белән җыелып, күз карасыдай саклап киленгән Тукай мирасы белән таныша ала.

Жизнь и творчество Габдуллы Тукая находится в центре внимания вот уже нескольких поколений ученых; увидели свет многотомные издания его произведений, академические издания. Скоро впервые в истории татарской литературы найдет своего читателя и Энциклопедия Тукая. Творчество Тукая, являясь источником вдохновения для многих исследователей и литераторов, несмотря на то, что глубоко изучено несколькими поколениями ученых, все еще радует нас новыми интересными фактами, материалами, документами. В данном сборнике мы сделали попытку осветить, интерпретировать материалы, помогающие понять личность Тукая, расширить научный взгляд на его творчество.

Книга открывается стихами Тукая из сборника 1914 г. «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре», мало известного читающей публике. Сборник «Тукаев сүзләре» (1913), собранный Галимджаном Шарафом, – труд, стремившийся показать красоту и величие творчества поэта. Сборник впервые предлагается вниманию читателей в полной редакции.

В Центре письменного и музыкального наследия института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ – Мирасханэ – хранится личный фонд Тукая. В сборник включено описание этого фонда. Читатель

Җыентыкта Г. Тукайның дусишләре, танышлары, замандашлары, шагыйрьне яхшы белүчеләрнең кайбер истәлекләре урын алды; аларның күбесе билгесез, игътибардан читтә калган истәлекләр, беришеләре исә архивларда сакланган кульязмалар аша тулыландырылды.

Тукай иҗаты күп еллардан бирле эзлекле, тирәнтен һәм җентекле өйрәнелеп килә, ләкин шагыйребезнең тормышы, иҗаты яңадан-яңа эзләнүләргә, табышларга нигез булып тора. Тукай иҗатын төрле яклап өйрәнгән мәкаләләр белән җыентыкның өченче бүлегендә танышырга мөмкин.

Бөек шагыйрьнең үлеме – татар халкын чын мәгънәсендә тетрәндергән вакыйга. Бу фаҗига шигъри җанлыларның һәм хәтта кулына бер генә мәртәбә каләм алмаганнарның да күңелләрен айкый. Татар вакытлы матбугатында аны сагынып, юксынып язылган шигырьләр дөнья күрә. Газета-журналларда 1913–1914 елларда дөнья күргән шул шигырьләрнең бер өлеше, гамәлдәге язуга күчерелеп, җыентыкта урын алды.

Халкыбызның рухи хәзинәсен тулыландыру юлындагы табышларыбыз һәрчак булып торсын, китап рәвешендә укучыга барып ирешсен. Алар халкыбызның рухи дөньясын туктаусыз сугарып торырлар, дигән өметтә калабыз!

имеет возможность ознакомится с подробным перечнем наследия Тукая.

Также представлены воспоминания современников поэта – друзей, коллег, знакомых... Большинство из них мало известно публике и обычно остается без должного внимания; некоторые свидетельства были дополнены на основе рукописей, хранящихся в архиве.

Как мы уже сказали, творчество Тукая последовательно, глубоко и подробно изучается вот уже на протяжении многих десятилетий. С научными статьями, разносторонне подошедшими к творчеству поэта, знакомит третья рубрика сборника.

Смерть поэта стала трагедией для всего татарского народа; событием, глубоко ранившим не только поэтов, но даже тех, кто никогда не брал в руки пера. В татарской периодической печати было опубликовано множество стихов, посвященных Тукаю. Вниманию читателей мы предлагаем небольшую подборку за 1913–1914 гг.

Надеемся, на пути изучения богатого духовного наследия татарского народа будет сделано еще немало открытий, найдут благодарного читателя малоизвестные произведения, тексты – свидетельства прошлого, которые станут источником вдохновения и расширения духовного мира народа.

*...Һаман мин яктырырмын*
*Вә бер дә батмамын, янып торырмын*

# طوغان تل.

اى طوغان تل، اى ماتور تل، ئەتكەم، ئەنكەمنڭ تلى!
دنياده كوب نرسه بلدم، سين طوغان تل آرقلى.
ايڭ الك بو تل بلەن ئەنكەم بيشكده كويلەگان،
آننارى توننار بويى ئەبكەم حكايت سويلەگان.
اى طوغان تل! هر وقتده ياردمڭ برلەن سينڭ
كچكنەدن آڭلاشلغان شادلغم، قايغم مينم.
اى طوغان تل! سينده بولغان ايڭ الك قيلغان دعام:
«يارلقاغل، ديب، اوزم هم ئەتكەم، ئەنكەمنى خدام.»

---

۱۹۰۹ سنه.

Туган тел // Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре. Казан. 1914. Б. 278.

## Туган тел

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишекдә көйләгән,
Аннары төнләр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытда ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шадлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
«Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам».

## بەيرەم بوگون.

بار کوڭللیلك بتون دنیادە، بار بر بەم بوگون!
نرسەدن بو؟ مین بلەم: بەیرەم بوگون، بەیرەم بوگون!

بر مقدس حس بلەن هر بر کشی حیران بوگون،
اوینی سازمدە مینم بەیرەم کوین، بەیرەم بوگون!

آرتدرا، کوردم، قویاش عادتدەگیدن بالقوون،
„اول کیینگاندر!“ دیدم، بەیرەم بوگون، بەیرەم بوگون!

حس ایتوب هر بیردەدە برتورلی خوش ایس آنقوون:
„ایسلی مای سورتکان ایکان دنیا“ دیدم، بەیرەم بوگون!

بر تلەنچینی قوچاقلاشقان کوروب بر بای بلەن،
„کوڭلی نچکەرگان!“ دیدم، بەیرەم بوگون، بەیرەم بوگون!

یار باشندن طڭلادم مین بر صونڭ دولقنلرن:
سویلەشەلر اوز آرا: „بەیرەم بوگون، بەیرەم بوگون!“

طڭلادم ئەکرن‌گنە ایسکاندە بەیرەم کون جیلن،
آنسی‌دە سویلی طاغن: „بەیرەم بوگون، بەیرەم بوگون!“

۱۹۰۸ سنە.

۱٦ ع. توقای مجموعەء آثاری

Бәйрәм бүген // Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре. Казан. 1914. Б. 16.

**Бәйрәм бүген**

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген!
Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген,
Уйный сазым да минем бәйрәм көен, бәйрәм бүген!

Артдыра, күрдем, кояш гадәтдәгедән балкуын;
«Ул киенгәндер!» – дидем, бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Хис итеп һәр йирдә дә бертөрле хуш ис аңкуын:
«Ислемай сөрткән икән дөнья!» – дидем, бәйрәм бүген!

Бер теләнчене кочаклашкан күреп бер бай белән,
«Күңле нечкәргән!» – дидем, бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Яр башындан тыңладым мин бер суның дулкынларын:
Сөйләшәләр үзара: «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»

Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җилен,
Ансы да сөйли тагын: «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»


2.

1

کتاب

БИБЛИОТЕКА
Татарского Научно-Исследовательского
Института Языка и Литературы

حیچده کوڭلم آچلماسلق اچم پوشسه،
اوز اوزمنی کوره‌لمیچه روحم توشسه،
جفا چیکسه‌م، جوده‌ب بتسه‌م بو باشمنی
قویالمیچه جانمه جلی هیچ برتوشکه،
حسرت صوڭره حسرت کیلب آلماش آلماش،
کوڭلمز اوی بله‌ن تمام ئه‌یله‌نسه باش،
کوزلرمده کیبب جیتگان بولسه
حاضرگنه صغلوب صغلوب جلاغان یاش.
شول وقتده مین قولمه کتاب آلام
آنڭ ایزگی صحیفه‌لرن آقتارام
راحتلنوب کیته شونده جانم، تنم
شونده نظنه دردلریمه درمان طابام.
اوقوب بارغان هربر یولم، هربر سوزم
بولامینم یول کورسه‌تکوچی یولدوزم
سویمی باشلیم بو دنیانڭ واقلقلرن
آچیله‌در، نورلانادر کوڭلم، کوزم.

Китап // ЯhММҮ. 9 ф., 1 тасв., 1 с.б., б. 2.

**Китап**

Һич дә күңлем ачылмаслык эчем пошса,
Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә,
Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм бу башымны
Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә.

Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,
Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,
Күзләремдә кибеп дә җитмәгән булса,
Хәзер генә сыгълып, сыгълып елаган яшь.

Шул вакытда мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам,
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шундан гына дәрдләремә дәрман табам.

Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем
Була минем юл күрсәткүче йолдызым,
Сөйми  башлыйм бу дөньяның ваклыкларын,
Ачыладыр, нурланадыр күңлем, күзем.

Җиңелләнәм, мәгъсумләнәм мин шул чакда,
Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка,
Ышанычым арта минем үз-үземә,
Өмид берлән карый башлыйм булачакга.

## ملی موڭلر (۱)

ایشتدم مین کیچه برەو جرلی
چن بزنـڭچه ماتور ملی کوی،
باشقه کیلە اویلر تورلی تورلی
ئەللەنبندی زارلی موڭلی کوی.

اوزلوب، اوزلوب کنەئەیتوب بیره
تاتار کوڭلی نیلر سیز گانن،
مسکین بولوب طورغان اوچیوز یللە
تقدیر بزنی نیچك ایزگانن.

(۱) زیلەیلوك کوینه.

کوبەی محنت چیکـگان بزنڭ خلق،
کوبەی کوز یەشلری توگلـگان،
ملی حسلر برلەن یالقنلانوب
صزلوب، صزلوب چەا کوڭلندن.

حیران بولوب جرنی طـڭلاب طوردم
طاشلاب توبەن دنیااویلارن.
کوز آلدمە کورگان توسلی بولدم
بلغار هم آق ایدل بویلارن

توزەلمادم باردم جرلاوچیغە،
دیدم، قرداش بو کوی، نیندی کوی؟
جوابـندە ملندەشـم میـڭا
بو کوی بولا، دیدی، ئەللوکی.

Милли моңнар // Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре. Казан. 1914. Б. 122.

## Милли моңлар

Ишетдем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка киләуйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чикгән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр берлән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңелдән.

Хәйран булып җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Ак Идел буйларын.

Түзәлмәдем, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Җавабында милләтдәшем миңа:
«Бу көй була, – диде, – Әллүки!».

# تاتار یەشلری.

دفنه لایق حاضرگی کون تاتارنڭ یەشلری،
آڭلامق، بلمك، ترقی، معرفت، حکمت بلەن

ئەبلەنوب هم نورلانوب طورمقده هردم باشلری،
موندی کورنش سوینچندن ایندی مین آلدن بلەم:

تیك بولار بزگه کیرەك دیڭگز توبی غواصلری.
اوستده بویەمسز بولوت باشدن کیتەر، یاکڤر یاوار،

بیرگه رحمت کوك توشەر یەشلرنڭ ایزگی قصدلری،
شاولاب آقغان صو بولور طاو باشلری، طاو آستلری.

کوك بولوب کوکرەر هواده حر یەشەو داولاشلری،
یالترار ایزگی کورەشنڭ خنجری، آلماسلری.

یورمەسون بەغری اوزوك ملت کیبب قاشسز یوزك،
بز آنڭ بیك زور فخرلی چن بریلیانت قاشلری!

۱۹۱۲ سنه.



Татар яшьләре // Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре. Казан. 1914. Б. 154.

**Татар яшьләре**

Дикъкатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре,
Аңламак, белмәк, тәрәкъкый, мәгърифәт, хикмәт белән

Әйләнеп һәм нурланып тормакта һәрдәм башлары.
Мондый күрнеш сөйнечендән инде мин алдан беләм:

Тик болар безгә кирәк диңгез төбе гауваслары.
Өстдә бу ямьсез болыт башдан китәр, яңгыр явар,

Йиргә рәхмәт күк төшәр яшьләрнең изге касдлары.
Шаулап акган су булыр тау башлары, тау астлары.

Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары.

Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек,
Без аның бик зур фәхерле чын брилиант кашлары!

# ТУКАЙ МИРАСЫН ӨЙРӘНГӘНДӘ...

* * *

Габдулла Тукай иҗаты төрле буын галимнәре тарафыннан никадәр тирәнтен өйрәнелгән булмасын, һаман да әсәрләре табылып тора. Академик басманың бишенче томы текстологиясен эшләү этабында Г. Тукайның моңа кадәр бер күптомлыгына да кертелмәгән балалар өчен язылган «Табигать һәм инсан» һәм «Казан шәһәре» хикәяләре барлыгы ачыкланды. Әдәбият галиме, язучы Гали Рәхим «Тукай һәм балалар әдәбияты» (Мәгариф, 1923, № 3–4) исемле мәкаләсендә язганча: «Тукай бер яктан татар шигыренең атасы булса, икенче яктан, шөбһәсез, татар телендәге балаларга махсус әдәбиятның да башлап тудыручыларыннан хисапланырга тиеш». Чыннан да, Тукай шагыйрь генә түгел, ә иҗат гомерендә балалар өчен әкият-хикәяләр язган, уку китаплары төзегән язучы да. Ул балалар күңелен нечкә тоемлап, аларның кичерешләрен, дөньяны танып белүләрен хикәяләрендә матур бизәкләр белән сурәтләп бирә. Аның хикәяләре яшь буынны чын татар җанлы, белемле һәм динле итеп тәрбияләүне максат итеп куя. Г. Тукайның «Табигать һәм инсан» һәм «Казан шәһәре» хикәяләре Казанның «Үрнәк» матбагасында 1910 елда чыккан «Яңа кыйраәт» китабының икенче басмасында урын алганнар. Әлбәттә, совет чорында күптомлыкларга кертелергә лаек табылмаган әлеге текстлар безгә кадәр эшләүче галимнәргә дә билгеле булгандыр. Чөнки шундый рухта язылган әсәрләр турында булса кирәк, 1986 елда нәшер ителгән биштомлыкның бишенче томында бер җөмлә белән генә «...әһәмиятсез һәм искергән әсәрләр төшерелеп калдырылды» дип әйтелгән. Чыннан да совет җәмгыятендә хөкем сөргән коммунистик идеологиягә туры килмәгән милләт, дәүләтчелек, дин хакында язу түгел, сөйләү дә тыелган заманда Аллаһы Тәгаләне мактаган, Казан шәһәре образында чагылыш тапкан дәүләтчелек, милләт хакында язылган әсәрләрнең Г. Тукай «Әсәрләр»енә кертелми, төшерелеп калдырылуы гаҗәп түгел.

## Табигать һәм инсан

Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре дөньяның барча мәхлукатенә[1] дә берәр төрле әмер боергандыр.

---

[1] *Барча мәхлукатенә* – җан иясенә.

Кояшка яктыртырга һәм җылытырга, көннәр, төннәр ясарга, елдагы дүрт фасылны тәртип итәргә, җиргә һәртөрле үсемлекләр, җиләк-җимешләр үсдерергә боергандыр.

Һәм барча җанлы-җансыз мәхлукат, үз-үзләрендән Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсынып, үз эшләрен эшләмәкдәдерләр.

Аллаһ инсанга һич дә фани булмас җан һәм якты, камил гакыл биргән һәм инсаннарга шул гакылны һәр ике дөньяда сәгадәт табар өчен истигъмаль итәргә тугры юллар күрсәткүче пәйгамбәрләр бәгыс иткән[1].

Аллаһ инсанга яхшыны ямандан аерыр өчен үзенең якты гакылын эшләтергә боерадыр.

Аллаһ инсанга, төрле гөнаһлардан ерак булып, Кәляме Аллаһының[2] һәртөрле әмерләренә буйсынырга боерадыр.

Шәригать әмерләрен кыйлу вә кыйлмауны Аллаһы Тәгалә инсанның үз ихтыяр җөзьәсенә калдырмышдыр. Чөнки, әгәр инсан яманлык вә гөнаһ эшләр кыйлса, аның үзенә дә һәр ике дөньяда яман була. Яхшылык кыйлса, үзенә дә һәр ике дөньяда ак йөзлелек вә сәгадәт табыладыр.

## Казан шәһәре

Бу шәһәр мондан дүрт йөз ярым еллар әүвәл безнең ханлыгымызның иң баш шәһәре иде.

Бу шәһәрдә мондан биш йөз ел әүвәл Казанда ханбикә булып торган Сөембикә салган мәсҗед манарасы бу көнгә кадәр саклана.

Бу шәһәр безнең гыйлем ала торган йирләремезнең иң зурысы һәм иң уртасы, бу шәһәр безгә үз телемездә язылган матур-матур һәм файдалы китаплар тарата. Безнең сөекле мөхәррирләремезнең күбрәге бу шәһәрдә торганнар. Бу шәһәрнең бер-берсенә якын гына салынган 17 мәсҗеде, шулар тирәсенә җыелып тора торган 20 мең татар халкы бөтен Русия мөселманнары күңеленә әүвәлдән бирле бертөрле якын булып килгәннәр. Бөтен Русия мөселманнары үзләренең иң зур эшләрендә башлап йөрүне казанлылардан көткән вә авылларга тапшырган; әле хазир дә күбрәк шулай итә. Әйе, бу шәһәр безнең кадерле сөекле шәһәремез. Ул шул көе калсын, шул хәлендә һаман алга барсын!

*Кереш мәкаләне һәм текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Гөлназ Хөснетдинова әзерләде*

---

[1] *Бәгыс иткән* – сайлап җибәргән.
[2] *Кәляме Аллаһының* – Коръәннең.

* * *

Габдулла Тукайның бүгенге көндә укучыларга билгеле булмаган, ягъни аның күптомлыкларының берсенә дә урнаштырылмаган мәкаләләре дә бар.

Татарстан Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге Габдулла Тукай фондында «Пожар вакытында кызгану» һәм «Дүнә вә Мишә» исемле мәкаләләр сакланып калган.

«Пожар вакытында кызгану» – кулъязма хәлендә сакланган, берничә урыннан өзгәләнгән (янган) сатирик парча (9 фонд, 1 тасв., 22 с.б.). «Шүрәле» имзасы белән язылган әлеге язманың башында «Ялт-йолт»ка дигән, ахырында «Монтазам кыйраәт» китабыннан дип куелган искәрмәсе бар. Димәк, Тукай аны «Ялт-йолт» көлке журналына бастырырга әзерләгән. Әмма ни сәбәпледер, мәкалә журналда басылмый кала.

Мәкаләнең язылу датасы билгесез. Эчтәлектән күренгәнчә, текстта гәзитче Мөхәммәтҗан һәм күптән түгел генә Оренбургтан килеп эшкә урнашкан бер кеше турында сүз бара. Мөхәммәтҗан «Бәянелхак» газетасының нашире һәм мөхәррире Сәйдәшев Мөхәммәтҗан Әхмәтҗан улы булса кирәк[1]. Сәйдәшев Мөхәммәтҗан (1865–1914) бу вазыйфага 1912 елдан, ягъни әтисе Әхмәтҗан Яхъя улы (1840–1912) вафатыннан соң гына керешә. Димәк, әлеге мәкаләнең язылу вакыты 1912–1913 (апрель) елларга туры килә.

«Монтазам кыйраәт» китабының (Казан, «Үрнәк», 1909) беренче кисәгендә имзасыз бастырылган шул ук исемдәге мәкаләнең тексты түбәндәгечә: *«Бер вакыт авылда пожар чыгып, бер минут эчендә бөтен йортны ут каплап алды. Идән сайгаклары шыгырдый, бүрәнәләр ялкынланып коела һәм төтен илә аралашкан кызыл ялкынлар түбәгә таба үрмәли башладылар. Озакламый бөтен авыл халкы урамга чыкды: хатын-кыз йорт җиһазыны чыгару кайгысы илә кычкырыша вә егълаша иделәр. Очкынлар әллә нинди бер ут бураны шикелле булып, төрле якка сачылдылар. Тирә-якдагы вак өйләргә дә ут капды. Шулвакыт яна башлаган бер абзар түбәсендә кайдан сикерергә белмичә аптырап йөргән бер мәчене күрделәр. Бичараны һәрьякдан ут чорнап алган иде.*

---

[1] Беренче тапкыр мәкалә турында мәгълүмат Рамил Исламов тарафыннан «Мәдәни җомга» газетасының 2015 елгы 24 апрель (15 (1023) нче) санында бирелде.

*Малайлар мәченең бик кызганычлы тавыш илә мияулап, әрле-бирле йөргәнендән эчләрене тота-тота көлә иделәр. Шул вакыт тимерче Галиулла ачуланып малайларга: «Нәрсәгә көләсез? Алладан куркырга кирәк азрак, явызлар! Ходайның бер мәхлүкы утка яна, ә сез авызыгызны җырып көләсез» дип кычкырды да, баскыч куеп, абзар түбәсенә менде. Мәче бичара, тимерченең ниятене аңлаган булса кирәк, бер дә курыкмыйча аның җиңенә ябышты. Тимерче кире төшеп мәчене иясенә тапшырды.*

«Дүнә вә Мишә» исемле мәкалә, 1953 елда Х. Хисмәтуллин тарафыннан, «Фикер» газетасының 1907 елгы 2 апрель (13) саны кушымтасыннан кыскартылып күчерелгән булган. (9 фонд, 1 тасв., 26 э.б.). Газетада ул Тукайның «Шүрәле» имзасы белән басылган «Күрдегезме?» шигыре белән бергә бирелгән.

Томны төзүчеләр: Х. Хисмәтуллин һәм Я. Агишев ни өчендер беренче дүрттомлыкның 1 нче томына (1955) бары тик «Күрдегезме?» шигырен генә урнаштыралар. «Фикер» газетасының 1907 елгы 2 апрель (13) саны кушымтасы беркайда да сакланмау сәбәпле, текст Х. Хисмәтуллин кулъязмасыннан алып бирелә.

## «Ялт-Йолт»га
## Пожар вакытында кызгану

Болак буенда [...][1] эчендә бөтен йортны [...] ялкынлар түбәгә үрмәли бара [...].

Бөтен Болак буе халкы урамга чыкды. [...] шыгырдый, бура йорт җиһазыны чыгару кайгысы илә кычкыру вә шаулашкан [...] кызыл иделәр. Очкынлар әллә нинди бер ут бураны [...] булып төрле якга сачылдылар. Тирә-якдагы вак өйләргә дә ут капды.

Шулвакыт яна башлаган бер абзар түбәсендә кайдан сикерергә белмичә апдырап йөргән бер мәче күрделәр. Бу мәче күпдән түгел генә Оренбурдан куылып кайткан «корчангы мәче» иде.

Малайлар мәченең, бик кызганычлы тавыш илә мияулап, әрле-бирле йөргәнендән эчләрен тота-тота көләләр иде.

Ә ул вакыт гәзитче Мөхәммәджан, малайларга ачуланып: «Нәрсәгә көләсез? Алладан куркырга кирәк азрак, явызлар! Ходайның бер мәхлукы, кая барырга [...]. Авызыңызны җырып көләсез», – дип кычкырды да, баскыч куеп, абзар түбәсенә менеп «корчангы

[1] Чыганакта бу урыннар бозылган (янган).

мәче» бичара, гәзитә [...]. Бер дә тарт [...]. «Корчангы мәче» һаман шунда мыраулап, [...] тагы [...] улар.

Валлаһи әгъләм биссавап.

*Шүрәле*

(«Монтазам[1] кыйраәт» китабындан)

**Дүнә вә Мишә**

Хәдәсханәсендән чыккан «Дүнә вә Мишә» исемле журналның соңгы номерында «Әл-Мәрҗали» исемле бер зат дөньядагы бөтен мөселман вә нәсара[2] (христиан), яһүди, мәҗүсиләрне оялтырлык дәрәҗәдә сасы вә кабәхәт үзенчә назым илә бер мәкалә язган. Мәкаләсендә бөтен ирләрнең, бөтен мөслимә хатынларның, тагы да йөзләре ачык йөри торган һәммә милләтләрнең хатынларының гыйрызы[3] вә намусларыны тукынган. Җир йөзендәге намуслы вә гыйрызлы ир вә хатынларның һәммәсен ата көчекләр вә ана көчекләр илә тиңләштергән. Оренбургтан бер мөселман кызы ушбу арада гына идарәмезгә язган бер мәктүбендә: шул лакырдыны язучы әл-Мәрҗалины һәм «Дүнә вә Мишә» журналының һәммә мөхәррир вә наширләрен судка бирәмез яки якында булачак хатынлар митингысында сөйләшеп үземез бер төрле ачы вә газаплы хөкем итәчәкмез, дип язадыр.

Керешеңез мөселман хатынлары! Ул залим вә хәясызларның хәлләрен үзләренә белдереңез. Шул кадәр җәза биреңез ки, кыяматкәчә сезнең намус вә гыйффәтеңезгә тияргә батырчылык итә алмасыннар. Ул кабәхәткә сез мөселман хатынлары гына түгел, йөзләренә төшкән кимәүче һәммә башка милләт хатынлары да каршы торырга бурычлылардыр. [...]

Юк, юк! Саклан! Милләтемезнең яртысы булган гыйффәтле хатын-кызларны ачуландырудан! Алар үзләренең намусларын вә гыйрызларын мөдафәга итү[4] өчен малларын вә җаннарын фида итәрләр[5]. Һич шөбһәсез, Мәрҗали әфәндене тыныч тотмаслар. Алар инде аның йокы арасына төшенә керерләр. Алар әдәбият галәмен хәдәскә[6] буяучыга ни кирәклеген күрсәтерләр.

*Кереш мәкаләне һәм текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәрләре, филология фәннәре кандидаты Эльмера Галимҗанова, Фәния Фәйзуллина әзерләде*

---

[1] *Монтазам* – тәртипкә салынган.
[2] *Нәсара* – христиан.
[3] *Гыйрызы* – абруе.
[4] *Мөдафәга итү* – саклау.
[5] *Фида итәрләр* – корбан итәрләр.
[6] *Хәдәскә* – тизәккә.

# ТУКАЙНЫҢ ХИКМӘТЛЕ СҮЗЛӘРЕ

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай телебезне баетуга күп көч куйган әдипләребезнең берсе. Аның иҗаты белән якыннан таныша барган саен, теленең үткерлегенә, тапкырлыгына кабат-кабат инанасың. Тукайның кыска, тәэсирле итеп әйтелгән, тирән мәгънәле фикер белдергән сүзләре мәкаль-әйтемнәргә, афоризмнарга тиң. Тукай үзе исән вакытта ук аның әсәрләрендәге хикмәтле сүзләргә, гыйбарәләргә игътибар ителәә башлый. Сүзләренең үтемлелеген арттыру максатыннан, халык еш кына Тукайга мөрәҗәгать итә. Халык телендә Тукай сүзләренең киң кулланылыш алуы «Тукаев сүзләре» исемле китапның барлыкка килүенә зур этәргеч булып тора. Күренекле тел галиме Галимҗан Шәрәф, Тукай әсәрләрен барлап, хатларында һәм сөйләмендә кулланылган һәр сүзенә игътибар итеп, әдипнең афоризмнарга тиң гыйбарәләрен туплый һәм 1913 елда «Җәмигыль кямил (*афоризмнары*), халык мәкальләре урынында йөртерлек вә йөртелә торган сүзләре» исем асты белән аерым җыентык бастырып чыгара. Әлеге китапның 1913–1920 еллар аралыгында дүрт тапкыр басылып чыгуы мәгълүм. Китапның беренче һәм соңгы басмалары арасында аермалар күзәтелә. Соңгыларында кайбер гыйбарәләр ни сәбәпледер төшереп калдырылганнар, кереш өлешендәге гарәп-фарсы алынмалары татар теленең үз сүзләре белән алыштырылганнар. Китапта Тукай афоризмнары 13 тематик һәм 1 өстәмә төркемгә бүлеп урнаштырылган, әмма аларның кайсы әсәрләрдән алынуы күрсәтелмәгән.

Г. Шәрәфнең китапка керешендә ышанып әйткән: «Киләчәкдә Тукаевның да күп шигырьләре татарлар арасында шулай ук бабалар мәкале берлә беррәтдән йөртеләчәкләрдер» – дигән сүзләре дөреслеккә туры килә. Тукай сүзләре еллар үтү белән дә мәгънәви әһәмиятләрен югалтмаган. Бу сүзләрне халык энҗе бөртекләре кебек саклый, бүген дә аларга еш кына мөрәҗәгать итә.

«Тукаев сүзләре»нең 1913 елгы басмасы, гарәп графикасыннан кирилл хәрефләренә күчерелеп, гарәп-фарсы алынмаларына сүзлек бирелеп, өзекләрнең кайсы әсәреннән булуы күрсәтелеп эшләнде.

## Тукаев сүзләре

Наширләрдән:

Тукай шигырьләренең мәгънә җәһәтендән тирәнлеге, самимилеге вә теле җәһәтендән матурлыгы тугрысында язып тору,

шәкердләр тәгъбире берлә әйтсәк, мәгъруфны тәгъриф – мәгълүмне тәгълим[1] булганлыкдан, без аларны калдырып, тугры максадка күчәмез.

Хәзердә руслар арасында Пушкин, Лермонтов, Грибоедов вә башка мәшһүр әдипләрнең бәгъзе сүзләре, ничек мәкальләр урынына йөртелсә, киләчәкдә Тукаевның да күп шигырьләре татарлар арасында шулай ук бабалар мәкале берлә беррәтдән йөртеләчәкләрдер. Инде хәзердә дә сүз арасында мохатәбенә[2] сүзене ачыграк аңлатасы, я аны берәр нәрсәгә мөсәлләм итәргә[3] теләгән кешеләр агызындан дәлил урынына Тукаев шигырьләренең кисәкләре шактый ишетелгәлиләр, газета вә журналларда мәкалә язучыларымыз да Тукаев сүзләрене үзләренә ярдәмгә еш-еш чакыргалыйлар.

Файдаланырга теләгән кешеләргә эшне җиңеләйтер өчен, без Тукаевның шигырь вә нәсер берлә язган әсәрләрендән шундый вакытларда файдаланырга ансат булган 2–3 юлда тулы-түгәрәк бер мәгънә, бер фикер эченә алган җөмләләрне җыеп басдырамыз.

Бу җөмләләргә карап, Тукаевның тирән фикерләрне, киң мәгънәләрне, шулкадәр аз сүз берлә вә шундый матур итеп әйтә алуына гаҗәп итмәслек түгелдер. Без укучыларның бу тәгаҗҗебне[4] безнең берлә бүлешәчәкләренә ышанамыз.

Билгеле, Тукаевның һәрбер сәтырында[5], һәрбер сүзендә уйлап укыганда әлләни кадәр нечкә вә гали мәгънәләр табарга мөмкин. Бу әсәрдә исә Тукаевның бәгъзе бакчаларындан гына сачәкләр җыелганга, бу букетка карап кына Тукаевның бөтен әсәрләре тугрысында ачык вә тугры бер карарга килергә мөмкин түгелдер. Тукай берлә якынрак, яхшырак танышырга теләүчеләргә Тукаевның тиздән басылып чыгачак «Мәҗмугаи асар»ене тәкъдим итәмез. Анда Тукаевның әлегә кадәр китап шәкелендә басылмаган байтак яңа әсәрләре дә булачакдыр.

«Мәгариф» көтепханәсе

[1] *Тәгълим* – билгеле нәрсәне сөйләү.
[2] *Мохатәбенә* – тыңлаучысына.
[3] *Мөсәлләм итәргә* – ышандырырга.
[4] *Тәгаҗҗебне* – гаҗәпләнүне.
[5] *Сәтырында* – юлында.

## Аллага ышану

Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен;
Ядыма[1] Тәңрем төшә, бәхтем кара булган саен!
*(«Күзге җилләр»)*

Түкмә күз яшь, ярдәмеңдә һәр заманда Алла бар,
Ал җәсарәт[2], алга омтыл, һич ялыкмый алга бар*!*
*(«Киңәш («Чикмә гамь...»)»)*

Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына,
Бел аны: керсез күңелдән тугры юл бар гаршенә!
*(«Таян Аллага»)*

Җиһанда барча эшләр, барча хәлләр Тәңредән, бәгърем!
*(«Ана илә Бала»)*

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала,
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм[3] таян син Аллага!
*(«Таян Аллага»)*

## Мәхәббәт

Йир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигьре шагыйрь, булмаса илһамчысы.
*(«Мәхәббәт»)*

Файдасыз бер ит кисәгендән гыйбарәтдер йөрәк,
Парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.
*(«Мәхәббәт»)*

Исемдә, иң элекке саф мәхәббәт дәрте кузгалгач,
Илаһи бер тәләззездән[4] беренче кәррә[5] тамган яшь.
*(«Исемдә»)*

Белмичә «уйный» диләр, эчтәнниләр уйланганын;
Сизмиләр – чыкмый төтен тышка – мәхәббәт янганын.
*(«Гашыйк»)*

---

[1] *Ядыма* – хәтеремә, исемә.
[2] *Җәсарәт* – батырлык, кыюлык.
[3] *Һәрдәм* – һәрвакыт, һәр сулыш.
[4] *Тәләззездән* – ләззәтләнүдән.
[5] *Кәррә* – тапкыр.

Ул түнә, хәлсезләнә шул, очраса үз хурына,
Хәзрәти Муса тәхәммелсез[1] тәҗәлли[2] нурына.
*(«Гашыйк»)*

Нишләсен, җанаш хозурында аңар лязем намаз;
Бер азан әйткәч, колак каккач, мөселман уйнамас!
*(«Гашыйк»)*

Мәхәббәтем – һаман иске мәхәббәт ич,
Югалтсам мин, югалттым, ди, шаһлык кына.
*(«Төш»)*

Үлде рух яшьрен мәхәббәтдән, – хафа юк үлсә дә, –
Нишлим, иркәм кәйфенә килгәч шулай бер җан кыю!
*(«Актык тамчы яшь»)*

Сөйгәнеңне мин кочам, дип, дошманым көлгән була;
Белми: җанаш кайгысы һәр кич кочагымда куна.
*(«Төрекчәдән («Сөйгәнеңне мин кочам, дип...»)»)*

Минемчә, тик яралган ул сөелергә,
Сөяргә һәм куанырга, көенергә;
Күргән саен, минем төсле гашыйкларга:
«Бу минеке булмас!» – диеп көенергә.
*(«Утырышу»)*

Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшерен яну!
*(«Мәхәббәт»)*

И матур! Мин янмас идем – яндыручы булмасаң;
Таммас иде җиргә яшьләр – тамдыручы булмасаң!
Бер минутда ташлар идем бу томанлы моңларый, –
Син мине мескин кыйлып моңландыручы булмасаң!
*(«Син булмасаң!»)*

Гомерлеккә башың әйләндерер ул;
Ирексез әйләр ул бәйләндерер ул!
*(«Вәгазь»)*

Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул бүген;
Ул шуңар да шадлана бит – чын җүләр түгел диген!
*(«... гә («Очраган юлда...»)»)*

---

[1] *Тәхәммелсез* – чыдаусыз.
[2] *Тәҗәлли* – иляһи көчләрнең күңелдә чагылышы.

Һич хуҗалыкны кабул итмәм бөтен дөньяга мин,
Булмага мөмкин икән гыйшык, мәхәббәт ялчысы!
*(«Мәхәббәт»)*

Барча әхрары[1] мәхәббәт миндән уңда, зан итәм[2], –
Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! – мин аларның таңчысы!
*(«Мәхәббәт»)*

Мин сөям, хәтта ки гакълымдан шашам –
Сөйгәнемдән шүрәле төсле качам.
Юлда күрсәм, күз йомам, күрмим, имеш;
Ут йотып янсам да, сер бирмим, имеш.
*(«Кызык гыйшык»)*

Булмаса сайраулары мәдхе сәнасында[3] моның,
Кит! Пычак керсен җиһанның барча сандугачына!
*(«Бер рәсемгә»)*

Көлсә, көлсен, шул кирәк шул, анда синең ни эшең?
Әйдә, көлсен ул матур, дөньяга күрсәтсен тешен.
Теш нурын чәчсен дә дөньяны җибәрсен балкытып;
Җире, күге яктырып китсен әле бер ялт итеп!
*(«Шәйтанның муенына»)*

Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә[4] дөнья бәһа;
Ул болай бер кыз гына – каршында Мәҗнүн булмаса!
*(«Булмаса»)*

Һич килештермим синең төсле гүзәллек шаһына,
Ичмасам, бер хисле шагыйрь дә килеп кол булмаса!
*(«Булмаса»)*

Һич элекке төсле алдыңда түбәнләнмим хәзер;
Без ераклашдык, ишет: син – син хәзер, мин – мин хәзер!
*(«Алдандым»)*

Инде әмриткән сүзең дә аяте Коръән түгел;
Тәмле сүзең яки шелтәң күңлемә солтан түгел!
*(«Алдандым»)*

---

[1] *Әхрары* – ирек сөючеләре, иреклеләре.
[2] *Зан итәм* – уйлыйм.
[3] *Мәдхе сәнасында* – мактавында.
[4] *Мәхбүбәгә* – сөелгән, яратылган хатын.

Кувәи шигъриями[1] – җанымны бирдем мин сиңа,
Әйтче, и салкын матур! Каршы ни бирдең син миңа?
*(«Алдандым»)*
Хуш җаным! Сөймим хәзер, сине вә синдән башканы;
Син сөя бир алда тагын берне – миндән башканы!
*(«Алдандым»)*

Барча кызлар алдый, дим, һичберсе юк ки алдамас;
Кайсы кызлар алдамас соң, син фәрештәм алдагач!
*(«Алдандым»)*

Кич мине, мин башны бөкмим, мин үземчә зур хәзер,
Син дә бер мәгърурә булсаң, мин дә бер мәгърур хәзер!
*(«Алдандым»)*

Бер мәхәббәтнең газабын, михнәтен сизгән кеше,
Бер сөеп арган вә җөмлә нәрсәдән бизгән кеше –
Күңеле бозланган кешедер: һич тагын бер кат сөймәс,
Инде ул беркем өчен дә гамь йимәс һәм «аһ!» димәс!
*(«Соңра»)*

**Балалар вә балалык вакыты**

Саф әле күңелең синең, һичбер бозык уй кермәгән,
Пакъ телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән;
*(«Таян Аллага»)*

Пакъ җаның һәм пакъ тәнең – барлык вөҗүдең пакъ синең;
Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-пакъ синең!
*(«Таян Аллага»)*

Бәхетле нарасыйдә! Тар бишек дә киң әле аңар!
Ике ат бер тиен, диңгез тубыкдан тиң әле аңар.
*(«Бишектәге бала»)*

Туйса Иблис, тормышыннан, яд итә оҗмахларын, –
Яд итәм, бизсәм үземдән, мин сабыйлык чакларын.
*(«Сагыныр вакытлар»)*

И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы,
И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы!
*(«Сагыныр вакытлар»)*

---

[1] *Кувәи шигъриями* – шигъри көчемне.

Исемдә курка– курка төрле уйлар уйлаган чаклар,
Гафифанә вә мәгъсуманә[1] көлгән, уйнаган чаклар;
*(«Исемдә»)*

Күңелдән сагынам «тоткын»лыгымны, мәктәбемне мин,
«Нигә соң үсдем инде һәм нигә «дәү» булдым инде», – дим.
*(«Гомер юлына керүчеләргә»)*

Нигә, – дим, – изге мәктәпдән, сабый чаклардан аерылдым?
Нигә дим кечкенә «Апуш» түгел, зуп-зур «Тукай» булдым?
*(«Гомер юлына керүчеләргә»)*

Тәңре! Чигерче яшемне, синдән сорыйм,
Теләгемне синдән сормый, кемдән сорыйм?
Бәйрәм көнне генә сабый булып торыйм,
Рәхәтләнеп, сикереп, көлеп, уйнап йөрим!
*(«Бәйрәм вә сабыйлык вакыты»)*

**Үзеңә ышану**

Сәгадәт талына менсәң – үзең мен;
Ни ярдәм килсә дә килсен үзеңдән!
*(«Тормыш»)*

Авырлык төшсә түз, сер бирми-нитми;
Ни хәлләр яшь кешегә килми-китми? *(«Тормыш»)*

Оныт барсын – бөтен хәсрәт вә моң зарыңны тын эчдән,
Хозур да эзләмә инсаф вә вөждан кушмаган эшдән!
*(«...га («Шома тормыш юлында»)»)*

Бирмә сер һичкемгә: сөйләшсәң сөйләш өсдән генә;
Көл – караңгы йөз бирү анчак килешмәсдән генә!
*(«...гә (Ядкяр)»)*

Ышанма, дөньяда һәркемдә ялган!
*(«Ачы тәҗрибә авазы»)*

Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,
Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл!
*(«Киңәш («Якын дустым...»)»)*

Үзеңне сөй! Ярат, үзеңне үзең!
*(«Кемне сөяргә кирәк?»)*

[1] *Гафифанә вә мәгъсуманә* – саф һәм гөнаһсыз.

Кешеләр үзләрен анчак сөярләр,
Бәхетсезләрнең өстендән көләрләр.
Алар ерткыч, алардан читдә бул син
Алар барда бүрең бер якда торсын!
*(«Киңәш («Якын дустым»)»)*

Сереңне бирмә, яшер карның ачын,
Ләимдин[1] интизар итмә[2] мәгашың[3]!
*(«Шәкерд, яхуд бер тәсадеф»)*

**Эшкә өндәү**

Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәндән килә,
Аһ! Оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәндән килә.
*(«Эшкә өндәү»)*

Булса калдырмак берәү ушбу җиһанда изге ат,
Тир белән тапсын ашарын, итсен, әлбәт, иҗтиһад[4].
*(«Эшкә өндәү»)*

Тынма, эшлә, и сабый! Бел, Тәңредән эшләргә – көн,
Эшләп аргачдан, бирелгәндер тыныч йокларга төн.
*(«Эш»)*

Син кояшдан үрнәк алсаң, иҗтиһад итсәң һаман,
Күп арасында кояш күк ялтырарсың бер заман!
*(«Эш»)*

Күрәм хәзер: эшкә һич нәрсә тиң түгел,
Эшдән көчле нәрсә табар мөмкин түгел!
*(«Япун хикәясе»)*

Гомер итмәк – тырышмакдыр, ялыкмый, һич дә ял итми,
Гаталәт[5] хурлыгын асла[6] үзеңә ихтыяр итми.
*(«Гомер юлына керүчеләргә»)*

---

[1] *Ләимдин* – саранннан, үзеннән-үзе кызганучыдан.
[2] *Интизар итмә* – зарыгып көтмә.
[3] *Мәгашең* – хезмәтең өчен бирелә торган акчаңны.
[4] *Иҗтиһад* – тырышлык.
[5] *Гаталат* – ялкаулык.
[6] *Асла* – һич, бер дә.

Ах, җүләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул;
Картаеп каткач буыннлар, эш белү уңайсыз ул!
*(«Кызыклы Шәкерт»)*

Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел.
*(«Эшкә өндәү»)*

**Өмид, өзелгән өмид**

Юк! Түбән калмас бу җан: фитърәтдә[1] гали[2] булган ул,
Кисмәк өстендә каракош – иттифакый[3] кунган ул.
*(«Өмид»)*

Кайвакытлар һәр сәгадәтдән өмидемне өзәм, –
Әллә кайдан шунда икъбаль[4] атлы чулпаным килә.
Ялтырый ул күкләремдә, күп өмидләр артдыра:
Күз яшем сөртергә гүя назлы җананым[5] килә.
*(«Тәрәддөд вә шөбһә»)*

Теләү бетде хәзер миндә теләкдән соң теләкләрне!
*(«Теләү бетте»)*

Сау бул, дөнья, инде бетдек;
Бетәргә сүзне беркетдек;
Вактында йирне селкетдек,
Инде бетдек, инде бетдек!
*(«Кичке азан»)*

Әсирмен, ычкыналмам инде мәңге,
Күңелсез һәр ягым – нурсыз караңгы.
*(«Үкенеч»)*

Язасылай сүземне язалмыйм,
Ни булдикән минем каләмгә?
Язам, диеп кенә утырсам да,
Вакътым гына китә әрәмгә!
*(«Сакмар суы» көенә)*

---

[1] *Фитърәтдә* – яратылышында, тумыштан.
[2] *Гали* – бөек.
[3] *Иттифакый* – очраклы рәвештә.
[4] *Икъбаль* – бәхет, уңыш.
[5] *Җананым* – сөеклем, җанашым.

Нинди дәрт берлә каләм сызсам да кәгазь өстенә,
Очмый әүвәлге җүләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы.
*(«Өзелгән өмид»)*

Күз яшең дә кипмичә, егълап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең, ят кеше?!
*(«Өзелгән өмид»)*

И мөкаддәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен – аерылабыз, ахрысы!
*(«Өзелгән өмид»)*

Тормыйм инде – бу дөньядан туйдым инде!
*(«Дөньяда торыйммы? – дип киңәшләшкән дустыма»)*

**Кайгы хәсрәт**

Караңгыдыр, күңелсездер гомер юлы;
Бу дөньяда кем килсә дә сиңа туры;
Шиксез, аның җәрәхәтле күкрәгендә
Яшьрен генә янып яткан хәсрәт тулы!
*(«Сәрләүхәсез»)*

Фәкыйрь калдым хәзер: тормыш үзенең биргәнен алды;
Күңел буш: анда калды тик авыр хәсрәт, ачы кайгы.
*(«Теләү бетте»)*

Әйләнә бит, үтми, бетми гомре дә!
*(«Читен хәл»)*

Ни була тугъмак сыйратын кичмәсәм!
Бу ачы гомрем шәрабен эчмәсәм?!
*(«Читен хәл»)*

Катле нәфситсәм[1], Ходайдан куркамын,
Ләкми чир, аурып да булмый, ичмасам!
*(«Читен хәл»)*

Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна;
Анда тормакка һәвәслек берлә ваклар мөбтәля![2]
*(«Дошманнар»)*

---

[1] *Катле нәфситсәм (катле нәфес итсәм)* – үз-үземне үтерсәм.
[2] *Мөбтәля* – дучар булган.

Керләнә өст-өстенә рух, һич хозур вөжданга юк;
Ни сәбәпдән йир йөзендә тәнгә – мунча, җанга – юк?!
*(«Тәләһһеф»)*

Мин, караңгылык эчендә уйланып яткан көйгә,
Нечкәреп күңлем, җылыйм да бер сүз әйтәм лампага:
«Ни бәхет! – дим, – иртәгә кич син тагын да янмасаң,
Бу янышдан мин дә мәхшәр җитмичә кузгалмасам!»
*(«Кичке теләк»)*

## Үз-үзенә

Баш имә – зур син – бу әдна[1] җанлылар дөньясына;
Падишаһ син! Бик кирәксә, баш исен дөнья сиңа.
*(«...гә (Ядкяр)»)*

Таш йөрәкләр кырсалар күңелеңне – түз, эндәшмә син;
Эшләре шул: болгасыннар, әйдә зәм-зәм чишмәсен.
*(«...гә (Ядкяр)»)*

Күңлемдә көн һаман аяз – һаман да яз:
Шагыйрь күңлендә кыш булмый да кар яумый.
*(«Шагыйрь»)*

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
«Без китәбез, сез каласыз!» – дип җырлармын,
Җәсәдемне[2] туфрак берлә күмгәндә дә!
*(«Шагыйрь»)*

Инкисар ит[3] гадәтенчә, ян, күңел, сызлан, күңел!
Күп сөекледер бөтендән – Тәңрегә сынган күңел.
Алга сәүкъ ит сахибеңне[4], бул чыдауда таш кеби,
И фәләкнең[5] төрле-төрле золменә[6] күнгән күңел!
*(«Күңел»)*

---

[1] *Әдна* – бик түбән.
[2] *Җәсәдемне* – гәүдәмне.
[3] *Инкисар ит* – сын, кайт (күңел).
[4] *Алга сәүкъ ит сахибеңне* – хуҗаңны алга этәр.
[5] *Фәләкнең* – язмышның.
[6] *Золменә* – җәберенә, изүенә.

Мин сизәм: дөнья йөзе – дүзәх[1], җәһәннәмдер миңа;
Бер шигырь язсам гына, җәннәт вә ризваным[2] килә.

*(«Тәрәддөд вә шөбһә»)*

Кайт, и нәфсе мотмәиннәм[3]! Бар, юнәл, кит Тәңреңә!
Бирдең арканңны моңарча, инде бир бит әмренә.

*(«Васыятем»)*

**Милләт, миллият вә туган йир**

Җилбер-җилбер йөрмәс идем,
Җил тавышын сизмәсәм;
Өзелеп такмак әйтмәс идем,
Үз халкымны сөймәсәм.

*(«Җил тавышы»)*

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үсдерде сыйпап тик маңлаемдан милләтем.

*(«Дошманнар»)*

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.
Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын!

*(«Үз-үземә»)*

Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,
Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас.
Кичә якты вә милли бер күңелдән
Бүген тычкан утыдай нур табылмас.

*(«Яшьләр»)*

Бәрсә дә дулкынларың, һич алмады, гаркъ итмәде[4];
Алды дүрт ягымны ялкын, якмады, харкъ итмәде[5];

*(«Туган җиремә»)*

Бу сәбәпдән аңладым мин, и туган йирем, синең
Җанга ягымлы икәндер ялкының да дулкының!

*(«Туган җиремә»)*

---

[1] *Дүзәх* – тәмуг, җәһәннәм.
[2] *Ризван* – җәннәт бакчалары сакчысы.
[3] *Нәфсе мотмәиннәм* – тынычлыгым.
[4] *Гаркъ итмәде* – батырмады.
[5] *Харкъ итмәде* – яндырмады.

Кая барсам, кайда барсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган йирем.
*(«Туган авыл»)*

Милләт үз кешеләрен онытмый, җаным!

Күзендән канлы яшь түксен иде барча шәятыйным[1],
Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Раб! гүзәл эзне.
*(«Күңел йолдызы»)*

Сән мөкаддәс, мөхтәрәм гыйндемдә варлык нәрсәдән;
Сатмазым[2] бу кяинатә[3] милләтем, миллиятем!
*(«Милләтә»)*

## Халык тел вә әдәбияты

Валлаһи, җандай күрәм мин искеләрнең җырларын,
Күкрәгемдә саклыйм, әйтерсең, рәсүлнең тырнагын.
*(«Күк сыер»)*

Халык хисләре берлә хисләнмәгән кешеләр өчен гади бер кычкырып утыру булган бу «җырлаулар» минем күңелемнең иң нечкә кылларына тукыналар[4] иде. *(«Халык моңнары»)*

Халык җырлары бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирасдыр. *(«Халык әдәбияты»)*

Чын халык рухын тик халык җырларындан гына табып була. *(«Халык әдәбияты»)*

Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул! *(«Халык әдәбияты»)*

Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкдән, миндә туган телемезне сөю тугды. *(«Халык әдәбияты»)*

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.
*(«Туган тел»)*

---

[1] *Шәятыйным* – *шәйтаннарым.*
[2] *Сатмазым* – сатмамын.
[3] *Кяинатә* – дөньяга, галәмгә.
[4] *Тукыналар* – кагылалар.

**Тәнкыйдьчеләргә**

Ул тота ат койрыгын да: «Бу – озын сач!» – дип куя.
«Тик нигә башда түгел, тәнкыйдькә мохтаҗ!» – дип куя.
*(«Мөнтәкыйд»)*

Ул сукачыны күрә дә: «Җир боза бит!» – дип куя,
«Шундый зур эшкә каләм әһле түзә бит!» – дип куя.
*(«Мөнтәкыйд»)*

Үзләре... сүздән түбәнләр, күзләре эздән түбән;
Эт кеби һаулап яманым, күз йомалар яхшыма.
*(«Дошманнар»)*

Дөньядан туйдым, өмидем юк, алар күпсенсә дә,
Тик мин үлгәчден, караңыз, типмәсенләр нәгъшемә[1]!
*(«Дошманнар»)*

**Алтын вә байлык**

Фәйзы бакый[2] – таҗе шагыйрь[3] мәңгегә булмас сиңа,
Ваксынып, син төшсәң алтын шылтыравы астына.
*(«...гә (Ядкяр)»)*

Бу җиһан Иблис вә шәйтанлар белән калыр тыныч,
Бетсен иде шул сары йөз, – шундадыр зур куркыныч.
*(«Алтынга каршы»)*

Мин тәмам гиздем җиһанны – кайда, кайда йөрмәдем,
Тик шул алтындан – бәла, шәйтан-фәлән һич күрмәдем.
*(«Алтынга каршы»)*

Тәти тапса сабый барган юлында,
Йомыш исдән чыгар, һич айрылалмас.
Шулай яшьләр дә: юлда күрсә алтын,
Баюдан башкага күңлен дә салмас.
*(«Яшьләр»)*

Туктале, бер көн килер дә өйрәтер, әлбәт, ләхед, –
Миллионың ул тар ләхеттә файда бирмәс, бәдбәхет!
*(«Матбага берлә уйнаган бер байга»)*

---

[1] *Нәгъшемә* – җеназама.
[2] *Фәйзы бакый* – мәңгелек байлык.
[3] *Таҗе шагыйрь* – шагыйрьлек таҗы.

Туктале, алдыңда дуст, мәхшәр дә бардыр, суд да бар,
Каһре Хак[1] бар, тиз янар корсагың, анда ут да бар!
Анда хакимләр дә алтынларга һич алданмыйлар;
Анда адвокад да юкдыр, – акчага ялланмыйлар!

*(«Матбага берлә уйнаган бер байга»)*

Зур эш мени ул бай булу?!

**Киңәш – нәсыйхәт**

Уграшып торма җиһанда иң түбән мәхлук[2] белән!

*(«Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә»)*

Зәгыйфь, корбан булу артык, Ходаем,
Булудан андан көчле һәм дә залим!

*(«Күгәрчен»)*

Ихтыяҗын гарз итеп[3] килсә теләнче капкаңа,
Каты сүзләр берлә инсаниятен[4] син таптама.

*(«Нәсыйхәт»)*

Әйләнә, көпчәк кеби, байлык вә шөһрәт, мәртәбә:
Син бүген бай, бәлки шәйтандан да ярлы иртәгә!

*(«Нәсыйхәт»)*

Бәхетсезләрне кимсетмә, егылганларга син кул бир!

*(«Бәхетле бала»)*

Газаб китми кабердә тән черүдән:
Бүрек ташлап котылмыйлар бүредән!

*(«Катиле нәфескә»)*

Батарсың дим – йөгермә Нилгә каршы;
Кире кайтыр – төкермә җилгә каршы.

*(«Бер манигы тәрәккыйгә»)*

Бу дөньяда тору, дуст! – Ярсыз артык,
Икәү булганчы булмак ялгыз – артык.
Берәү булсаң, ике җан бирмисең син,
Ике рәт җан ачысын күрмисең син!

*(«Вәгазь»)*

---

[1] *Каһре Хак* – Аллаһ каһәре.
[2] *Мәхлук* – җан иясе.
[3] *Гарз итеп* – гарыз итеп – аңлатып, җиткереп.
[4] *Инсаниятен* – кешелеген.

Тәшагырь итмә[1], зинһар, кермә шагыйрь битлегенә син,
Кисәрләр койрыгыңны, кермә былбыл читлегенә син!
*(«Мөтәшагыйрьгә»)*

Әгәр басса сине бер-бер заманны
Җыламый йомшамас хәсрәт вә кайгы, –
Утыр аулакка, кайда һич кеше юк,
Сабыйдай тәмле-тәмле күз яше түк!
*(«Киңәш»)*

И карендәш! Син, кирәксә, суга бат йә сөткә бат!
Ит сабыр, күрсәт чыдамлык, һәм дә ит гайрәт, сөбат[2]!
*(«Сөткә төшкән тычкан»)*

Өйләнмә, баш имә һич, телгә дә алма «хатын-кыз» дип;
Олуг җан бул, куан-шадлан, шөкер, бит мин хатынсыз, дип.
*(«Толстой фикере»)*

Өйләнмәк бер-берәүнең җәбре-хаһре өсткә менмичә –
Егылмак берлә бердер, һичбер әйбергә абынмыйча.
*(«Толстой фикере»)*

Кем генә булсаң да, бул – юк ансына һичбер сүзем;
Тик сүзем шулдыр сиңа: саклан булудан үз-үзең!
*(«...гә (Ядкяр)»)*

Үл! Туфрак бул, кайт асылыңа, – асылың яхшы,
Хәнҗәр берлән күкрәгеңә касдың[3] яхшы.
И йир шары! Нидән, белмим, хак сөйгәнгә
Мең кат синең өстеңдән дә астың яхшы.
*(«Дөньяда торыйммы? – дип киңәшләшкән дустыма»)*

**Гыйлавә**

Хак Тәңренең каршысында килешмидер
Тәһарәтсез намаз илә корбансыз хаҗ!
*(«Милләтчеләр»)*

Нәрсә пешсен, булса ялкынсыз күңел, сүнгән күңел!
*(«Күңел»)*

---

[1] *Тәшагырь итмә* – үзеңне шагыйрь итеп күрсәтергә азапланма.
[2] *Сөбат* – чыдамлык.
[3] *Касдың* – (чәнчергә) явыз ниятең.

Булмаса дустлык, җитә бит сугышырга бер юк эш!
*(«Чын вә ялган»)*

Бу дөньяда, табигыйдер, кеше буш булмый дошмандан,
Шулай ансы; вәләкин, и Ходаем, сакла дустлардан!
*(«Вак-төяк»)*

Күрсәтер изге уемны күз яшем,
Айрылыр арзанлы таш чын энҗедән!
*(«Милләтче»)*

Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан,
Вә юлны тапмый калган һәр адашкан.
*(«Тормыш»)*

Без яраткачдан ярар, дим, кем аны синдән сорар?
Хөр кеше алдында йирләр һәм дә күкләр калтырар!
*(«Гөнаһ»)*

Җаһилең[1] дошманлыгыйлә ифтихар итмәк[2] кәрәк;
Анларың һәр сәбләри[3] бер-бер вирер фәхри[4] сәңа!
*(«Мөхәрриргә»)*

Бөтенләй бәйләнә анда аяк-кул,
Җүләрлек ул – өйләнмәк, гайре мәгъкуль[5].
*(«Өйләнү – түгел сөйләнү»)*

Бел, хәзер дөнья кяфергә һәм сиңа җәннәт әле;
«Мөэминә зиндан» булыр ул, тотса мәскәүләр якаң.
*(«Тотса мәскәүләр якаң»)*

Җәза бирми халык һич дә гөнаһ эш, яшьрен эшләргә,
Куша анчак[6] кеше сизмәс рәвешдә яшрен эшләргә!
*(«...га («Шома тормыш юлында...»)»)*

Утыз ел казыган баз бик тирән шул:
Менә инде Хәмидең шунда «Гөмберррт!»
*(«Габделхәмид»)*

[1] *Җаһилең* – наданың.
[2] *Ифтихар итмәк* – мактану.
[3] *Сәбләри* – начар сүз әйтүләре.
[4] *Фәхри* – мактау.
[5] *Гайре мәгъкуль* – акылга сыймый торган.
[6] *Анчак* – бары тик.

Аның күк тиз сүнә торган сөюдә ни хәер бар соң?!
*(«...га («Шома тормыш юлында...»)»)*

Эзләдем, филлаһ, сөямен, биллаһ[1];
Эзләдем дә тапдым... бу бәлане!
*(«Төрекчәдән («Эзләдем, филлаһ...»)»)*

Бик күңелсез бер начар журнал – гомер
Анда, әлбәт, баш мәкалә мал ирер.
*(«Гомер хакында»)*

Без җүләрме, үземезне утка илтеп ник терик?
Бу кызу йирдән чыгып, тагын сәкарьгә[2] ник керик!
*(«Китмибез»)*

Таш йөрәкләр һәм яшен күргәч укыр «ляхәүлә»сен!
*(««Яшен» журналы хакында»)*

Киләчәккә кешенең күзе йитми. Ул сыбызгының үзенә нигә төшкәнен соңындан гына сизә. *(«Сыбызгы»)*

Алганы булса берәүдән, ахирәт исдән чыга,
Биргәне булса: «янарсың», – ди, кыямәт күрсәтә.
*(«Күрсәтә»)*

Уйнасын шул бәндә – кемнең акчасы бар, вакъты бар,
Әйдә отдырсын бәхетсез, отсын әйдә – бәхте бар.
Бозмасын мәҗлес хозурын акчасы беткән кеше,
Измәсен яшьләрне дә күпдән яше үткән кеше!
*(«Картлар»)*

Ибне адәмме[3] түзәр, йирдә әгәр күрсә мәләк[4]?!
*(«Тәүбә вә истигъфар»)*

Бер сынык юкдан гына үлгән таза ирләр күреп,
Җан алырга кызганудан анда Газраил җылый.
*(«Күзге җилләр»)*

Бу бака, хәтта ки, «Йолдыз»дан да курка дип көләм!
*(««Йолдыз»дан да курка»)*

---

[1] *Биллаһ* – биллаһи – Алла белән ант итәм.
[2] *Сәкарьгә* – тәмугка.
[3] *Ибне адәмме* – адәм баласымы.
[4] *Мәләк* – фәрештә.

Ник агай мәсҗед эчендә юкка ирнен селкетә? –
«Пыш-пыш»ындан күршесе белсә укый дип, шул җитә.
*(«Дин вә гавам»)*

Барча кошның да үзенчә сайравы бар, шигъре бар.
Карга, мескин, җырлый белми, кычкыра тик «кар» да «кар!»
*(«Карга»)*

Үпкәнеңдән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә[1] син,
Һәр ишекдән сөрде углыңны мәхәббәт сакчысы.
Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, –
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!
*(«Өзелгән өмид»)*

Тиз югал, и Кыш бабай, син ал да тиз кач карт башың,
Барыбер күрсәң, качарсың, язны – гөлләр патшасын!
*(«Кышка бер сүз»)*

Бик тынычлап сайрагыз сез, мин тимим, сезгә тимим!
Әллә иркендә торуның нә кадрене белмимме мин?!
*(«Кошларга»)*

Кире төшде угы, Нәмрүд башына
Атып баккан иде Җибрилгә каршы.
Яһүдләр улды мәгъзуб[2] та кыямәт,
Карышып, күз йомып Инҗилгә каршы.
*(«Бер манигы тәрәккыйгә»)*

Син исә: «Эстәр исәң, җанымны бирермен», – дисең,
Нәрсәгә җаның миңа, нишлим синең җаным белән?
*(«Шиллердән»)*

Килешмидер: Коръән уку, тәсбих әйтү
Фәхеш-вәхшәт берлән тулган бер ханәдә!
*(«Дөньяда торыйммы? – дип киңәшләшкән дустыма»)*

Татар байы, никадәр тәрәккый кыйлса да, тәҗвидчелекдән уза алмый.

Халык яңа нәрсәнең кадрен белми! Өйрәнгән татар тол катынга!

Яңаларга тел тиермә, үз балаларың да шулай буласы!

---

[1] *Кәррә* – тапкыр.
[2] *Мәгъзуб* – ачуланылган зат.

Ач кеше вакытның соң икәнен белсә дә ята: «Торып нәрсә бар?» – ди. (Троицкидан Казанга Гыйльметдин Шәрәфкә язылган хаттан. 1912 ел, 11 июнь.)

Монтазам[1] булсынмыни соң гаскәрең,
Алгач үрнәккә Бохара гаскәрен!
*(««Кисекбаш»ка гыйлавә»)*
Китә рәхәт, «килә башлый» дигәнче.
*(«Шекспирдән»)*

Йөгерәләр аллы-артлы бер көтү
Кәкре койрыклар! – кая Башны җитү!
*(«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»)*

Көрәшмәк куркыныч: күп хәлләре бар,
Вәли, җиңгәч, ганимәт маллары[2] бар.
*(«Тормыш»)*

«Йөземләр чи, әле өлгермәгәнләр, пешмәгәнләр», – ди, –
Бозарсың ашказаныңны, килешми эчкә анлар!» – ди.
*(«Төлке һәм йөзем җимеше»)*

Әфкяре гомумия берлә уйнарга ярамый. *(«Тәнкыйть – кирәкле шәйдер»)*

Яшь балаларның иң мохтаҗ булдыклары нәрсә – ачык йөздер! *(«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» җыентыгының кереш сүзеннән)*

Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә ләтыйф булып, ялгыз гүзәл вә мөкаддәс нәрсәләрне генә сөючән булалар. *(«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» җыентыгының кереш сүзеннән)*

Һич гаҗәп юк, булса булыр, – бик калын, бик күп бит ул;
Күкдә ни булмас? – дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул!
*(«Шүрәле»)*

И җүләр! Кысканга былтыр, кычкыралармы быел?!
*(«Шүрәле»)*

---

[1] *Монтазам* – тәртипкә салынган.
[2] *Ганимәт маллары* – сугышта кулга төшерелгән дошман маллары.

Очды дөнья читлегендән тарсынып күңлем кошы,
Шад яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.
*(«Өзелгән өмид»)*

Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадрен белү?!
Без аны кайдан белик, мескин үлеп аңлатмагач?!
*(«Хөрмәтле Хөсәен ядкяре»)*

Шадыман ул мәркадеңдә[1]! – Без онытмыйбыз сине;
Белмәсәк вактында кадрен, инде котлыйбыз сине.
*(«Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә»)*

Гәрчә «үлде» дисәләр дә, син бөтенләй үлмәдең;
Яхшы исмең калды, син мәнси вә мәтрүк улмадың[2].
*(«Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә»)*

Шунда да исмең синең милләт яшәдекчә яшәр,
Милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар!
*(«Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә»)*

*Кереш мәкаләне һәм текстны басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәрләре Фәния Фәйзуллина,*
*филология фәннәре кандидаты Эльмера Галимҗанова әзерләде*

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ХАТЛАРЫ

Габдулла Тукайның эпистоляр мирасы шагыйрь тарафыннан язылган утыз дүрт хаттан гыйбарәт. Хронологик яктан алар 1903-1913 елларны үз эченә ала. Хатлар шагыйрь яшәгән, кунак булган, дәваланган төрле төбәкләрдән, шәһәр-авыллардан юлланган. Әлеге хатларның адресатлары арасында Тукайның туганнары (Саҗидә апасы, Газизә апасы, Абдуловлар), хезмәттәшләре, сыйныфташлары, якын дуслары да бар. Хатлар шагыйрьнең шәхесен, биографиясен, аның дөньяга карашын, иҗат юлын тулырак күзалларга шактый дәрәҗәдә ярдәм итә. Биредә Тукайның кешеләргә мөнәсәбәте, теләк-омтылышлары, эмоциональ кичерешләре, төрле буяуларга төрелмичә, ничек бар, шулай бирелә.

Тукай тарафыннан язылган хатлар, әлбәттә, күбрәк булган, әмма алар, кызганыч, төрле сәбәпләр аркасында безнең көннәргә килеп җитмәгән. Килеп җиткәннәренең дә шактый өлеше

[1] *Шадыман ул мәркадеңдә* – шат бул кабереңдә.
[2] *Мәнси вә мәтрүк улмадың* – онытылмадың, ташланмадың.

күчермәдә, төрле җыентыкларда, газета-журналларда дөнья күргән мәкаләләр эчендә, Тукай «Әсәрләр»ен туплаган томлыкларда сакланып калган.

Бүген, кулга алып карардай, шагыйрьнең үз кулы белән язган, төп нөсхә дип исәпләнгән сигез хаты Казанда: җидесе Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, берсе Казан (Идел буе) федераль университеты Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапхәнәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

Биредә Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклanучы Г. Тукайның җиде хатының, гамәлдәге татар язуына күчерелгән тексты (факсимилесе белән) бирелде, аларга искәрмә һәм аңлатмалар язылды. Хатлар хәзерге татар теле орфографиясе кагыйдәләренә туры китерелеп тәкъдим ителә. Тыныш билгеләре безнең тараф-тан куелды.



Г. Тукайның 1903 елның 30 июнендә апасы Сәҗидәгә язган хаты // ЯһММҮ. 9 ф., 2 тасв., 10 с.б.

## Апасы Сажидәгә

[Уральскидан Каенсарга]

30 нчы июнь, 1903 сәнаи миладия[1+].

Биисми Габдулла бине Мөхәммәдгариф Тукаев.

Фөтүвәтле вә сәгадәтле жизнәмез[2+] илән миһербанә вә мөшфика Сажидә апайга[3+] биниһая догаи-сәламләремне васил вә мөтәвасил әйләдем. Кәзалик мөгаззәзә вә мөхтәрәмә сеңлемез Бибимәсрүрә[4+] илән энемез Габделвәһһабка[5+] бездән күп-күп дога вә сәлам диеңез. Вә дәхи хөрмәтле атамыз бәрабәрендә улан бабамызга[6+], әһлияи мөхтәрәмәләрене шамилән, биниһая дога вә сәлам дидем[1]. Сез туганымның йибәргән эманәт вә хатларыңызи ушбу үткән кышта алдым. Үзем йоклаган вакытта, баш очыма куеп киткән. Торып карасам, бер савыт манпаси һәм какъ тора. Соңра какыңыздан һәр апаларыма өлеш чыгардым. Бик рәхмәт укыдылар. Бу эманәтләрне биреп киткән кешене таба алмадым. Зинһар, гаеп итмәңез. Иншалла, мондин ары һаман хәбәрләшеп торырмыз. Үзем әлхаль[2] мәдрәсәдә таләбе голүмдәмен[3]. Дәресем «Шәрхе мелла»дыр[7+]. Кадәре халь сарфы ижтиһад идәмез[4]. Һәрничек хәер-фатихада булышаек. Сездән янә бер илтимасым[5] бар: Сез, җизнәңнән күп сәлам, дип язасыз. Ләкин җизнәм нә исемдә вә кайда тәхсиле голүм иткән[6] – шулары бәңа бик мәҗһүлдер[7]. Мөмкин булса, хат язганда мәгълүм итеңез. Бервакыт, Кырлайдан Өчилегә җыенга килгән вакытымда[8+], бабайларда җизнәмнең яңа кияү вакыты иде. Исеңездәме, мин икеңезнең хәлвәт бүлмәсенә[8] кереп чәй эчтем, әмма яшьлегемнән бернәрсә фәһемләмәдем[9]. Мөшфика[10] апаем! Синең сабый вакытта һәм хәзер дә иткән изгелекләреңне кабердә ятсам да, онытмам. Анам дарелбәкайә

---

[1] Габдулла Мөхәммәтгариф Тукаев исеме белән.

Киң күңелле һәм изгелекле җизнәбез белән йомшак күңелле һәм шәфкатьле Сажидә апайга чиксез күп теләк һәм сәламнәремне ирештердем. Шулай ук кадерле һәм хөрмәтле сеңлебез Бибимәсрүрә белән энебез Габделвәһһабка бездән күп-күп теләк һәм сәлам диегез, һәм тагын хөрмәтле атабыз урынында булган бабабызга, хөрмәтле гаиләләрен дә кертеп, чиксез күп теләк һәм сәлам дидем.

[2] *Әлхаль* – хәзерге көндә.

[3] *Таләбе голүмдәмен* – гыйлем алам, укыйм.

[4] *Кадәре халь сарфы ижтиһад идәмез* – хәлдән килгәнчә тырышабыз.

[5] *Илтимасым* – үтенечем.

[6] *Тәхсиле голүм иткән* – укыган, белем алган.

[7] *Мәҗһүл* – билгесез, мәгълүм түгел.

[8] *Хәлвәт бүлмәсенә* – кияү белән кыз ялгыз кала торган бүлмәгә.

[9] *Фәһемләмәдем* – аңышмадым.

[10] *Мөшфика* – шәфкатьле.

рихләт иткәч[1], бабайлар өендә бәңа мәрхәмәт күзе илән караучы юк иде, мәгәр син бар идең.

[...] дия золым-җәберләренең җәрәхәте җәннәте гаденгә[2] керсәм дә, йөрәгемнән китмәс. [...] ... ләр дә шуның тәвабигыннан[3] иде [...] ... дөрестен әйтеңез. [...] хәзер ничек тора, һәм ул[9+] да Саҗидә апай илән бер атадан, бер анадан туганмы? Йә булмаса ул [мыеклы әбидән туганмы?[10+]][4]

Хәзер дә атам-анама һаман Коръән укып торам, мәүлам кабул итсен. Бу үткән кышта Кырлайдагы анам[11+] да кура җиләге кагы йибәргән иде. Атам[12+] бер елдан бирле авыртулә[5] ята икән. Сезнең йибәргән чиккән аяк чолгавыңызны, апай төсе дип, кадерләп кенә тотамын. Үзем дә хәзер тәмам мөстәкыйль булдым. Бүләкләр йибәргәләрмен. Хәзер бу җулы йибәрә алмадым, зинһар, рәнҗи күрмәңез. Язачак сүзләрем күп иде, икътисар иттем[6]. Мондагы апаларым барчасы сәламәтләр. Сезнең догаларыңызны үтенеп, сәлам диделәр. Бик ашыгыч яздым.

Хәерле гомерләреңезне теләп язгучы талибел-гыйлем[7] Габдулла.

1+ *...сәнаи миладия* – Гайсә пәйгамбәрнең туган көненнән алып исәпләнгән, хәзер гамәлдә булган ел хисабы.

2+ *...җизнәмез...* – Әхмәтсафа Зариф улы Хәбибуллин (1864–1937).

3+ *...Саҗидә апайга* – Бибисаҗидә Зиннәтулла кызы Әмировага (Хәбибуллинага) (1877–1956).

4+ *Бибимәсрүрә* – Бибимәсрүрә Әхмәтсафа кызы Хәбибуллина (1900–1981).

5+ *Габделвәһһаб* – Габделвәһһаб Әхмәтсафа улы Хәбибуллин (1896 – ?).

6+ *бабамыз* – Зиннәтулла Зәйнелбәшир улы Әмиров (1829–1909).

7+ *«Шәрхе мелла»* – гарәп грамматикасыннан дәреслек.

8+ *Кырлайдан Өчилегә җыенга килгән вакытымда* – Тукайның Өчилегә җыенга баруы 1894 елның җәендә була.

9+ *ул* – Гөлчәһрә апасы.

10+ *...мыеклы әбидән туганмы?* – Әмиров Зиннәтулланың беренче хатыны Камиләдән туганмы?

11+ *...Кырлайдагы анам...* – Кырлайга Габдулланы тәрбиягә алган Салихов Сәгъдетдин Шәмсетдин улының (1837–1904) хатыны Салихова Бибизөһрә Габделгани кызы.

12+ *Атам...* – Яңа Кырлайдан Салихов Сәгъдетдин Шәмсетдин улы (1837–1904).

---

[1] *Дарелбәкайә рихләт иткәч* – үлгәч.

[2] *Җәннәте гаденгә* – оҗмахка.

[3] *Тәвабигыннан* – иярчененнән.

[4] Квадрат җәяләр эчендә бирелгән сүзләрне бүгенге көндә, кульязмадан уку мөмкин түгел. Алар элекеге басмалардан алынып бирелде.

[5] *Авыртулә* – авырту илә.

[6] *Икътисар иттем* – кыскарттым.

[7] *Талибел-гыйлем* – гыйлем эстәүче, укучы.



عبدالله توقایف

А. М.-Г. Тукаевъ

فاتح افندی! سلام کابچنو.

Г. Тукайның 1908 елның 23 июнендә Фатих Әмирханга язган хаты // ЯһММҮ. 9 ф., 2 тасв., 1 с.б.

## Фатих Әмирханга

[Казаннан Серноводскига]

Фатих әфәнде! Сәлам, конечно.

Хатыгызны алдым. «Әлислах»да «Кызык гыйшык»[1+] шигырен яраттыңызмы? Керпе үзенең кабыгына кереп яшеренгән төсле, мин дә сөю хакында бер нәрсә язсам, ялган имзалар астына сыгынам. Язам шунда. Үзем хәзер бернәрсәне дә, беркемне дә сөймим. Күңел эчү белән тәмам бозылган.

Уянды хандра[1] күңелемдә инде,
Караңгылык күңелдә нурны җинде!

Торам, торам да: «Йа Рабби! Ятимлекләр, фәкыйрьлекләр, ачлыклар, авылдан-авылга сатылып йөрүләр, рәхимсез татар байларында хезмәт итүләр, татар мәдрәсәсендә черүләр арасында да

[1] «Хандра» сүзе җәяләр эчендә рус хәрефләре белән язылган.

саклап килдекем истигъдад[1] очкыны шушы исереклекләр, исерек иптәшләр арасында бер дә кабынмаслык булып сүнәрмени инде?» – дим.

Тәмам бер сәнә җон агызып йөрим бит![2+]

Бу хәл туйдырды инде тәмам. Оренбургка Фатих Кәримев[3+] чакырган иде. Анда барсам, бәлки, үземә мөгайян[2] эш булуы һәм серьёзный кешеләр тирәсе файдалы булыр иде, дим. Нишлим? Барыйм микән?

Монда «Әлислах» ходка китсә, көлке журналы да чыкса[4+], үземнең кальбән[3] сөйгән гәзитә вә идеямә хезмәт итәр идем. Ләкин бу да бәгыйд[4]. Шушы минем кайгым тугрысында бер-ике юл языңыз әле. Һаман үземне генә сөйлим икән. Сезнең кәефләр нәсыл[5], әфәндем? Анда баргач, тәәссереңез ничек булды? «В.-К.»[5+]да «Татарин» имзалы бер зат теге Касыйм Уралецка җавап язды[6+]. Сезгә кирәк булса, шул номер гәзитәне йибәрермен.

Монда хосусый минем хәл искечә. Көндез «Ислах» идарәсенә[7+] барып утырам. Кич «Швейцария»[8+], «Аркадия»[9+], «Панаевский»[10+]-ларга барам. Мин әле кая барам.

Соңгы номерга бернәрсә дә яза алмадым. Бик озын бер хат языңыз әле[11+], зинһар.

Г. Тукаев
23 июнь, 1908

1+ *«Кызык гыйшык»* – Тукайның 1908 елның 12 июнендә язылган бу шигыре «Әлислах» газетасының 1908 елгы 17 июнь (34) санында «Мәҗнүн» имзасы белән басылган. Шигырь шагыйрьнең Зәйтүнә Мәүлүдовага булган мөхәббәте тәэсирендә иҗат ителә. Тукай бу шигырен 1908 елның 11 октябрендә Купеческое собрание залына (хәзерге Островский урамындагы Яшь тамашачылар театры бинасы) җыелган яшьләр әдәби кичәсендә сәхнәгә чыгып укый.

2+ *...җон агызып йөрим бит!* – «җон агызу» – «юкка йөрү» мәгънәсендә. Әлеге образ-гыйбарә Тукай тарафыннан С. Рәмиевнең «Алданган» шигыренә пародия рәвешендә язылган «Саташкан» шигырендә («Әлислах». 1908 ел, 19 май) дә кулланыла.

3+ *Фатих Кәримев* – Фатих Гыйльман улы Кәримов (1870–1937), язучы, нашир, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе.

4+ *...көлке журналы да чыкса...* – биредә сүз «Яшен» журналы турында бара. Әлеге сатирик, юмористик журнал 1908 елның августыннан 1909 елның

---

[1] *Истигъдад* – талант.
[2] *Мөгайян* – билгеләнгән.
[3] *Кальбән* – чын күңелдән.
[4] *Бәгыйд* – ерак.
[5] *Нәсыл* – ничек.

24 июненә кадәр Казанда татар телендә (10 сан) нәшер ителә. Журналны оештыруда Г. Тукай белән Ф. Әмирхан да катнашкан.

5+ *«В.-К»* – «Волжско-Камская речь» («Идел-Кама сүзе») Казанда 1907–1908 елларда рус телендә чыккан иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Нашире – Н.П. Гусев, мөхәррире – Н.А. Скворцов.

6+ *...«Татарин» имзалы бер зат теге Касыйм Уралецка җавап язды* – биредә сүз «Волжско-Камская речь» газетасының 1908 елгы 21 май санында «А.П.-ч» имзасы (А. Пинкевич) белән «Яңа татар әдәбияты турында очерклар» дигән мәкалә басылуы һәм шул мәкаләдә язылган кайбер фикерләр тирәсендә туган бәхәс турында бара. А. Пинкевич әлеге мәкаләсендә татар әдәбияты вәгазьчелек, моралистлык рәвешен алды, дип билгели. Аның фикеренчә М. Гафури – коеп куйган үгет-нәсыйхәтче, Тукайда бераз гына чын поэзия үрнәкләре очраса да, аны да дидактизм биләп алган. Бары тик Сәгыйть Рәмиев шигърияте генә әлеге кимчелекләрдән азат, дип белдерә.

«Волжский листок» газетасының 1908 елгы 10 июнь (696) санында Касыйм Уралецның «О татарских поэтах» («Татар шагыйрьләре турында») исемле мәкаләсе басылып чыга. Биредә ул А. Пинкевич белән бәхәскә керә. Ләкин Тукайны мәкалә авторы урам теле белән язуда гаепли, аны тәрҗемәче дип атый. Татарда бердәнбер шагыйрь – М. Гафури, дип саный.

«Волжско-Камская речь» газетасының 1908 елгы 18 июнь санында «Татарин» имзалы берәү Касыйм Уралецка җавап яза. Биредә мәкалә авторы Уралецны, шигъриятьне, гомумән татар әдәбиятын аңламауда тәнкыйтьли.

Ф. Әмирхан А. Пинкевич, Касыйм Уралец мәкаләләре белән танышканнан соң «Әлислах» газетасының 1908 елгы 13 июль (37) санында «Татар шагыйрьләре» дип аталган мәкаләсен бастыра. Биредә Әмирхан Тукайның вәгазьче түгеллеген, ә чын шагыйрь икәнлеген исбатлый.

7+ *«Ислах» идарәсенә* – «Әлислах» газетасы идарәсенә.

8+ *«Швейцария»* – «Швейцария» бакчасы. Хәзерге М. Горький исемендәге ял итү паркы урынында була.

9+ *«Аркадия»* – «Аркадия» бакчасы. Кабан күле буенда 1895 елда нигез салына. Заманасында Казан халкының яраткан ял итү урыны.

10+ *«Панаевский»* – «Панаев» бакчасы. Казанда хәзерге М. Горький урамында урнашкан «Динамо» стадионы урынында була. Биредә революциягә кадәр сәүдәгәр Панаевлар гаиләсе яшәгән һәм халык арасында популяр булган җәйге театр урнашкан.

11+ *Бик озын бер хат языңыз әле* – Ф. Әмирханның мондый хатны язуы мәгълүм түгел.

## Камалетдин Хисаметдиневкә

[Казаннан Уральскига]

Борадәр[1] Кәмалетдин әфәнде[1+]!

Һәр өч хатыңны да алдым[2+]. Җавап язмаганым өчен гафу итәсез. Чөнки һичкемнең хатына да каршы җавап язмыйм. Әллә нигә ялкауландым. Хәзер бер җирдән дә хат килми. Барысы да миннән җавап булмаганга тукталдылар.

---

[1] *Борадәр* – ир туган.




Г. Тукайның 1910 елның 25 сентябрендә Кәмалетдин Хисаметдиневкә язган хаты // ЯһММҮ. 9 ф., 2 тасв., 15 с.б.

Хатыңны «Юл» көтепханәсенә[3+] күрсәттем. «Дөруссеш шифаһия»нең[4+] ничәнче җөзьәләрен[1] һәм нәхүнең[2] нинди нәхү вә кем тәэлифе[3] икәнлеген аерым язуыңызны үтенәләр. Дәфтәрдә, чынлап та, җибәргән акча вә маркаларыңыз күренми.

Шулай да, хат язып, нәрсә вә ни сумага китап сораганыңызны язсаңыз, Сезгә ышанып китаплар җибәрелер.

Бакый ихтирам Г. Тукаев
25 сентябрь, 1910

1+ *Кәмалетдин әфәнде* – Кәмалетдин Бәдретдин улы Хисаметдинов (1882–1966), Кушлавыч авылы крестьяны Бәдретдин Хисаметдиновның улы. Революциягә кадәр вак сәүдәгәр булган.

2+ *Өч хатыңны алдым* – К. Хисаметдинов хатлары сакланмаган.

3+ *«Юл» көтепханәсе* – «Юл» китап нәшрияты – Казанда 1907 елдан алып 1918 елга кадәр эшләп килгән нәшрият. Оештыручысы – Әхмәт Урманчиев (1880–1922). Нигездә матур әдәбият әсәрләре бастыру белән шөгыльләнгән. «Ялт-йолт» (1910–1918) журналы да әлеге нәшриятта чыккан.

4+ *«Дөруссеш шифаһия»* – гарәп телендә язылган берничә томлы «Тел дәресләре» китабы.

## Сәгыйть Сүнчәләйгә

[Казаннан]

Мелла Сәгыйд! Бу хат белән теге, вәгъдә иткәнем Садриның ачык хатын[1+] җибәрәм. «Шура»да һәм «Идел»дәге «Мөселманство»ны[4] яклаган мәкаләләреңне укыдым[2+]. Балаларга ярдәмгә

---

[1] *Җөзьәләрен* – бүлекләрен.
[2] *Нәхүнең* – синтаксисның.
[3] *Кем тәэлифе* – язучысы кем.
[4] *Мөселманство* – монда: мусульманство.



Г. Тукайның 1911 елның 20 октябрендә Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хаты // ЯhММҮ. 9 ф., 2 тасв., 8 с.б.

килүем тугрысындагы дөрест фикереңә тәхсин[1]. Бүген сигезенче көн инде, авыруым килми. Авыруына кайгырмаганым шикелле, сәламәтләнүенә дә куанмыйм. Барыбер. М.-гә[3+] мин, әлбәттә, яхшы тәэсир калдыргганмындыр. Чөнки аның алдында мин һаман көлдергечлек ролен уйнадым. Һәм аның безнең Казанның бәгъзе интеллигентларыннан аерым булуына вә укып та чукынмаганлыгына[4+], һаман татар булып калуына таянып, аннан бер дә тартынмыйча, алдына рухымны ачып салдым.

«Мөселманство»[5+] һәм «Мөселманин»[2] кешеләре хакында монда төрле сүзләр сөйләнгәнгә генә тәвәкъкыф итәм[3]. Югыйсә, миндә «Мөселманство»ның татарчасына бастырырга шигырьләр[4] бар.

Син аларны кемнәр дип танийсың? М.[5] ул кавказлыларга алданып йөрми микән?[6+]

Мин хәзергә шул кадәр генә язам. Вакытым аз.

Бакый[6] сәлам вә ихтирам.

Г. Тукаев
1911. 20 октябрь

[1] *Тәхсин* – рәхмәт.
[2] *Мөселманин* – монда: мусульманин.
[3] *Тәвәкъкыф итәм* – тукталып торам.
[4] Моннан соңгы «табылыр һәм» сүзләре сызылган.
[5] М. хәрефе астындагы «Мирсаяф» сүзе сызылган.
[6] *Бакый* – мәңгелек.

1+ *Садриның ачык хатын...* – биредә сүз Садри Максудиның «Йолдыз» газетасының 1911 елгы 10 март санында дөнья күргән «Дәүләт Думасының 26 нчы февраль мәҗлесендә Садри әфәнде Максудов җәнаблары ирад иткән[1] нотык» исемле язмасы турында бара булса кирәк.

2+ *...мәкаләләреңне укыдым* – «Шура» журналының 1911 елгы 18 нче (15 сентябрь) санында С. Сүнчәләйнең «Мияубикә» исемле мәкаләсе, «Идел» газетасының шул ук елгы 19 октябрь санында «Мусульманин» журналы» дигән кечкенә мәкаләсе басыла. «Идел»дәге мәкаләсендә Парижда чыккан «Мусульманин» журналының финанс хәле начарлануы, тукталу алдында торуы хакында язып, хәлле кешеләрдән аңа ярдәм оештыруны, абүнәчеләр җыюны үтенә.

3+ *М.* – Хатның кульъязмасында башта «Мирсәяф» дип куелган. Аннары сызылып, «М.» хәрефе генә калдырылган. Биредә сүз шагыйрь, тәрҗемәче Мирсәяф Кырымбаев турында бара. Ул 1908–1910 елларда «Мусульманин» журналының секретаре булып эшләгән.

4+ *...укып та чукынмаганлыгына...* – бу очракта Тукай татар халкында яшәп килгән «укыган кеше – чукынган кеше» мәкаленә каршы фикер белдерә.

5+ *«Мөселманство»* – «В мире мусульманства» («Мөселманнар дөньясында»), 1911 елның 3 апреленнән 1912 елның 20 апреленә кадәр Петербург шәһәрендә рус телендә нәшер ителгән атналык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Барлыгы 44 саны дөнья күрә. «Мусульманин» журналының дәвамы. Наширләре һәм мөхәррирләре М. Хаҗи Теләши һәм Арслангәрәй Датиев.

6+ *...кавказлыларга алданып йөрми микән?* – Тукай, кавказлылар дип, М. Хаҗи Теләши һәм А. Датиевларны атый булса кирәк.

## Фатих Әмирханга

[Казан. Клячкин шифаханәсеннән]

Фатих!

Мәкаләне бик сирәк нәрсәне баскан кеби зурлап бaскансыз[1+]. Рәхмәт. Тагы да язмый булмас, ахры, дип торам әле.

Хәтереңдә булса, Шиһаб хәзрәтнең әллә кайсы гарәб шагыйреннән алып, «Болгар» манарасына язган бәетен[2+] язып җибәр әле. Хәзер үк.

«Кояш»[3+] тәртипсез килә. Соң килә. 72 нче номер бер көндә өчәү килде. Бу көнге номер икәү килде. 73 не исә бөтенләй күргәнем юк. Зинһар, хәзер бер номерын йибәрсәгез лә! Зәкәрия абзыйга[4+] сәлам.

Бәндәгез Тукай

1913 сәнә, 18 март

1+ *Мәкаләне ... баскансыз* – биредә сүз Тукайның «Уянгач беренче эшем» исемле мәкаләсе турында бара. Ул «Кояш» газетасының 1913 елгы 18 март (74)

---

[1] *Ирад иткән* – монда: сөйләгән.

санында «Габдулла Тукаев, Клячкин шифаханәсе, 14 март, 1913 сәнә» дигән язу белән басылган.

2+ *Шиһаб хәзрәтнең ... Болгар манарасына язган бәетен* – биредә сүз тарихчы, илаһият галиме, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) 1870 елда борынгы Болгар шәһәренә барып, шунда сакланган манарага язып калдырган гарәп телендәге шигыре турында бара. Соңыннан ул шигырьнең текстын Ш. Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел әхбар...» исемле хезмәтендә бастырып чыгара. Тукай хатында Фатих Әмирханнан әлеге шигырьне сорый.

3+ *«Кояш»* – 1912 елның 10 декабреннән алып 1918 елның 29 мартына кадәр Казанда татар телендә нәшер ителгән көндәлек газета. Наширләре – бертуган Кәримевлар, мөхәррире – З. Садретдинов. Газетада Ф. Әмирхан, Г. Тукай, И. Бикколов һ.б.ның әсәрләре басылган.

4+ *Зәкәрия абзыйга* – Зәкәрия Садретдин улы Садретдинов (1880–1930), педагог, журналист. Ул чорда «Кояш» газетасының мөхәррире.



Г. Тукайның 1913 елның 18 мартында Фатих Әмирханга язган хаты // ЯһММҮ. 9 ф., 2 тасв., 5 с.б.

## Әхмәтгәрәй Хәсәнигә

[Казан. Клячкин шифаханәсеннән]

Мөхтәрәм Гәрәй әфәнде![1+]

«Бер мөхәрриргә»[2+] шигыремдә «Аң»га лаек дәрәҗәдә үк нәфасәт[1] күрмәгәнемә күрә, «Мәктәб» журналына бирдем. Анда да ул шигырьне баш сәхифәгә керттермәдем[3+]. Ахырда вә незаметныйрак җирдә китәчәк. 7 нче санда минем шигырь бик аз вә кешегә сизелерлек аз кергән[4+]. Өстәп йибәрергә бер нәрсәм бар иде. Инде, әлбәттә, соңдыр. Иншалла, 8 нчедән дә гафил калмам[5+]. Бер шәй язармын. Шулай да 7 нчегә өстәргә материал алып китсәң, ярыйдыр иде. Көн дә сине көттем. Хәер ул.

Г. Тукай

1913 сәнә, 20 март

---

[1] *Нәфасәт* – матурлык, гүзәллек.



محترم گرای افندی!

۲۰ مارت ۱۹۱۳

Г. Тукайның 1913 елның 20 мартында Әхмәтгәрәй Хәсәнигә язган хаты // ЯhММҮ. 9 ф., 2 тасв., 17 с.б.

1+ *Мөхтәрәм Гәрәй әфәнде!* – Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәни (Хәсәнев) (1883–1934), нашир, әдип, журналист, тәрҗемәче. «Гасыр» нәшриятын (1907–1921) оештыручылардан, «Яңа китап» нәшриятының (1926–1929) җитәкчесе. 1912–1918 елларда «Аң» журналының нашире һәм мөхәррире.

3+ *...баш сәхифәгә керттермәдем* – Тукайның бу шигыре «Кыйтга» исеме белән журналның 77 нче битенә урнаштырылган. Ә ул вакытта журналлар үз саннарының беренче битен Тукай шигырьләре белән ача торган булганнар.

4+ *...кешегә сизелерлек аз кергән* – «Аң» журналының 1913 елгы 7 нче (15 март) санында Тукайның «Тәфсирме? Тәрҗемәме», «Толстой сүзе (Кирәк анчак...)» исемле ике шигыре басылган.

5+ *Иншалла, 8 нчедән дә гафил калмам* – «Аң» журналының бу 8 нче (10 апрель) саны Тукай үлгәч басылып чыга. Биредә шагыйрьнең «Толстой сүзләре», «Буш вакыт», «Мәктәп» исемле шигырьләре «Мәрхүм Габдулла Тукаевның иң соңгы шигырьләре» дип тәкъдим ителә.

**Зәйнәб Хәсәниягә**

[Казан. Клячкин шифаханәсеннән]

Мөхтәрәмә Зәйнәб ханым![1+]

8 нче санга бар кадәремне җибәрдем. Беренче корректурын үземә күрсәтсәңез икән. Андан соң шушы язылган микъдар шигырьнең һәммәсе бер номерга кереп бетсә иде. Шулай булганда, ул шактый көч булырлык. Хәер, «Толстой сүзләре»нең бер-икесен цензор бозар кеби сизәм[2+]. Ул вакыт һәммәсен[1] басылуы мәҗбүри үк булыр.

Г. Тукаев
1913, 28 март



Г. Тукайның 1913 елның 28 мартында Зәйнәп Хәсәниягә язган хаты // ЯһММҮ. 9 ф., 1 тасв., 8 с.б.

1+ *Зәйнәб ханым!* – Зәйнәп Хәсәния (1888–1967) Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәнинең (1883–1934) хатыны.

2+ *...цензор бозар кеби сизәм* – «Аң» журналының 8 нче санында басылган «Толстой сүзләре» цензор тарафыннан киселми.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙГА ЯЗЫЛГАН ХАТЛАР

Бүгенге көндә Тукайга язылган хатларның бары тик ике нөсхәсе генә безгә мәгълүм. Болар – шагыйрь белән аралашкан журналист, педагог Кәрим Сәгыйтьнең һәм «Аң» журналы мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәнинең хатлары.

Беренче хат Кәрим Сәгыйтьнең кызы Энҗе Сәгыйтова тарафыннан, этисе архивыннан табылып, басмага әзерләнә һәм беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1970 елгы 1 нче санында «Тукайның ике җыентыгы» исемле мәкалә эчендә басылып чыга.

---

[1] *Һәммәсен* – монда: һәммәсенең.

Э. Сәгыйтова мәгълүматларына караганда кульъязмада хатның датасы куелмаган. Чама белән 1912 елның ахыры – 1913 елның башы дип бирелә. Хат 21×26 см зурлыктагы икегә бөкләгән кәгазь битенә, гади кара карандаш белән язылган. Сул яктан битнең югары почмагы азрак ертылган. Бүгенге көндә әлеге кульъязманың язмышы билгесез. Хат тексты «Казан утлары» журналыннан алынды.

Икенче хатның төп нөсхәсе Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, Тукай фондында саклана (9 ф., 2 тасв., 17 с.б.). Язманың икенче ягында Тукайның Ә. Хәсәнигә язган хаты урын алган.

Текст төп нөсхәдән алынды.

## Кәрим Сәгыйтьнең Тукайга язган хаты

1912 елның ахыры – 1913 елның башлары
Петербургтан Казанга

Тукай!

Мин соңгы көннәрдә «Җан азыклары» дигән соңгы шигыреңне[1+] кулга төшереп укып чыктым. Моңа кадәр әсәрләрең арасында «Халык әдәбияты»[2+] дигәнен бигрәк тә тәкъдир иткән идем. Инде бу «Җан азыклары» минем сиңа булган өметемне арттыра гына түгел, көткәнемне тәкмил итәр[1] дәрәҗәсенә җитештерде. Алты юлдан гыйбарәт «Тәләһһеф»[3+] ниһаять фәсыйх[2] вә балигъ[3], чын ихласыңнан әйтелгән дөрес шигырь. Фәкать уртадагы ике юлы, астагы һәм өстәге дүрт юлның шәрхе булганга (шөбһә юк, гөл исә дә), аны үзегез әйтмәенчә, шәрехләргә калдырсагыз, артыграк булачак иде дип, зан итәмен[4]. «Тәләһһеф»нең соңгы ике юлы бигрәк фәсыйх, тәркиби дөрес[5], пакъ, мәгънәсе бөектер.

«Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылып чүпләрем»[4+] дип, нигә һазмы нәфес итәсең[6]? Бакчабызда чүп-чар булмыймыни?

«Мин үлгәчтен, карагыз, типмәсеннәр нәгъшемә[7]»[5+], – дигән васыятеңне, Иншаллаһ, онытмамын. Дошманнар, нәгъшеңә тибү

---

[1] *Тәкмил итү* – монда: канәгатьләндерү.
[2] *Фәсыйх* – матур һәм килешле.
[3] *Балигъ* – кимчелексез, тулы.
[4] *Зан итү* – уйлау.
[5] *Тәркиби дөрес* – төзелеш ягыннан дөрес.
[6] *Һазмы нәфес итәсең* – монда: үз-үзеңне битәрлисең.
[7] *Нәгъшемә* –мәетемә.

түгел, тәкъдис итәргә[1] мәҗбүр булырлар дип, зан итәмен. Ләкин «дөньядан туйдым, өметем юк», дигән яңа сүзләреңне мине кайгырталар. Соңгы хасталыкларың шулай әйттергәндер дип уйлыйм.

«Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна»[6+] дип, җитмәсә тагын күңелне бутыйсың.

«Сагыныр вакытлар»[7+] дигәндә син ник үзеңне иблискә тәшбиһ итәсең[2]?

«Күзге җилләр»[8+] өчен мин сине адәм дип кенә түгел, Ходаның иң сөекле адәме дип тәкъдир итәм.

«Йолдыз»дан куркучы авыл татары – бака[9+], бу – бик удачно.

«Буран»[10+]: «Йә тишелгәнме Ходайның бихисап зур мендәре» – бу җөмләгә татарлар һич риза булмаслар дип зан итәм.

Минем бу сүземә «Мөнәкъкыйд»[11+] дигән ачы хакыйкатьле шигырьләреңне җырлап җавап бирмә. Ачуны китермә.

«Һич берәүнең дә чәчәккә инде китмәс исләре»[12+], дигәндә «берәү» мөфрәт сыйгасы[3] булып, аның мөзафи[4] булган «исләре» сүзе җәмегъ сыйгасы[5] булуга мин гаҗәпсендем. «Минем исләрем китте» дигән сүз хата бит, минем исем китте, диләр.

Бу сүзләрем өчен мине «Бу хаким ишәк, мәхәббәтсез килемшәк[6] икән»[13+] дип сүкмә. Хәер, ихтыярың»[7].

1+ *«Җан азыклары» дигән соңгы шигыреңне* – биредә сүз Г. Тукайның «Җан азыклары» исемле соңгы шигырь мәҗмугасы турында бара. Җыентык 1912 елның декабрь аенда Казанда басылып чыга.

2+ *«Халык әдәбияты»* – Г. Тукайның халык әдәбияты турында «Шәрык» клубында укыган лекциясе. 1910 елны Казандагы «Сабах» нәшриятында аерым китап булып басылып чыга.

3+ *«Тәләһһеф»* – Г. Тукайның «Буби»лар вакыйгасы уңае белән язылган шигыре. Беренче тапкыр «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 18 нче (1 декабрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Соңрак «Җан азыклары» (1912) җыентыгына да кертелә.

4+ *«Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылып чүпләрем»* – «Җан азыклары» (1912) мәҗугасында басылган «Үтенеч» шигыренең азаккы юлы.

5+ *«Мин үлгәчтен, карагыз, типмәсеннәр нәгъшемә»* – «Җан азыклары» (1912) мәҗмугасында басылган «Дошманнар» шигыреннән бер юл.

---

[1] *Тәкдис итәргә* – изге санарга.

[2] *Тәшбиһ итәсең* – охшатасың.

[3] *Мөфрәт сыйгасы* – берлек формасы.

[4] *Мөзафи* – кушылган, арттырылган.

[5] *Җәмегъ сыйгасы* – күплек формасы.

[6] Килмешәк булырга тиеш булса да, чыганакта «килемшәк» дип бирелгән.

[7] Соңгы ике юллык абзац кульязмада җиңелчә сызылган, ләкин укырлык. – *Э. Сәгыйтова иск.*

6+ *«Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна»* – «Җан азыклары» (1912) мәҗмугасында басылган «Дошманнар» шигыреннән бер юл.

7+ *«Сагыныр вакытлар»* – Г.Тукайның беренче мәртәбә «Җан азыклары» (1912) җыентыгында басылган шигыре.

8+ *«Көзге җилләр»* – Г. Тукайның 1910–1911 елларда Урта Иделдәге ачлык фаҗигаләре тәэсире белән 1911 елның 13 ноябрендә язган әсәре. Беренче тапкыр «Йолдыз» газетасының 1911 елгы 18 ноябрь (758 нче) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган.

9+ *«Йолдыз»дан куркучы авыл татары – бака* – биредә сүз Г. Тукайның «Йолдыз»дан да курка» исемле шигырендәге юллар турында бара. Шигырь беренче тапкыр «Җан азыклары» (1912) җыентыгында басыла.

10+ *«Буран»* – шигырь беренче тапкыр «Җан азыклары» (1912) җыентыгында басылган.

11+ *«Мөнәкъкыйд»* – биредә Г. Тукайның беренче тапкыр «Җан азыклары» (1912) җыентыгында басылып чыккан «Мөнтәкыйд» исемле шигыре турында бара.

12+ *«Һич берәүнең дә чәчәккә инде китмәс исләре»* – беренче тапкыр «Җан азыклары» (1912) исемле җыентыкта урын алган «Интикадка мөтәгалликъ» исемле шигырьдән юллар.

13+ *«Бу хаким ишәк, мәхәббәтсез килемшәк икән»* – бу юллар Тукайның «Интикадка мөтәгалликъ» (1912) шигыреннән бераз үзгәртелеп алынган, оригиналда:

Тик китә кайчакта кәйфең, хакимең булса ишәк,
Бер татарга ят, мәхәббәтсез күсәк һәм килмешәк!

**Мөхтәрәм Габдулла әфәнде!**

Мин ун көнгә Мәскәүгә сәфәр иттем. Сезнең янга барырга вакытым булмады. «Аң»ның 8 нче санына кертү өчен «Бер мөхәрриргә» исемле шигыреңезне бирергә вәгъдә иткән идеңез. Шуны бу записка белән барган әфәндегә биреп җибәрсәң, мәмнүн булыр идем[1]. Әлегә хушың. Шигырьнең төп язмасын җибәрдем.

Ихтирам илә, Әхмәтгәрәй Хәсәни
20 март, 1913 ел

*Искәрмә һәм аңлатмаларны, хат текстларын басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре*
*Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

*Фитрәттә гали булган ул...*

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ФОНДЫНДА САКЛАНА ТОРГАН МАТЕРИАЛЛАРНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ

Габдулла Тукай фонды (9 нчы фонд). Әлеге фонд бүгенге көндә Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. Ул дүрт тасвирламадан гыйбарәт.

Г. Тукайның тормышына һәм иҗатына кагылышлы документлар, шагыйрьнең автографлары, аның турында истәлекләр 1939 елда Казанда Татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү фәнни-тикшеренү институтында җыела башлый. 1940 елның маенда шагыйрьнең 1913 елның 28 мартында язылган автограф хаты һәм тагын ике автограф язмасы тапшырыла, ләкин аларның кемнән керүләре мәгълүм түгел (билгесез кешедән 200 сумга сатып алынган). Июль аенда Тукайның ике хаты автографы 200 сумга сатып алынган. Бу елда шулай ук Г. Тукай замандашларыннан Шәриф Каюмов, Миргазиз Укмасый, Фатыйма Бәхтиеваларның автограф истәлекләре, шагыйрьгә кагылышлы метрика дәфтәре күчермәләре дә кергән. Соңрак исә шагыйрьгә мөнәсәбәтле истәлекләр, фоторәсемнәр, аның әсәрләре басылган газета-журнал кисемтәләре, Тукай үлгәч аның йөзеннән алынган маска, автограф хатлары һ.б. тапшырыла.

Г. Тукайның архив материаллары 1960 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы фәнни архивында бер фондка тупланалар. Аларны фәнни тасвирлау эше Х.Г. Саймановага йөкләнә. Ул бу эшкә 1961 елның 15 июнендә керешә. Фондка 9 нчы тәртип саны куела, материаллар дүрт тасвирламага бүленәләр. Тасвирлау эше 1963 елның 18 декабрендә төгәлләнеп Г. Тукай фонды 4 тасвирламада 289 саклау берәмлеге тәшкил итә. Фонд үсә барып, 1966 елда инде 347 саклау берәмлеге исәпләнә.

I тасвирламада шагыйрьнең автограф кулъязмалары, басылган әсәрләре һәм аларга кагылышлы 1907–1947 елларда нәшер ител-

гән материаллар тупланган. Барлыгы 53 саклау берәмлеге теркәлгән, шуларның дүртесе – автограф.

II тасвирламада шагыйрьнең 1903–1913 елларда язган хатлары урнаштырылган. Барысы 19 саклау берәмлеге. Хатларның текстлары Академик басманың 5 нче томына урнаштырылды.

III тасвирлама Габдулла Тукайның тормыш юлына кагылышлы материаллардан гыйбарәт. Алар арасында метрика язмаларыннан күчермәләр, альбомнар, Тукай тормышы белән бәйле тарихи урыннарның сурәтләре, Тукай дәверенә караган шәхесләрнең фотолары, шагыйрьнең автографлы рәсемнәре бар. Барлыгы 126 саклау берәмлеге.

IV тасвирламада Г. Тукай турында замандашлары, дуслары, туганнары һәм башка кешеләрнең 1938–1961 елларда язылган истәлекләре урын алган. Барлыгы 159 саклау берәмлеге.

**Фонд № 9***

Тукай Габдулла (Тукаев Габдулла Мухаметгарифович)
(1886–1913) – татарский поэт

Опись № 1
рукописей, печатных произведений и материалов к ним
за 1907–1947 гг.

Постоянное хранение

| № | Делопроизв. | Заголовок единицы хранения | Крайние даты | К-во листов | Отметка |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | 234 | Стихотворения Г. Тукая. Рукопись-подлинник. На татарском языке, арабской графике. | 1909, 1911 | 6 | |
| 2. | | Тоже. Фотокопия. | 1909, 1911 | 8 | |

* Тасвирлама үзгәртүләрсез бирелә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 3. | 234 | «Литература» – 10ая тетрадь. Сборник стихотворений с автографом и датой автора. «На память товарищу Якубу Байбурину – Г. Тукаев. 2 ноября 1909 г. На татарском языке, арабской графике. Печатный экз. Напечатано: Казань. Электротипография «Урнэк», 1909 г. стр.1–8, 18–20 отсутствует. Л. 3 – печатная фотография поэта. | 1909 | 11 | |
| 5. | 234 | Стихотворение Г. Тукая (без названия). Рукописный текст на татарском языке, арабской графике, написано на листке журнала «Будильник». | 1912 | 2 | |
| 6. | 745 | «Слово Толстого». Стихотворение. Написано в больнице. Подлинник на татарском языке, арабской графике с подписью автора. | 1913 | 1 | |
| 7. | 250 | Стихотворения Г. Тукая: «Завещание», «Слово Толстого» на татарском языке, арабской графике. Фотокопии. | 1913 | 2 | |
| 8. | 48, 49 | «Слово Толстого». Стихотворения. Препроводительная записка автора к секретарю татарского журнала «Ан» («Знание») Хасани Зайнаб. С просьбой напечатать в следующем номере. Подлинники с подписью автора, на татарском языке, арабской графике. Написаны в больнице за несколько дней до его смерти.<br>Напечатано: Казань. Журнал «Ан», № 8, 1913 г. | 1913 28 марта | 2 | |
| 9. | | То же. Фотокопия. | 1913 | 2 | |
| 10. | | То же. Фотокопия. | 1913 | 2 | |
| 11. | | То же. Фотокопия. | 1913 | 2 | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 12. | 611 | Фотоснимок первой страницы журнала «Ан», март 1913 г. № 6 со стихами Г. Тукая: «Слава», «Отрывок» на татарском языке, арабской графике. На I листе. | 1913 | 1 | |
| 13. | 110 | Стихотворение Г. Тукая «Хорриятэ». Выписки на татарском языке, арабской графике, из газеты «Олфэт» февраль 1907 г., № 62. | 1941 | 3 | |
| 14. | 98 | Неизвестное стихотворение Г. Тукая. Напечатано в Ижевске, газете «Ленин юлы» («Путь Ленина») в воспоминаниях артистки Сахипжамал Гизатуллиной-Волжской, в связи с 25-летием со дня смерти Г. Тукая. Рукописный текст на татарском языке с подписями С.Хакима и А.Х. Хисматуллина. | 1940 | 1 | |
| 15. | | То же. Машинописная копия. | 1940 | 1 | |
| 16. | | «Экспромт». Стихотворение Г. Тукая. Записано Яраевым Ахметом из с. Амирханово, Свердловского р-на Чкаловской области со слов матери, 20 мая 1947 г. Рукописный текст с подписью Яраева А. | 1947 | 2 | |
| 17. | 605 | «Как Сабит научился читать». Стихотворение. Рукописный текст. Копия. Из книги Г. Тукая хранящейся в Госмузее ТАССР, инв. № 116165. На татарском языке, арабской графике. Выполнена ст. научн. сотр. ИЯЛИ Хисматуллиным А.Х. | 1912 | 2 | |
| 18. | 623 | «Наши стихи». Статья. Напечатано: газета «Фикер» («Мысль» № 15, 22 апреля 1907 г.) г. Уральск. Рукописная на татарском языке. Копия сделана ст. научн. сотрудником ИЯЛИ КФАН СССР Хисматуллиным А.Х. 18 августа 1953 г. в г. Уфе. | 1907 | 7 | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 19. | 196 | Тетрадь стихотворений Г. Тукая и др. неустановленных авторов (начало и конец не сохранилось). Рукописный текст на татарском языке, арабской графике. | | 8 | |
| 20. | 127 | Часть сборника избранных стихов, статей, сказок, сатирических рассказов Г. Тукая, подготовленных им в 1912 г. к изданию. Рукописные копии. На татарском языке, арабской графике. | 1912 | 197 | |
| 21. | 496 | Народные песни. Тетрадь Г. Тукая. Рукопись на татарском языке, арабской графике. | | 24 | |
| 22. | 497 | «Сожаление во время пожара». Статья для журнала «Ялт-Юлт» («Зарница»). Рукопись на татарском языке, арабской графике. Псевдоним автора «Шурале» (документ частично сгорел). | | 2 | |
| 23. | | То же. Фотокопия. | | 2 | |
| 24. | 54 | Стихотворение Г. Тукая без названия. Гранки, на татарском языке, арабской графике | | 1 | |
| 25. | | Бесплатное приложение к реакционному журналу татарского духовенства «Религия и жизнь». Здесь помещён нецензурный материал против женщин. Против этого гнусного выступления Г. Тукай написал стихотворение «Видели?» (т. I, стр. 76 четырехтомник). Текст печатный на татарском языке, арабской графике. | 1907 | 1 | |
| 26. | 621<br>622 | Стихотворение Г. Тукая «Видели?» и его статья «Дуня и Миша». Рукописная копия на татарском языке ст. научного сотрудника ИЯЛИ КФАН СССР Хисматуллина А.Х. из газеты «Фикер» («Мысль»), № 13 за 1907 г. | 1953 | 2 | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 27. | 106 | Вырезки иллюстраций из произведений Г. Тукая: «Парень и девушка», «Нос» и др. | | 5 | |
| 28. | 106 | Арсланов Г.В. – художник. Иллюстрации к произведениям Г. Тукая: «Сенной базар или отрубленная голова», «Шурале», «Парень и девушка», «Плешивый сорванец», «Кисенька» и др. Оригиналы. Ватман. Акварель в двух красках. Изданы, как иллюстрации к произведениям Г. Тукая. | | 16 | |
| 29. | | Фотокопия иллюстрации к стихотворению Г. Тукая «Нос». 11,7×17. | | 1 | |
| 30. | | Фотокопии иллюстрации художника Арсланова к произведению Г. Тукая «Яна Кисекбаш». 15×19,5. | | 8 | |
| 31. | 331–338 | Фото-иллюстрации сцен из драмы А. Файзи «Тукай», в постановке Татарского Гос. академического театра им. Г. Камала сезон 1940–1941 гг. 17,8×24, 11,7×172. | | 9 | |
| 32. | | Фотокопия титульного листа журнала «Сөембикэ», № 11, 1914 г., посвящённый году со дня смерти Г. Тукая. 15,8×23,8. | 1914 | 1 | |
| 33. | | Фотокопия титульного листа журнала «Ялт-Юлт» («Зарница»), № 23 за 1911 г. 18×24. | 1911 | 1 | |
| 34. | | Фотокопия титульного листа сказки Г. Тукая «Золотой петушок». 17,3×33,7. | | 1 | |
| 35. | | Фотокопия титульного листа сборника Г. Тукая «Плоды раздумья». 17×23. | 1911 | 1 | |
| 36. | | Фотокопия газеты «Фикер», которая издавалась в г. Уральске 1905–1907 гг. при близком участии Г. Тукая. 16,7×23,2. | | 1 | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 37. | | Фотоснимок здания Госфилармонии им. Г. Тукая (Казань, улица Островского-Кави Наджми). | 1962 | 1 | |
| 38. | | Фотоснимок здания татарской молодежной газеты «Эльислах», где сотрудничал Г. Тукай в 1907–1909 гг. г. Казань, улица Тукаевская, д. № 63. 11,7×17,6 | | 1 | |
| 39. | | Фотокопия газеты «Эльислах», 3 апреля, 1908 г., № 25. 17×23,5. | 1908 | 1 | |
бүлеге белгечләре. Музей экспозициясен яңарту 1996 (Р.Г. Гарифҗанова, М.К. Завьялова, Ф.З. Яхин фәнни эшкәртмәләре, рәссамы Ф.А. Зиязов) һәм 2006 елда (Р.К. Аймәтов җитәкчелегендәге музей коллективы, Э.У. Матвеева җитәкчелегендәге «Музей үзәге» иҗади-сәнәгать комплексы) уздырыла. Даими экспозициянең мәйданы – 361,7 кв.м., анда 600 гә якын саклану берәмлеге урын алган. Музей Казанның Иске Татар бистәсендә XIX гасыр ахыры тарихи-мәдәни мирас истәлеге булган ике катлы Шамил йортында урнашкан. Йорт архитекторлар Г.Б. Руш һәм Ф.И. Амлонг проекты нигезендә төзелгән. Ул беренче гильдия сәүдәгәр Ибраһим Исхак улы Аппаков (1821–1885) милке булып саналган. И. Аппаков бердәнбер кызы Бибимәрьямбануны отставкадагы генерал-майор, Кавказ халыкларының милли азатлык хәрәкәте җитәкчесе имам Шамилнең уртанчы улы генерал Мөхәммәтшәфигә кияүгә бирә һәм, бирнә итеп, әлеге йортны бүләк итә. XX гасыр башында Иске Татар бистәсендә көчле янгын вакытында әлеге бина да зыян күрә һәм Бибимәрьямбану биредә реконструкция ясата. 1906 елда Мөхәммәтшәфи Шамил Кавказга дәваланырга киткән җирендә вафат була. Бибимәрьямбану йортны кондитер товарлары җитештерү белән шөгыльләнүче сәүдәгәр Вәлиулла Ибраһимовка сата һәм ике кызы белән Санкт-Петербургка күченеп китә. Аннан соң әлеге бина төрлечә файдаланыла, хәтта торак йорт ролен дә үти. Музей шагыйрь исемен йөрткән урамда урнашкан. Элекке Юнысов мәйданында Тукай «Ялт-Йолт» журналы редакциясендә эшләгән. Әлеге мәйданда 1913 елның 4 (15) апрелендә шагыйрьнең җеназа намазы укылган.

Бу урамда Тукай һәм аның дусларына бәйләнешле башка йортлар да булган. 63 нче йортта 1908–1909 елларда шагыйрьнең актив катнашлыгы белән «Әлислах» газетасы чыгып килгән. 73 нче йортта рус-татар укытучылар мәктәбе («учительская школа») эшләгән. Анда Тукайның күп кенә дуслары укыган. 79 нчы йортта шагыйрьнең фикердәше Хөсәен Ямашев туган һәм гомер иткән. Тукайның тормыш юлын һәм иҗат эшчәнлеген чагылдырган музей экспозициясе йортның икенче катында дүрт залда урнашкан.

Беренче зал шагыйрьнең авыр балачагына багышлана. Әтисе Мөхәммәдгариф хәзрәт тарафыннан язылган Габдулланың тууы турындагы таныклыгы – бу залдагы иң кыйммәтле документларның берсе. Зиннәтулла бабасы өенең шартлы интерьеры безне шул

чордагы авыл мулласының көнкүреш тормышы белән таныштыра. Бала чагында Габдулла ике еллап Казанда, Яңа Татар бистәсе һөнәрчеләре гаиләсендә яши. Шәһәр турындагы беренче якты хатирәләре Печән базары, Татар бистәсенең матур һәм бай интерьерлы йортлары, Ташаяк ярминкәсе белән бәйле. Экспозициядә Печән базары сәүдә кибетенең шартлы интерьерында – читекләр, түбәтәйләр, калфаклар, Крестовников сабын кайнату һәм шәм эретү заводы продукциясе һ.б. күрсәтелгән.

Музейның икенче залы шагыйрьнең Җаек һәм Казан шәһәрләрендәге тормышы һәм иҗаты турында сөйли. Шагыйрь белем алган «Мотыйгыя» мәдрәсәсе мөдәррисе Мотыйгулла Төхфәтуллинның улы нашир, журналист, җырчы Камил Мотыйгыйның шәхси әйберләре, китаплары, ул чыгарган газета-журналлар – барысы да Тукай шәхес буларак формалашкан мохитне, Җаекның мәдәни тормышын күзалларга мөмкинлек бирә. Шушы ук залда Тукайның Казан чоры да яктыртыла. «Нурлы Казан» – шагыйрь өчен илһам чыганагы да, рухи таяныч та. XX йөз башына караган Казан күренешләре, шәһәрнең мәдәни тормышы белән таныштыручы театр, нәшрият һәм музыка дөньясы турындагы документлар, дуслары Ф. Әмирхан, Г. Коләхмәтов, Г. Камал гаиләләре әйберләреннән корылган әдәби салон интерьеры – барысы да Казан турында сөйли. Шулай ук шагыйрь корректор һәм экспедитор булып эшләгән китап кибете һәм «Болгар» номерларының кырыгынчы бүлмә күренешләре Тукайның киңкырлы иҗат эшчәнлеге алып баруын яктырта. Музейның иң кадерле ядкәрләре – шагыйрьнең шәхси әйберләре. Алар күп түгел: бишәү генә. Тамашачылар иң беренче булып, аның фаянстан эшләнгән тартмачыгы белән очрашалар. Ул аны үзенең беренче гонорар акчасына сатып ала һәм Газизә апасына бүләк итә. Шагыйрьнең кара бәрхеттән тегелгән түбәтәе, «Аң» журналын чыгаручылар – дуслары Әхмәтгәрәй һәм Зәйнәп Хәсәниләр бүләк иткән көмеш җиң каптырмалары, «Болгар» кунакханәсенең кырыгынчы бүлмә шартлы интерьерында урын алган юл кәрзине – Казан чоры экспозициясенең кадерле экспонатлары.

Шагыйрьнең сәяхәтләре һәм соңгы көннәре турында өченче зал сөйли. Ул Түбән Новгород, Сембер губернасының Гурьевка, Әстерхан, Уфа, Петербург шәһәрләренә сәяхәт итә. Бу сәяхәтләр документлар, фотосурәтләр, төрле шәһәрләрдә нәшер ителгән татар газета-журналлары һәм башка предметлар ярдәмендә

яктыртыла. Биредә тагын бер кадерле ядкәр урнашкан. Ул Тукайның 1912 елда Петербургка сәяхәте вакытында сатып алган карандаш савыты (Петербургка нигез салынуның 200 еллыгына багышлап эшләнелгән). Шулай ук биредә шагыйрь вафатыннан соң Казан медицина институты студентлары тарафыннан мәрхүмнең йөзеннән алдырылган битлек тә бар.

Соңгы «Тукай һәм бүгенге заман» дигән залда Тукайның төрле елларда, төрле графикада һәм төрле телләрдә чыккан китаплары белән танышырга мөмкин. Алар арасында шагыйрьнең 1933–1937 елларда Токиода дөнья күргән җыентыгы аеруча зур кызыксыну уята. Мәшһүр «Шүрәле» балеты сәхнә костюмнары да музей караучыларны битараф калдырмый. Шулай ук бу залда талантлы рәссамнар В. Аршинов, И. Колмогорцева, З. Гыймаев, Р. Вахитов, Н. Нәккаш, Ш. Шәйдуллин һәм башкаларның сәнгать әсәрләре урын алган. Музей экспозициясе буенча «Г. Тукайның тормышы һәм иҗаты», «Г. Тукай сәяхәтләре», «Шагыйрьнең балачагы»на багышланган экскурсияләр үткәрелә. Шулай ук музей Казанда шагыйрь белән бәйле урыннар буенча – «Нурлы Казан» һәм Татарстанда шагыйрьнең тормышы һәм иҗатына мөнәсәбәтле истәлекле урыннар белән таныштыруга багышланган «Шагыйрь бишеге» автобус һәм җәяүле экскурсияләр тәкъдим итә. Музейда шагыйрьнең чордашлары Ф. Әмирхан, С. Сүнчәләй, К. Бәкер, М. Бигиев, Ә. Хәсәни һ.б. турында «Г. Тукай һәм аның замандашлары» әдәби-музыкаль чаралар циклы эшләп килә; Г. Тукай премиясе лауреатларына багышланган кичәләр оештырыла. Күренекле шагыйрьләр, язучылар, галимнәр белән очрашулар уздырыла. Музейда балалар өчен Тукайның әкият геройлары белән мавыктыргыч уеннар, музей бәйрәмнәре, интерактив экскурсияләр тәкъдим ителә.

Календарь чаралар: Апрель – Тукай укулары; 2–5 апрель – Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген дәгъва итүче кандидатлар белән очрашу; 15 апрель – Төп нөсхә көне; 26 апрель – Г. Тукайның туган көне; 18 май – Халыкара музейлар көне; 21 март – Халыкара шигърият көне; 27 март – Халыкара театр көне; 11 июнь – музейның туган көне; 1 сентябрь – Белем көне; 25 декабрь – 10 гыйнвар – «Шүрәле белән Яңа ел»; 21 февраль – Халыкара туган тел көне уздырыла. Г.Тукай әдәби музееның адресы: Казан шәһәре, Тукай урамы, 74 йорт. Электрон адрес: muztukay@mail.ru. Сайт: http://g-tukay.tatmuseum.ru/.

***Әдәбият:*** *Багаутдинова Д.Б. Музей Габдуллы Тукая в Казани: Путеводитель. Казань, 1989. 63 с.; Литературный музей Габдуллы Тукая: Путеводитель. Казань, 2006. 9 с.; Музей Габдуллы Тукая в Татарстане: Путеводитель. Казань, 2006. 14 с.; Татарская энциклопедия. 2010. Т. V. С. 690; Ядкярләрдә – Тукай рухы: ТР Милли музее җыелмасында татар халык шагыйре Габдулла Тукайның мемориаль тупланмасы каталогы. Казан, 2012. 144 б.*

*Гүзәл Төхфәтова,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казандагы Г. Тукай Әдәби музее директоры,*
*Лена Медведева,*
*Казандагы Г. Тукай Әдәби музее өлкән фәнни хезмәткәре*

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘДӘБИ-МЕМОРАИЛЬ МУЗЕЙ КОМПЛЕКСЫ

ТР Арча районы Яңа Кырлай авылында Тукайга багышланган музей экспозициясе 1960 елларның икенче яртысында, башта җәмәгать башлангычында, авыл китапханәсендә оештырыла. 1971 елның 30 мартында ул М. Горький музее (Казан) филиалы, 1976 елда ТАССР Дәүләт музее филиалы статусын ала. ТАССР Министрлар Советының 1978 ел 7 декабрендә чыккан «Яңа Кырлай авылын һәм Габдулла Тукай мемориаль үзәген төзекләндерү, архитектура-сынлы бизәү буенча чаралар» карары буенча, рәссам Бакый Урманче проекты белән, яңа музей бинасы төзелә. Яңа музей эскпозициясен ачу тантанасы 1979 елның 25 апрелендә үткәрелә. Музей комплексы әдәби-нәфис экспозицияне (Б. Урманче проекты белән сап-сары нарат бүрәнәләрдән салынган ике катлы бина һәм Кушлавыч авылында урнашкан Тукаевларның музей-йорты) һәм мемориаль-көнкүреш экспозицияне (Сәгъди абзый, Әхмәтхан бай йортлары) үз эченә ала. 2006 елда музей дәүләт мәдәният учреждениесе статусына ия була. Әдәби экспозициянең авторлары – Д.Б. Баһаутдинова, И.З. Минһаҗева, Л.Е. Похвалинская,



рәссам А.П. Мухин. Музей экспозициясе 1986, 1996, 2006 елларда яңартыла; мәйданы – 809 кв.м, хәзерге вакытта музей фондларында 1279 берәмлек экспонат саклана.

Ике катлы агач бинада урнашкан «Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты» дигән төп экспозиция шагыйрьнең тормыш юлын гәүдәләндерә: биредә Тукайның беренче шигырьләре язылган кулъязма журналдан алып үзе исән чакта басылган иң соңгы китабына кадәр урын алган. Шулай ук ул хезмәттәшлек иткән газета-журнал, фоторәсемнәрне, Тукай биографиясенә һәм шагыйрь яшәгән дәвергә кагылышлы документларны, архив материалларын, апасы Газизә Зәбированың шәхси әйберләрен һәм дә Тукай үзе яшәгән «Болгар» кунакханәсе җиһазлары, Тукай темасына багышланган әдәбият-сәнгать әсәрләре – китаплар, картиналар, скульптура, графика һәм башка хезмәтләр дә күрсәтелә. Беренче катның дүрт залында Габдулла Тукайның иҗаты һәм тормышы темасы киң җәелдерелгән:

1 зал. Тукайның балачагы. (1886–1894). Бу залда Кушлавыч, Кырлай авыллары күренешләре, Кырлайда Габдулла Тукай укыган мәдрәсәнең, Тукайның беренче укытучысы Хәбибрахман хәлфәнең дә фотосурәтләре куелган. Аеруча игътибарны җәлеп итә торган экспонатлар (күчермәдә): Мөхәммәтгариф мулла үз кулы белән теркәгән улының туу турындагы метрикә бите (1886), Мөхәммәтгариф Мөхәммәтгалим улының Казан өязе Кушлавыч авылы мәчетенә икенче мулла итеп билгеләнү таныклыгы (1864, апрель), Габдулла Тукайның әтисе мулла Мөхәммәтгарифның үлеме турында метрикә язуы (1886, 29 август), Сәгъди Салиховның улы Садретдинның туу таныклыгы (1893 ел, 28 декабрь) бирелә. Экспозициядә шулай ук мәдрәсә шәкертләре укыган «Бәдәвам», «Кисекбаш», «Рисаләи Газизә» кебек китапларының төп нөсхәләр дә урын алган. Кырлай аылында, Сәгъди абзыйлар гаиләсендә Тукайның нинди мохиттә яшәгәнлеген күзаллау өчен, зал уртасындагы махсус күтәртмәдәге татар авылы йорты күренеше ярдәмгә килә.

2 зал. Җаек чоры (1895–1907) Тукайның Җаектагы тормышына багышланган экспозицияне Җаек шәһәренең гомуми күренеше, бертуган апасы Газизә Забированың, XX йөз башында төшереп алынган башка фоторәсемнәр ачып җибәрә. Шагыйрьнең мәдрәсәдә укыган елларын чагылдыручы экспонатлардан: мәдрәсә бинасының фоторәсеме, шәкертләр кулланган дәреслекләр; рус

әдәбиятының күренекле әдипләреннән Пушкин, Чехов, Куприн китапларына да урын бирелгән. Биредә Тукайның 1907 елда басылган «Яңа кыйраәт» китабының төп нөсхәсен күрергә мөмкин. Музейның бәя биреп бетергесез экспонатларыннан пыяла һәм тимер шкатулкалар тамашачыда тирән кызыксыну уяталар. Аны музейга 1971 елны Тукайның апасы – Газизәнең улы Хөсәен Забиров, әнисенең төсе булсын дип бүләк итә. Янәшәдә куелган уникаль экспонат – чигүле намазлык та игътибарны үзенә җәлеп итә. Аны Газизә Зәбирова 1895 елны энесе Габдуллага чигә. 1905 елны Камил Төхфәтуллин рус телендә чыга торган «Уралец» газетасының типографиясендә татар телендә газета-журналлар чыгару өчен рөхсәт ала. Бирегә шагыйрь буларак танылып килгән Тукай хәреф җыючы булып эшкә урнаша. Монда шагыйрь ярдәмендә газета – журналлардан «Фикер» газетасы, ә 1906 елны «Әлгасрелҗәдид» һәм «Уклар» сатирик журналы дөнья күрә. Алар экспозициядә төп нөсхәләрдә бирелә. Типографиянең хәреф җыю бүлмәсен зал уртасындагы махсус күтәртмәдәге интерьерда күрә алабыз. Анда куелган өстәл, урындык, хәреф кысалары, газета басу өчен башка махсус җайланмалар Тукайның типографиядәге эш шартларын күзалларга ярдәм итә.

3 зал. Казан чоры (1907–1913). Казан дәверенә Тукайның иң актив эшчәнлек еллары туры килә. Экспозиция Казан шәһәренең XX йөз башындагы истәлекле урыннарын күрсәткән оригинал открыткалар белән ачылып китә. Тулы бер стенд «Әлислах» газетасына бирелә. Монда газетаның 1908 елгы 23 февраль саны төп нөсхәдә һәм шагыйрьнең дуслары белән бергә төшкән фоторәсемнәре куелган. Моннан соң Казанда Тукайның актив катнашында чыккан «Ялт-Йолт» журналының 1910 елгы 1 октябрь саны, «Яшен» журналының 1909 елгы 3 гыйнвар саны, «Аң» журналының 1913 елгы 1 февраль саны; Тукайның үзе исән чагында басылган «Яңа кыйраәт» (1910), «Габдулла Тукаев шигырьләре» (1909), «Шүрәле» имзасы астында басылган «Яшен ташлары» (1910) китаплары урын алган. Экспозициядә Тукайның сәяхәтләрен чагылдыручы материаллардан: Әстерхан шәһәренең, Сәгыйть Рәмиев һәм Шәһит Гайфи белән бергәләп төшкән фоторәсемнәр белән беррәттән, Уфа, Петербург, Троицк шәһәрләренең дә фотоларын; иң кадерле экспонатлардан: Тукайның Ф. Әмирханга (Казан 1908, 23 июнь) һәм С. Рәмиевкә (1911, 20 октябрь) язган хатларын күрергә мөмкин. Залның уртасында шартлы рәвештә Тукай

яшәгән «Болгар» кунакхәнәсенең 40 нчы бүлмә күренеше китерелә. Монда куелган ике урындык, кәнәфи һәм өстәл нәкъ 40 нчы бүлмәнеке булмаса да, алар «Болгар» кунакханәсенең җиһазлары. Биредә шулай ук Хөсәен Ямашевның тимер караваты, этажеркасы да иң кадерле экспонат булып тора. Тукайның соңгы көннәре турында сөйләүче Клячкин шифаханәсе һәм шагыйрьнең вафатына бер тәүлек кала төшерелгән соңгы фоторәсемнәре, соңгы юлга озаткандагы матәм процессиясен чагылдыручы күренешләр, «Аң» журналының Тукайга махсус багышлап чыгарылган (1913, 1 февраль саны) төп нөсхәсе урын алган.

4 зал. Тукай мәңге яшәячәк! Экспозициядә Тукайның вафатыннан соң төрле елларда басылган китаплары, шулай ук аның турында татар, рус һәм дөнья халыклары телләрендә чыккан китаплар сәнгать әсәрләре белән чиратлаштырып бирелгән. Витринада урнаштырылган, рус телендә Павел Радимов тәрҗемәсендә 1921 елда чыккан «Шүрәле» китабы экспозициянең иң кадерле экспонатларыннан берсе булып тора.

Музейның икенче каты, Габдулла Тукайның татар профессиональ сынлы сәнгатен үстерүгә йогынтысы зур булганга – «Габдулла Тукай сынлы сәнгатьтә» дип атала. Тукай әдәбиятта, театрда, музыкада гына түгел, рәсем сәнгатендә, скульптурада да көчле яңгыраш тапты. Шул әсәрләрнең кайбер үрнәкләре музей залларына куелган. Экспозициягә урнаштырылган рәсемнәрдә Тукай тормышына бәйле төбәкләрдән аерым күренешләр дә сурәтләнә. Мәсәлән, биредә Ф. Әминов, С.О. Лывин, Х.М. Казаков, Ф. Хасьянова, И.К. Колмогорцева, М.К. Мавровская кебек рәссамнарның, Тукай тормышын һәм иҗатын чагылдырган сәнгать әсәрләре лаеклы урын алып тора.

Төп музей белән танышканнан соң, юл Тукай эзләрен саклаган сукмак буйлап, Сәгъди абзый нигезенә таба илтә. «Сәгъди абзыйның йорты, басу капкасыннан кергәч, күп ерак түгел икән; аз гына баргач, коймасы читәннән булган тәбәнәк кенә, салам түбәле бер өйгә туктадык» (Г. Тукай «Исемдә калганнар», 1909 ел). Сәгъди абзый нигезен Тукай шу-



лай сурәтли. Биредә безне салам түбәле абзарлары, читән коймасы белән кечерәк кенә бер йорт каршылый. 1986 елда Сәгъди абзый йорты махсус реставрацияләнеп, яңадан корылды: анда барлык корылмалар да XIX гасыр аһырындагыча, ягъни Габдулла яшәгән еллардагыча итеп куелды. Йорт эчендә савыт-саба, кием-салым һәм башка татар крестьяннары файдаланган типик әйберләр. Сәкедә урын-җир, намазлык, сандык. Ә сәкенең чаршау белән бүленеп алынган кече ягына самовар, чынаяк-тәлинкә, агач табак һәм башка аш-су кирәк-яраклары куелган. Биредә һәр крестьян йортында булган эш коралларыннан чабата ясау җайланмасы – бүкән, калыплар, шөшлеләрне дә күрергә мөмкин. Шулай ук әдәби-мемориаль комплекска кергән, авылның тарихи-мәдәни истәлекләренең берсе булып саналган, XIX гасырның беренче яртысында салынган ике катлы Әхмәтхан бай йорты да (Мөхәмәтҗанов Әхмәтхан; 1879–1955) зур әһәмияткә ия. Бу йортның хуҗасы – авылның урта хәлле крестьяннары. Ул тырыш, эш сөючән, намуслы, үз авылы халкына ярдәмчел кеше була. Аның үз көче белән төзегән җил һәм су тегермәннәре дә авыл халкына хезмәт иткән. Әмма 1930 елларда илдә барган репрессия аппаратының кулы Яңа Кырлай авылына да килеп җитә. 1931 елның 14 июнендә Мөхәмәтҗанов Әхмәтхан милке тартып алынып, гаиләсе белән Магнитогорск якларына сөрелә. Йорт 2006 елда махсус реконструкцияләнә һәм монда урта хәлле крестьян тормышын чагылдырган экспозиция урнаштырыла. Экспозициядә шул чорга хас булган типик әйберләр: йорт җиһазлары, бизәкле балчык савыт-саба, тәпәннәр, чүлмәк, кувшин, тәлинкә, табак-җамаяклар, тимер пычаклар, агач кашыклар, кием-салымнардан – хатын-кыз күлмәкләре, муенса-күкрәкчәләр, читекләр һ.б. урын алган.

Шагыйрьнең туган авылы Кушлавычта Габдулла Тукайның истәлеген мәңгеләштерү эшләре 1956 елда, шагыйрьнең тууына 70 ел тулу уңае белән башланып китә. Биредә 1956 елның 23 сентябрендә Габдулла Тукайга һәйкәл ачыла (сынчысы – И. Новоселов). Һәйкәл артында китапханә өчен яңа агач бина төзелә, аның бер бүлмәсендә 1959 елда музей ачыла. Ә 1986 елда, шагыйрьнең тууына 100 ел тулу уңаеннан, Кушлавыч музее экспозициясе үзгәртеп корыла. 1996 елда Тукаевларның музей-йорты яңадан торгызыла. Биредә түбәндәге объектлар урын ала: музейның төп экспозициясе урнашкан өч залдан торган алты почмаклы йорт, Казан арты крестьяннарының көнкүрешен яктырткан дүрт почмаклы

йорт, келәт һәм мунча (2011 елда төзелә). Алты почмаклы йортта урнашкан экспозиция шагыйрьнең әти-әнисенең йорты белән таныштыра. Музей экспозициясенең төп темасы – Габдулланың балачак дөньясы. Шагыйрьнең балачагы һәм аның балалар өчен язылган иҗаты, Г. Тукай әсәрләре һәм алар буенча ясалган рәсемнәр экспозициядә мөһим урынны алып тора. Китап образы музейнең барлык заллары аша уза.

Экспозициядә Арча һәм Әтнә район авыллары халкыннан җыелган, XIX–XX гасырларга караган көнкүреш предметлары, авыл тарихын бәян итүче, Кушлавыч авылында яшәгән мөселман дин әһелләре, Тукайның әти-әнисе һәм башка туганнары турындагы архив документлары, фотосурәтләр урын алган. Йортның хатын-кызлар ягы традицион татар авыл йортын гәүдәләндерә. Монда ана дөньясы: бик күп әйберләр уңган һәм тырыш хатын-кыз куллары белән эшләнгән. Бүлмәнең бер почмагында зур мич урнашкан, ул чын мәгънәсендә гаилә учагы җылысын биреп тора. Аның янәшәсендәге витринада шагыйрьнең әнисенең шәхси әйберләре куелган. Чит кешеләр кулында, ана мәхәббәтен, якыннарының назлау-иркәләвен күрмичә узган балачагы булачак шагыйрьнең күңелендә төзәлмәс яра калдыра. Авыр ятимлек язмышының әрнүле хатирәләрен вакыт та оныттыра алмый. Нәкъ менә Кушлавыч авылыннан – аның ятимлек юлы башланып китә. Шагыйрь иҗатында, бигрәк тә балалар өчен язылган әсәрләрендә, ана, гаилә, балачак темалары ачык чагыла. Кайчак («Минем гаиләм» шигырендә) үрнәк бәхетле гаилә образын тудыру омтылышын күрергә мөмкин. Бу – шагыйрьнең үзе мәхрүм булган балачагын сагынуыдыр.

Элекке Казан губернасының Мәңгәр волостена кергән Кушлавыч авылы Казан артындагы башка татар авылларыннан бер ягы белән дә аерылып тормаган. Ул Казаннан 60 чакрым ераклыкта урнашкан. 1885 елгы хисапка алу мәгълүмәтләре буенча бирedә 120 хуҗалык, 794 кеше саналган. Авыл халкы фәкыйрьлектә яшәгән. Төп кәсепләрен умартачылык алып торган. Авылда бер кибет, бер тимерче алачыгы булган. Бердәнбер күренекле урынны мәчет алып торган. Г. Тукай заманында Кушлавыч әнә шундый булган.

Хәзер Кушлавыч авылында Тукай чорыннан калган бер генә бина да сакланмаган. Ләкин монда әтисенең кабере һәм шагыйрьнең балачагын искә төшерүче мохит, тирәлек бар. Булачак шагыйрьнең илһам чишмәсе, туган телгә мәхәббәт хисе,

әйләнә-тирәне аңларга омтылышы нәкъ менә Казан артында формалаша да инде.

Музей директорлары: З.М. Гарипова (1971–1973), З.Ф. Фәйзрахманова (1974–1978), Р.Х. Якупов (1978–1979), Б.В. Антонов (1979–1983), Д.А.Шакиров (1983–2000), Г.Ф. Лотфуллин (2000–2001), Д.З. Абдуллин (2001–2006), Т.К. Гумеров (2006–2014). Хәзерге вакытта Габдулла Тукай әдәби-мемориаль музей комплексы директоры – Д.З. Абдуллин.

***Әдәбият:*** *Музей Г. Тукая в Кырлае. Кырлайда Г. Тукай музее. Казан, 1984. 14 с.; Татарстанда Габдулла Тукай музейлары: Сәяхәтнамә = Музеи Габдуллы Тукая в Татарстане: Путеводитель. Казан, 2006.*

*Дамир Абдуллин,*
*Кырлайдагы Г. Тукай Дәүләт әдәби-мемориаль музей комплексы директоры*

## УРАЛЬСКИДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ МУЗЕЕ

Г. Тукай музее татар иҗтимагый оешмалары инициативасы белән, Казакъстан һәм Татарстан республикалары Президентлары Н. Назарбаев һәм М.Ш. Шәймиевнең уртак килешүләре нигезендә, 2006 елның 12 декабрендә Уральск шәһәрендә дә ачыла. Аны булдыруга шәһәрнең «Г. Тукайның Евразия үзәге» рәисе проф. Рәззак Әбүзәрев, шулай ук эшмәкәр Ришат Хәйруллин, Көнбатыш Казакъстан тарих һәм крайны өйрәнү музее директоры Сара Танабаева, ТР Милли музее директоры урынбасары Алсу Хәйруллина актив катнаша; шәһәрдә яшәүче татарлар да үзләренең өйләрендә саклан-ган тарихи әһәмияткә ия әйберләрне бүләк итә. Габдулла Тукай музее заманында шагыйрьнең остазы имам Мотыйгулла Төхфәтуллин яшәгән, шәкерт Тукай үзе дә еш килеп йөргән ике катлы тарихи йортта урнашкан. Экспозициясенең мәйданы





170 кв.м., фондларында 1000 нән артык саклау берәмлеге бар. Дүрт бүлектән гыйбарәт экспозиция 4 залны бизи. «XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Уральск татарларының тормышы һәм көнкүреше» шәһәрдәгеләрнең көнкүреш әйберләре, тормыш тәртибе белән таныштыра. Тукай тормышына һәм иҗатына багышланган бүлектә М. Төхфәтуллин кабинеты интерьеры торгызылган. Андагы материаллар Тукайның балачагы, Уральскидагы тормышы һәм иҗади эшчәнлеге, Казанда яшәгән еллары турында сөйли. Экспозициянең бер бүлеге Уральскида туган фән һәм сәнгать, дин эшлеклеләренә багышланган. Аерым алганда, бу йортта үскән, ТАССР халык артисткасы Галия Кайбицкая, тарихчы Рәфикъ Нәфыйков, композитор Нәҗип Җиһанов, скульптор Хәсән Шәмсетдинов, шәһәр мәчетләре имамнары Габдерәкыйб һәм Мөхәммәдгариф Тулбаев, Гайнетдин Җәлалетдиновның шәхси әйберләре күрсәтелә. Бинаның подвалында 1905–1907 елларда Камил Мотыйгый наширлегендә чыккан «Уральский дневник», «Фикер» газеталары, «Әлгасрелҗәдид», «Уклар» журналлары басылган типография эшләгән. Музейда ел саен Муса Җәлил истәлеге көне (15 фев.), Шигърият көне (26 апр.), Халыкара музейлар көне (18 май) һ.б. төрле чаралар үткәрелә. Музейда булучылар якында гына урнашкан Татар мәдәнияты үзәге, Кызыл мәчет, берара Тукай яшәгән Галиәсгар Госманов йорты, «Уралец» газетасы типографиясе, «Казан» кунакханәсе, шагыйрь укыган рус мәктәбе бинаалары белән дә танышырга мөмкин.

Музей ачылган көннән 2014 елга кадәр директор булып Марат Рафаэль улы Баһаутдинов эшли.

***Әдәбият:*** *Рәмиев З. Уральскида Тукай музее булды // Мәдәни җомга. 2007. 12 гыйнв.; Тукая Габдуллы музей // Татарская энциклопедия. Т. V. Казань, 2010. С.691; Абузяров Р.А. Музей Габдуллы Тукая – научный и методический центр патриотического воспитания, формирования межконфессионального согласия // Музей Габдуллы Тукая – центра формирования паритетного евразийства, межнационального и межконфессионального согласия. Уральск, 2007. С. 11–20; Умарова Г.С. Воспитание толерантности у студентов казахского отделения на материалах музея Г. Тукая // там же. С. 60–64; Милли мирасыбыз сагында // Чын*

*мирас. 2013. № 5. Б. 64–65 [М. Баһаутдинов белән Л. Гобәйдуллин әңгәмәсе]; Курманова Д. Музей Тукая в Уральске: назад в прошлое. akbars.kz›rus/?id=4158*

*Зөфәр Рәмиев,*
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге*
*баш фәнни хезмәткәре*

## ПАМЯТНИКИ ТУКАЮ

Первое скульптурное изображение великого татарского поэта – это барельеф на надгробии начала двадцатого века. Могила, расположенная на центральной аллее, окружена чугунной массивной оградой 2,5 на 3,3 метра. Внутри установлен на мраморной плите черный мраморный обелиск высотой 2 метра, на котором выше надписи расположен барельеф.

Известно, что в 1922 году в конкурсе на скульптурном факультете Казанской художественной школы в предложенных заданиях по проектированию монумента на героическую тему одним из первых стояло имя татарского поэта.

В 1956 году в одной из двух ниш театра оперы и балета был установлен памятник Тукаю скульптора Е. Шулика в лучших классических традициях парадного портрета, раскрывающий характер личности, ее духовной жизни. Изначально созданный в бетоне, в 2005 году, в год 1000-летия Казани, памятник был отлит в бронзе. Он удачно вписан в полукружие бокового фасада театра.

Произведение С. Ахуна (в соавторстве с московскими скульпторами Л.Е. Кербелем и Л.М. Писаревским и архитектором Л. Павловым) было открыто в 1958 году в сквере центральной части города.

Фигура Тукая с открытой книгой в руках установлена на высоком восьмигранном постаменте из черного лабрадорита. Восьмигранная высокая часть постамента вырастает из более широкого четверика с усеченными углами. Это является прямой цитатой архитектурной традиции Булгара. Нижняя часть постамента деликатно украшена полосой орнаментальной резьбы, характерной для булгарской архитектуры.

Мемориальные произведения, посвященные Тукаю, находятся на его родине в деревне Кушлавуч, в Кырлае. Всего в Арском районе установлено 5 памятников Г. Тукаю: бюсты на железно-

дорожном вокзале и центральной площади Арска (скульпторы Абдрашитовы), в селе Новый Кырлай (скульптор И.А. Новоселов).

Памятник около музея в селе Новый Кырлай (скульптор Б. Урманче), изображающий поэта сидящим на деревенской скамеечке, является центром художественного ансамбля, включающего в себя архитектуру (объемно-пространственное решение музея) и естественное природное окружение с вкраплениями декоративной скульптуры из дерева.

Нетрадиционным решением в увековечивании памяти поэта отличается скульптурная композиция И. Ханова «Древо поэзии» (1986 г.). Композиция около шести метров высотой с опорой в одной точке выполнена в бетоне, инкрустированном смальтой. В скульптуре работает не только сам объем, но и ее внутреннее пространство, сквозной ажур, организованная воздушная составляющая.

Также Тукаю установлены памятники и за пределами Татарстана. Это бюст в сквере Тукая на главной улице Уральска (скульптор М. Гасимов), где продолжительное время жил и работал поэт. В 2011 году Москве на Новокузнецкой улице был открыт памятник, выполненный заслуженным художником России С. Щербаковым.

В Петербурге на пересечении Кронверкского проспекта и Звериnской улицы весной 2006 года установлен памятник, выполненный в классической традиции скульптором А. Зиякаевым.

В 2009 году в Анкаре был установлен бюст Г. Тукая (скульптор А. Минулина, архитектор А. Лопаткин), этими же авторами в 2012 году был создан памятник поэту в парке его имени в Стамбуле.

Г. Богородской создана памятная медаль «Тукай» (1976, медь).

***Литература:*** *Казань в памятниках истории и культуры. Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. С. 214; Червонная С.М. Искусство советской Татарии. М.: Изобразительное искусство, 1978, С. 155; Древо жизни Ильдара Ханова: Альбом / вступительная статья Р.Р. Султановой. Казань: Идел-Пресс, 1998; Кривошеева Т.Н. Габдулла Тукай и мотивы его творчества в произведениях пластического искусства // Тукай мирасы һәм хәзерге заман: халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казань. 2007. С. 303–307; Кривошеева Т.Н. Миссия Ильдара Ханова // Республика Татарстан. 2010. № 71–72 (26708–26709). С. 3; Кривошеева Т.Н. Илдар Ханов иҗаты: традицияләр һәм новаторлык // Шәһри Казан. 2010. № 39 (4771). С. 5*

*Татьяна Кривошеева,*
*кандидат искусствоведения, преподаватель*
*Художественного училища им. Н.И. Фешина*

*Әгәр минем милләт, илтифат итеп,*
*искә алса, —*
*Шул минем максатым, теләгем*
*һәм бәхетем*

## СОВЕТ ЧОРЫНДА ЯЗЫЛСА ДА...

Әхмәт Фәйзинең күренекле шагыйрь, прозаик, драматург буларак 1940–1950 еллар татар әдәбияты үсешенә керткән зур өлеше турында сөйлибез икән, сүзне иң беренче чиратта аның өч әсәренә нигезләнеп алып барырга тиешбез. Болар: татар театры сәхнәсенә менгән «Тукай» пьесасы, атаклы «Шүрәле» балеты либреттосы (Л. Якобсон белән берлектә), «Тукай» романы. Ул аеруча «Тукай» романын иҗат итүгә зур көч куйган. Әлеге ике китаптан торасы эпопея өчен яңа материаллар җыю барышында язучы Тукайның Уральскида яшәгән вакытларда аралашкан замандашлары белән дә мөнәсәбәткә кергән, гомумән, Уральскида булып узган иҗтимагый вакыйгалар белән кызыксынган. Ә. Фәйзи җыйган төрле-төрле характердагы материаллар, шөкер, юкка чыкмаганнар, вафатыннан соң беркадәр вакыт узгач, алар Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына тапшырылган. Бүген бу кыйммәтле 101 нче фонд Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана.

Ә. Фәйзинең әлеге шәхси архивы бик бай. Ул тасвирланган, димәк, андагы материалларны фәнни максатларда өйрәнергә була. Заһир Шәйхелисламов, аларны өйрәнеп, «Аңлыем дип шагыйрь җанын...» исемле монография дә чыгарды[1]. Күптән түгел без дә бу фондтагы материалларга игътибар иттек. Шул вакытта безне фондның 3 нче тасвирламасында күрсәтелгән шактый күләмле бер хат кызыксындырды[2].

Хатны Әхмәт Фәйзигә Габдерахман Кәлтиев 1953 елның 5 ноябрендә юллаган. Тексттан аңлашылганча, ул – Уральск кешесе. Тарихчы Р.И. Нәфыйков китабында аның Гариф (Гарифҗан) Кәлтиевнең бертуган энесе икәнлеге, 1905–1907 елгы инкыйлаби вакыйгалар турында рус һәм татар телләрендә ике мәкалә дә бас-

---

[1] Шәйхелисламов З.Р. Аңлыем дип шагыйрь җанын... (Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай). Казан, 2001. 144 б.

[2] Габдерахман Кәлтиевнең Ә. Фәйзигә язган хаты. Автограф. 5 ноябрь 1953 ел // ЯһММҮ, 101 ф. 3 тасв. 123 с.б.

тырганлыгы әйтелә[1]. Гариф Кәлтиев (1882–1940) Уральскидагы типографиядә печатник булып эшләгән, Тукай белән бик якыннан аралашкан. Р.И. Нәфыйков, Г. Кәлтиев, Г. Тукайларның татар телендә листовкалар, өндәмәләр бастыруны оештыруларын, аларны эшчеләр арасында таратуларын да яза.

Габдерахман Кәлтиевнең хаты, югарыда искәртелгәнчә, 1953 елда, совет хакимияте чорында язылган. Текстта чагылыш тапкан фактлар, фикер-бәяләмәләр башлыча абыйсы Гариф Кәлтиев сөйләгәннәрдән чыгып китерелә. Гариф Кәлтиевнең (бераздан-мы) большевиклар партиясе әгъзасы булганлыгы мәгълүм. Габдерахман Кәлтиев хат язылган вакытларда Уральскида инкыйлаби вакыйгалар турында диссертация язу белән мәшгуль. Болар бөтенесе хатта ул чор мохитен, вакыйгаларны беркадәр совет идеологиясе күзлегеннән чыгып интерпретацияләүгә дә китерә (мәсәлән, Тукай белән К. Мотыйгый мөнәсәбәтләре, карагруһлар турында язганда). Шулай да хат чынбарлыкны бозып күрсәтә икән дигән фикер туарга тиеш түгел. Хатта китерелгән Тукайның Уральскидагы иҗтимагый эшчәнлегенә караган фактларның чыннан да булганлыгы аның турындагы истәлекләр белән раслана.

Ни генә булмасын, Габдерахман Кәлтиев хаты да Тукайның Уральскидагы эшчәнлеге турында сүз барганда җентекләп өйрәнелергә тиешле. Шуны истә тотып, укучылар игътибарына бу хатның тулы текстын (бернинди үзгәрешсез) тәкъдим итәргә булдык.

Г. Тукай һәм К. Мотыйгый (1883–1940) мөнәсәбәтләрен яктырту берьяклы гына булмасын өчен, К. Мотыйгый-Төхфәтуллинның «Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем» исемле, 1914 елны аерым китап булып Казанда басылып чыккан истәлеген дә укучылар игътибарына тәкъдим итәбез. Текст «Тукай турында истәлекләр»[2] китабыннан алынып, кыскартылган урыннары К. Мотыйгыйның «Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем»[3] ядкяреннән тулыландырылып бирелә.

*Кереш мәкалә һәм искәрмәләрне ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы, профессор Зөфәр Рәмиев язды*

---

[1] Нафигов Р.И. Тукай и его окружение. Казань, 1986. С. 46.

[2] Тукай турында истәлекләр / төз. И. Нуруллин, Р. Якупов. Казан, 1986. Б. 30–37.

[3] Төхфәтуллин М.-К. Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем. Казан: Умид, 1914. 22 б.

**Хат**

Исәнмесез, Әхмәд иптәш Фәйзи, шушы хат аркылы сезгә бик күп сәламнәремне юллап, сәламәтлек һәм эшләрегездә зур уңышлыклар теләп калдым. Берникадәр уйлану һәм эзләнүләрдән соң, сезгә шушы хатны язуымны тиешле таптым. Хат язып борчуым өчен гафу итегез.

Әхмәд иптәш, минем уемча, сез, әлбиттә инде, «Тукай» романын язуда дәвам итәсездер[1]. Мин дә бит хәзер Уральски шәһәренең моннан 50 еллар борын булган хәлләре белән бәйләнешле темада булган диссертация язу эшләренә керешеп йөрим[2]. Шул сәбәбле прогрессив күз карашлы халык шагыйре Тукаевны чыгарган дәвернең урталыгын һәм аның особенностьларын тикшерү белән шөгыльләнәм. Бу йирдә мине бик кызыктырган һәм Тукаевның Уральскидагы тормышы белән бәйләнешле моментлар күп. Үзегезгә билгеле, Тукаевның Уральскидагы тормышы хакында бик күп төрле фикерләр бар. Ләкин аларның кайберәүләре белән һич тә килешеп булмый. Бу йирдә, минем уемча, иң дөрест мәгълүмат: Габдулла Кариевның Тукаевның Уральскидагы тормышы хакындагы язылган хатирәсе[3] болар дип уйлыйм. Тукаев хакындагы тарихның бик җитди бер мәсьәләсе – Тукаевның Уральскидан китү мәсьәләсе. Тукай, әлбиттә, тик үз теләге буенча гына Уральскидан китмәгән. Аның Уральскидан китүен тизләтергә сәбәп булган берничә төрле шартлар булган. Бу шартларның эчендә кайберәүләр, Тукайга каршы чыккан төрле «бәлаләрне» күрмиләр. Моңар кадәр Тукаевның Уральскидан Казанга китүенең төп сәбәбен күбесенә Тукаевның әдәбият-матбугат мәйданына ашкынуыннан дип төшендерелде, шул ук вакытны Тукаевның теләгеннән тыш булган яклары Тукаев фәкать үзенең әдәби иҗатларын, үзенең шагыйрьлек теләкләрен киңрәк мәйданга чыгарырга юл эзләгән бер яшь шагыйрь сурәтендә генә күрсәтелде. Шулай ук Камил Мотыйгый белән Тукаевларның арасындагы мөнәсәбәтләргә дә җитәрлек әһәмият бирелмәде. Хәзерге көндә дә Тукаев белән Камил

---

[1] Ике китап итеп уйланылган бу романның беренчесе 1952 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкса да, Ә.Фәйзи аның өстендә эшләвен дәвам иттергән, аның тулыландырылган икенче басмасы 1956 елда нәшер ителгән («Әдипләребез». Ике томда. Т. 2. Казан, 2009. Б. 482).

[2] Диссертациянең язылып бетү-бетмәве турында мәгълүмат табылмады.

[3] «Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы» исемле язмасы «Мәктәп» журналының 1913 елгы 4 нче санында басылган (Б. 100–105).



Г. Кәлтиевнең Ә. Фәйзигә язган хатының беренче бите. Автограф. 1953 ел, 5 нче ноябрь, Уральск // ЯhММҮ, 101 ф., 3 тасв., 123 с.б.

Мотыйгыйның аралары бозылу мәсьәләләренә тиешле күңел бирмиләр һәм моның тарих өчен әһәмияте юк дип караучылар да юк түгел. Тукаев белән Камил Мотыйгыйны бер теләктә, бер юлда булганнар дип хөкем итәләр. Бу, әлбиттә, зур яңлышлык. Әгәр дә мондый күз караш матбугатта юл алса, ул Тукаевның тарихтагы ролен киметеп, Тукаев хакындагы тарихка яңлышлык тудырыр иде. Җирлек материаллар һәм фактлар Тукаевның Уральскидан фәкать шул елларны (реакция башлаган елларны) китәргә мәҗбүр булганлыгы хакында тирәнрәк сәбәбләрне күрсәтәләр. Бу елларны Тукаев кыенлык белән булса да юл расходына акча эзләве һәм, акча табып[1], тизрәк Казанга китүе факт. Тукаевны Уральскида торудан биздергән, аны яңа дөньяга тарткан сәбәбләрнең нигезгесе – Тукайга карашы, аны күрә алмаучылар тарафыннан хәрәкәтнең көчәюе дип әйтергә була. Бу еллар, реакцион элементларның котырып, революция көчләренә каршы баш күтәрүе. Бигрәк дә үзенең үткен сүзле шигырьләре белән чыккан шагыйрь Тукаевка бу елларда карагруһлар тарафыннан нәфрәт чаткылары чәчри[2]. Тукаевның моңа кадәр «Уклар», «Әлгасрелҗәдид», «Фикер» шикелле газета-журналларда карагруһ элементларга каршы язган мәкалә һәм шигырьләре. Байлардан, муллалардан көлеп язган үткер шигырьләре (ул вакыт «Уклар» журналында ишаннарны чалмалы дөя һәм аларның мөридләрен чалмалы ишәкләр итеп төшергән карикатуралар басыла). Бигрәк тә Тукаевның эшчеләрне забастовка ясарга өндәүләре, эшчеләр[3] хәрәкәтенә катнашып йөрүләре, эшчеләргә забастовка ясарга ярдәмләшүе[4] аркасында Тукайның хезмәттән чыгарылып[5] эшсезлектә, кыенлыкка, мохтаҗлыкта кала.

---

[1] Г. Кариев: «Аңа атасыннанмы, белмим кемнәндер, 100 сумнар чамасы мирас калган икән, шуны бер писарь белән хлопатать итеп, акчаны алып, үзенең сөйгән Казанына китте», – дип яза. Р. Хәйруллин «үзара акча җыеп» Тукайны Казанга озаткан (Г. Тукай. Академик басма. Т. 1. Казан, 1943. Б. XVIII ).

[2] Гайнетдин Туприевка адресланган «1909, 13 март» тарихлы хатында Тукай: «Уральскиның үзенә вә җаһил татарларына, һәммәсенә киткән вакытымда ләгънәт укып киткән идем», дип язган.

[3] Чыганакта: эшчилә.

[4] А. Гладышев истәлегендә: «өлкән иптәшләрнең кушуы буенча, мин һәм Апуш (Г. Тукай) кәгазьләр, прокламацияләрне шәһәр уртасындагы Б. Михайловская урамында һәм башка җирләрдә ябыштырып йөрдек... Эшчеләр һәм «мужиклар»ның листовка укуларын һәм куеннарына яшерүләрен күреп, Тукай куана иде», – диелә (Тукай турында замандашлары. Казан, 1960. Б. 71–72).

[5] Г. Кариев язуына караганда, Тукай Камил Мотыйгыйдан матбагасын сатып алган Мортаза Гобәйдуллиннарның «Фикер» газетасын чыгарудан туктатуы аркасында эшсез кала.

Карагруһлар «Уклар» һәм «Фикер» матбагасын ут төртеп яндыралар[1]. Эшчеләрнең 8 сәгатьлек эш көнен куюны, союзлар корырга, эшчеләрнең җыелышларын ясарга ирек бирү һәм эшчеләрнең тормыш хәлләрен яхшыртырга таләп итеп куйган требованиеләренә каршы шәһәр купецлары, эшчеләрнең забастовкаларын тыярга үтенеп, военный губернаторга мөрәҗәгать итәләр. Алар: «Тимер юлда бунт. Безнең товарларыбыз югала» дип, губернаторны куркыталар. Губернатор, бу хәбәрне ишетеп, забастовкаларга каршы төрле чаралар күрә башлый. Бу эшләрне тикшерү максаты белән тимер юл эшчеләренә вицегубернатор Шидловскийны йибәрәләр. Бу вакыт тимер юл эшчеләренең җыелышлары булып яткан вакыт була. Шидловский, килеп, эшчеләр белән сөйләшергә рөхсәт сорый. Аңа эшчеләр рөхсәт итәләр. Ул, үзенең военный губернатор Родзянко тарафыннан йибәрелгәнлеген әйтеп, эшчеләрнең забастовка ясауларының сәбәбләрен сорап, аларның тиздән забастовкаларын туктатуны таләп итә. Эшчеләр аңа: «Без забастовканы тик стачка комитетының күрсәтүе буенча гына туктатабыз» дип җавап бирәләр. Шушы көннән башлап күп арестлар башлана. Бу көннәрдә ышпиклар[2], доносчылар хәрәкәттә була. Карагруһлар Тукаевны да кулга алу юлын көн-төн эзлиләр. Уральски татар карагруһларының башында Фатыйх Шәрипов кебек бай сәүдәгәрләр була. Болар донос йөртәләр. Шул сәбәбле шул көннәрдә доносчыларга карата әйтелгән: «Фатыйх – катык, эчең бокырдый – тычкан шыкырдый» дигән тирән мәгънәле җөмләләр күп вакытка кадәр безнең халыкның исендә булып килделәр. Минем исемдә әз генә калган, 1925 елларда, типографиядә наборщик булып эшләгәндә, без яшь эшчеләр, Тукай белән бергә типографиядә эшләгән карт эшче, Гарифҗан Кәлтиевтән бу җөмләләрнең мәгънәсен сорадык. Ул безгә болай дип төшендерде: «Фатыйхка катык дип исем бирү – кислятина дип әйткән сүзнең мәгънәсендә, – диде. Фатыйх бай берәүнең эче бокырдаса да, «Ай-һай, идән астында

---

[1] Булган хәл. Р. Вафеев «Господин издатель» исемле китабында бу турыда: «4 мая противники изданий Тухфатуллина впервые совершили нападение на редакцию и типографию. Они подожгли баню некоего торговца, рядом с постройкой, где размещалось издательство. День был ветреный, и огонь перекинулся на соседние постройки, включая типографию. ... Служащие типографии, включая Тукая, спасали оборудование и машины», – дип яза (С. 115).

[2] Монда: *шпиклар* – шпионнар, яшерен агентлар.

тычканнар шыкырдый түгел микән» дип шикләнеп, колак салган. «Тычканнар» дигән Фатыйхның өендә: «Идән асты әһелләре – революционер-подпольщиклар, алар патшага каршы эш йөртәләр. Кайда әле тизрәк» – дип, донос ясарга хәзерләнгән.

Камил Мотыйгый белән Тукайның дуслыгына килгәндә, мондый фактларны күрсәтергә тугры килә: Камил Мотыйгый революция башларында революционер булып күренергә тырышкан мөхәррир, матбага хуҗасы, иске кадимчеләргә каршы көрәшә. Ләкин аның бу көрәштән максаты: атасы Мотыйгулла хәзрәтнең имамлык указын алдырган рәкыйбчеләргә (Рәкыйб хәзрәт Тулбаев), булган үчне кайтару булды. Шул сәбәбле Рәкыйб хәзрәт имамлык указын алгач, аңа һәм аның мөридләренә каршы Камилнең көрәше барлык кадимчеләргә каршы көрәш булып танылды. Камил Мотыйгый 1905 елгы революциядә тик вакытлыча[1] гына попутчик булды.

Революция җиңелгәннән соң, мәсләксез, тик үзенә шөһрәт эзләгән динчел бер милләтче булып калды. Революция башларында Камил Мотыйгый һәм Тукай бер эздә йөрсәләр дә, 1906 нчы елларда Камил Мотыйгый, революциягә каршы фронтның дулкыннарына ияреп, эшчеләр кузгалышына каршы чыга. Габдулла Тукаев исә барлык вөҗүде белән революциянең көчләренә ышанган шагыйрь, революциянең идеалларын халык арасында таратуын дәвам итә. Эшчеләр белән нык бәйләнеш ясап, аларны забастовкага өнди, эшчеләргә забастовка эшләрендә ярдәмләшә. Әлбиттә, әле бу көннәрдә Тукайны революциядә катнашкан төрле партияләрнең юлын тирәннән төшенеп йиткән деятель булган дип әйтеп булмый. Ләкин, шулай булса да, шул көннәрне Тукай белән мәсләктәш һәм сердәш кешеләрнең барын да Бөек Октябрь революциясе җиңгәннән соң большевиклар партиясендә һәм Совет хөкүмәтен урнаштыручылар ягында булдылар (Покатилов, Рәхим Рамазанов, Александр Коканов («Сашка»), Гариф Төхфәтуллин, Шәһид Миндубаев, Гарифҗан Кәлтиев һ.б.). Камил Мотыйгый исә, 1919 елны Самара шәһәрен чех-словаклар алгач, аклар ягына чыгып, яңадан «мөхәррир» була. Камил Мотыйгый аклар ягында «Безнең фикер» дигән атакта[2] большевикларга каршы газета чы-

[1] Чыганакта: вакытча.

[2] *Атакта* – монда: исемдә.

гара[1]. Бу газетада Камил болай дип, шигырь яза: «Чыкды менә бу газета басылып «Безнең фикер», бу фикер – безнең фикер бу, бу фикер – тугры фикер».

1906 елларда Камил Мотыйгый белән Тукайның арасында сәяси күз карашларның көннән-көн тирәнәюе, бу ике арада дошманлык тудыра. Әгәр дә Камил Мотыйгый, моннан борын Тукайның аңар багышлап язган мәкаләсе өчен аңар жалованиене ике исә арттырган булса, хәзер аны [Камил Мотыйгый][2] эшчеләрне забастовкага чакыруы өчен, бөтенләй хезмәттән чыгарып ташлый. Моның дөреслеген без Камил Мотыйгыйның Тукай хакындагы үзе язган хатирәсеннән дә укып күрә алабыз. Камил болай дип яза: «Ул шул елларда модада булган эшчеләрне забастовкага котыртучылар мәзһәбенә кереп китеп, минем матбагада булган барча эшчеләрне миннән жалование арттыруны сорап, эш ташларга котыртты. Мин, Габдулла әфәнденең бу эшен сизеп, берничә мәртәбә тәһдид кылып[3] куйсам да, файда бирмәде. Ул һаман котыртуында дәвам итте. Шуның өчен ахирел әмер[4] аны матбагадан (матбагам ябылмастан борын ике атна гына әүвәл) бөтенләй чыгарырга тугры килде. Бу эш минемчә бик урынлы булып күренсә дә, Габдулла әфәндегә бик каты тәэсир әйләмеш иде. Ул шуның өчен үлгәнче миңа ачуланып һәм кәефе китеп йөрде»[5]. (Камил Мотыйгый «Тукаев хатирәләре»)

Бу ачуны Тукай Казанга килгәч дә онытмады. Чөнки бу хосуси ачу булмады. 1909 елны Тукай Камил Мотыйгыйга багышлап язган «Төхфәтуллин» урынына «Сибгатуллин»га дигән сәрләүхәле шигырендә болай дип яза:

---

[1] «8 июля Самара оказывается в руках белочехов и Комитета членов учредительного собрания (Комуч), власть советов ликвидируется. События происходят стремительно, К. Тухфатуллин с дочерьми остается в городе. В эти дни, местные татарские националисты начинают издавать газету «Безнең фикер» («Наша мысль»). Камиля, как опытного татарского редактора и газетчика, вынуждают работать в этом издании. Это очень короткий, длиною всего несколько месяцев эпизод очернит всю оставшуюся жизнь Тухфатуллина. До конца своих дней он будет считаться советской власти классово чуждым и ненадежным элементом» (Вафеев Р. Господин Издатель.....С. 212).

[2] Җәяләр эчендә бирелгән сүзләр чыганакта сызылып ташланган.

[3] *Тәһдид кылып* – кисәтеп.

[4] *Ахирел әмер* – иң ахырда.

[5] Мотыйгый Камил. Мәшһүр шагыйрь Габдулла Тукаев турында хатирәләрем // Тукай турында замандашлары. Казан, 1960. Б. 67.

«Бер егет шәмдәй буен катырып[1] йөри,
Алга, дип, милләт, сине чакырып йөри,
Белмисең, милләт, синең хакың өчен
Нинди җырлар ул егет шапырып йөри.
Җаны һәм вөҗданы шул юлда фида,
Кайда бай күрсә, шуңар сатылып йөри.
«Мин мөхәррир һәм дә бик шәп!» дип йөри,
Инде дә, милләт, тәрәккый итмәсәң:
Ресторાннарга кереп акрып йөри.

Моннан да ачыграк итеп, Камил Мотыйгыйга характеристика бирергә мөмкин дә түгел. Тукайның Уральскидагы тарихын тикшергәндә, бу фактларны күрми китәргә булмый. Ә ул фактлар Тукай белән Камил Мотыйгыйның арасын күк белән җирдәй итеп күрсәтәләр.

Бу – мине кызыктырган беренче мәсьәлә.

Мине икенчедән кызыктырган мәсьәлә: бу – Тукайның Уральскига яңа гына килгән еллары. Тукаев Уральскига килгән елларны Уральски белән Саратов шәһәрләре арасында әле яңа гына тимер юлы салынып беткән еллары була. 1894 елны Уральски, Саратов һәм Русиянең башка шәһәрләре белән бәйләнешә. Бөтен Русиядә капитализмның таралуы Азия белән Европаның бусагасында булган бер кечкенә генә мещаннар шәһәре Уральскига да үзенең әсәрен тидерми калмый. Бу вакытларда Уральски казачи войскның 300 еллык юбилее була. Моңар багышлап ясала торган «Алтын чиркәү», храм «Христа Спасителя» ясалып беткән була. Һәм шәһәрнең уртасында өлкән «таш капка» – арка ясалып шәһәрнең тышкы күренешләренә бераз «ямь» кертелә. 1891 елны Уральскиның казачествосы 300 еллык юбилеен үткәзгән бәйрәмгә яшь патша Николай II нче Уральски казакларына кунакка килә. Уральски казаклары, ниһаять, зур бәйрәм ясыйлар. Бу елларда шәһәр кайнап торган сәүдә үзәгенә әйләнә. Төнен шәһәр керосин фонарьлары белән яктыртыла. Өлкән таш биналар ясала. (Кәриев өе һәм башкалар) шәһәрдә сәүдә компанияләре, коммерческий банклар ачыла, зур паровой тегермәннәр (Кәриев – Ыстаров һәм Макаров тегермәннәре) салына. Тимер юл мастерскойлары «Мортаза бай»ның (Гобәйдуллин) күп магазиннары, ыскладлары һәм заводлары ачыла. Мортаза бай Гобәйдуллинның таш мәсҗеде салынып бетә. Уральскида типографияләр ачыла,

[1] Чыганакта: картырып.

эшчеләрнең саны күбәя. Уральскида эре татар байлары белән сәүдә йөртәләр. Мәсәлән, Гобәйдуллинның Берлин һәм Париж банкларына салган капиталлары була. Царизм татар байлары һәм хаҗилары аркылы Казакъстан халкын һәм бөтен Шәрыкны үзенә биләргә бу йирдә күп көч сала. Тукай Уральскига килгән елларны Уральски үзенең яңа салган биналары һәм чиркәү-мәчетләре белән бизәлгән ямьле генә бер шәһәр була. Ләкин, тимер юл салыну сәбәбле, халыкның тормышы бик авырлана. Азык нәрсәләренең хакы күтәрелә. Халык тимер юл килүеннән зарлана башлый. Икмәк, ит, май, балык, тире, җон нәрсәләре кыйбатлана. Халык моңар сыкрана, зарлана.

Уральскига тимер юл килсә дә, халык әле ерак йирләргә барырга туры килгәндә дә ямщик белән файдалана. Казанга баручы-килүчеләр пар атта ямщик белән йөриләр. Бу вакытларны казачийлар Уральскига, ярминкә базарларына күп нәрсәләр китерәләр. Агач табаклар, кашык, чана, тәртә, чабата, чыпта, бал, сабын, шәм, балан, тагы да шундый нәрсәләр ташыйлар. Юл йөрү эшләрен яхшы белгән ямщикчы Сафи абзый Мәҗитов була. Сафи абзый Мәҗитов (халык аңа «Алты-биш Сафи» дип ләкаб[1] исем биргән) урта яшьле, кара чәчле, гайяр[2] һәм шаян кеше булган. Сафи абзый ике хатынлы кеше булып – олы хатыны Нәфисә апа һәм кече хатыны Бибикамал апа үзара бер-бере белән тату яшәгәннәр. Өлкән хатыныннан Фатыйма исемле кызы була. Һәм кече хатыннан Хәким исемле улы була.

Юлда Тукайны алдына утыртып, җылытып килгән Нәфисә апа була.Ул хәзер инде вафат. Бибикамал апа исә шушы көнгә кадәр исән икәне билгеле.

Тукаев 1895 елны Уральскига килү белән, аның җизнәсе Галиәсгар Госманов Габдулла Тукаевны Уральски областында атаклы карт учитель Әхмәдшаһ абзый Сираҗетдинов школына русча укырга бирә. Школда укуның икенче җылындан башлап, Тукай («кичке укуга») Мотыйгый мәдрәсәсенә укырга йөри башлый.

Әхмәдшаһ абзый Сираҗетдинов – Тукайны беренче рәт рус телендә сабак укыткан һәм йаурупача тәрбия биргән остазы. Әхмәдшаһ абзый Сираҗетдинов белән якын танышлыгым булу сәбәбле аның авызыннан Тукай хакында ишеткән сүзләрем күп. Миңа аларның берникадәрен Нәфигов иптәшнең язган мәкаләсенә биргән рецензиямдә күрсәткән идем, сез аның белән таныш. Тукаев

---

[1] *Ләкаб* – кушамат.
[2] *Гайяр* – дәртле, гайрәтле.

Әхмәдшаһ Сираҗетдиновның мәктәбендә укыганда үзен Гарифов дип йөрткән. Гаять дәрәҗәдә зирәк һәм сәляхиятьле[1] шәкерт булып, Әхмәдшаһ Сираҗетдиновның үз файдалануында булган китаплар аркылы рус классикларының әсәрләре белән танышып, үз-үзен онытыр дәрәҗәдә аларны кызыгып укып, хәтта шул көннән башлап, аларны татарчага тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә башлаган. Һәркемгә дә диярлек билгеле, Тукайның Уральскида яза башлаган шигырьләре гарәп-фарсы-төрек сүзләре белән мөнәҗәт формасында языла. Ләкин күп вакыт та үтми Габдулла Тукаев үзенең шигырьләренең формасын үзгәртә. Ул, гарәп-фарсы-төрек сүзләрен ташлап, саф татар телендә яза башлый. Әгәр моның сәбәбләрен тирәнрәк тикшереп карасак, бу эштә Габдулла Тукаевка Әхмәдшаһ Сираҗетдинов иткән күп ярдәмнәрнең җимешләрен күрәбез. Уральскида күп еллар учительлек иткән халык учителе Әхмәдшаһ Сираҗетдинов татар балаларының дөрест сөйләп, дөрес рус телен төшендерү эшләренә күп тырышлык иткән. Саф татар теле өчен көрәшеп, гарәп-фарсы юлын куәтләүчеләргә каршы чыккан. Бу хакта Уральскидагы иске хәлфәләргә зур шелтәләр ясаган (Нури хәлфә Һидиятуллинга һәм башкаларга).

Әхмәдшаһ абзый Сираҗетдинов 1902 елны «Төрки теле» исемендә татар теленең грамматикасын язып бастырып чыгара. Моның өчен муллалар, динчел хәлфәләр Әхмәдшаһ абзыйга каршы «дәгъва»лар куйсалар да, Әхмәдшаһ алардан курыкмый. Бу «Төрки теле» исемендәге китап үз заманында укучыларга татар теленең нигезге кагыйдәләрен төшендереп, рус телен яхшы төшенүдә күп җиңеллекләр тудыра. Шул вакытларда рус телендә саф сөйли торган кешеләр очраса, «бу Әхмәтшаһ укыган кеше булыр» дип халык хөкем иткән. Әхмәдшаһ Сираҗетдинов үзенең «Төрки теле» дигән китабының мөкаддимәсендә болай дип язган: «Мәгълүм улынадыр ки, бу мәсьәләне тәртип кылдык без мөселман балаларының төрки теле белән дөрест сөйләп, дөрест язу эшләрен җиңеләйтү өчен. Шуның өчен дә, Йаурупадагы Русиянең мәшрикъ җанибендәге[2] мөселманнар теленең сарфыны тәртип итеп, үз телемездә рисаләмезгә исем таба алмаенча (төрки теле) дип ләкаб исем куйдык ... Һәркайсы тел, кирәк бай булсын, кирәк ярлы булсын, сарфи булса кирәк дип ... Туган телемезнең сарфыны тәртипкә иҗтиһад

---

[1] *Сәляхиятьле* – сәләтле.

[2] *Мәшрикъ җанибендәге* – көнчыгыш тарафындагы.

иттек[1] ... төрки теленең сарфы безнең Русия мөселманнарының теленә бу вакытка чаклы тәртип кылынганы юк иде... Гарәп вә фарсы телләрен би-кадәрел-имкян[2] кертмәскә тырышып эшләдек... Имде... гыйлем әһеленнән үтенәбез бу рисаләнең хатасы күп булыр, һәр ни булса да, хатасын кичереп тәгълим биргәндә гакылларына муаффәкъ итеп[3], хатасын савап итеп тәгълим биргәйләр иде.

Тәгълим ала торган сабый балаларның күп догаи хәерләрени өмид итеп мөрәттәб[4] мөгаллимес-сыйбъян[5] Әхмәдшаһ бине мелла Сиражетдин Әс-Сарытави»

(Әхмәдшаһ Сиражетдинов, «Төрки теле»,
Казан, 1902 ел, 2–3 нче битләр).

Әхмәдшаһ Сиражетдинов Тукайга саф татар телен дөрес белеп, русчадан татарчага дөрес тәрҗемә итү эшенә өйрәткән остазы дип әйтсәк, яңлыш булмас иде. Мотыйгулла хәзрәт исә – Тукайга күбрәк гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәткән остазы. Ләкин Тукай шул гарәп, фарсы һәм төрек телләренең влияниесеннән тазарылмый торып, саф татар шигърияттен тудыра алмас иде. Тукаев Мотыйгулла хәзрәтнең күп дини сабакларын алса да, күп дини һәм фәлсәфи мәсьәләләрдә аңар каршылыгын изһар иткән. Бигрәк тә Мотыйгулла хәзрәт белән Тукай арасында капитал һәм аның роле мәсьәләләрендә карама-каршы фикердә булганнары да мәгълүм. Тукаев Мотыйгуллалар семьясына каршы чыгышлары белән аларны үзенә каршы куйды. Шуның нәтиҗәсендә, соңгыларның тарафыннан «Тукай фәлән генә, Тукай төгән генә» дигән Тукайны кисметергә теләп әйткән нигезсез сүзләре аз түгел. Хәтта Тукайны «порнография юлына бирелгән шагыйрь» дигән җалалары да юк булмады. Боларның барсы да чеп-чи ки ялган. Һәр хәлдә Тукаевның Мотыйгыйларның кул астында изелеп күргән җәфалары, роман рамкаларыннан чыгып, фаҗигә булырлык дисәң дә ялгыш булмас.

Тукай Уральскида тора башлагач, җизнәсе Галиәсгар Госмановлардан башка да, әнкәсе белән туган апасын таба[6]. Ул кеше Габдерахман Зәбиров дигән кешенең җәмәгате була. Исеме хәте-

---

[1] *Иҗтиһад иттек* – тырышлык күрсәттек.
[2] *Би-кадәрел-имкян* – мөмкин кадәр.
[3] *Муаффәкъ итеп* – ирештереп.
[4] *Мөрәттәб* – төзүче.
[5] *Мөгаллимес-сыйбъян* – балалар укытучысы.
[6] Сүз Газизә Зәбирова турында бара.

ремдә калмаган, ләкин төсе Габдулла Тукаевка гаять тә охшашлы иде. Шул апасының кардәшләре Сафи дигән Чаган суы буенда торган кешеләргә килеп, шулар белән аралашып йөри (бу кеше Сафи Мәҗитов түгел). Сафи абзыйның еш кына диярлек семейный драмасы булгалый. Тукай шуларның барын күреп, аларның тормышына багышлап, бер шигырь яза. Ул шигырьнең хәтеремдә тик аерым җөмләләре генә калган. Мәсәлән:

«...Лампы янмый – кыска икән филтәсе,
Күз ачырмас, Сафи абзыйны талар,
Әллә кайдан фитнә чыгарыр табар...»[1].

Шушы хат белән бергә, Габдулла Тукаевның беренче рәт русча укыган классын һәм учителе Әхмәдшаһ Сираҗетдиновның рәсеменең фотокопиясен йибәрәм[2]. Бу шәкердләр эчендә Габдулла Тукаевны таба алмадым. Ул моннан борынгырак җылларда укыган. Ләкин бу рәсемдә Габдулла Тукаевны бик якын белгән Әхмәдшаһ Сираҗетдинов, Гариф Төхфәтуллин һәм Гарифҗан Кәлтиевләр бар. Икенче фотокопиядә Сираҗетдиновның «Төрки теле» атлы китабының тышы һәм китапның мөкаддимәсе.

Әхмәд иптәш, мондый озын хат язып, вакытыгызны алуым өчен гафу итегез.

«Тукай хакындагы тарихка бер кечкенә генә булса да булышлык итеп булмасмы икән» дигән өмет белән язучы Габдерахман Кәлтиев.

Уральск. 5 нче ноябрь, 1953 ел.

(Бик начар итеп иске, череп беткән хәрефләр белән хат язуыма оялып калам).

Бу хат бәлки бәйрәм көннәрендә тапшырылса, сезне олуг бәйрәм белән тәбрик итеп, эшләрегезгә уңышлыклар теләп калам.

Бу хатның тапшырылганын белсәм, үземне бәхетле санар идем...

Хушыгыз Г.К.

*Хатны, гамәлдәге язуга күчереп, басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре*
*Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

---

[1] Тукайның «Кечкенә генә бер көйле хикәя»сеннән.

[2] Бу фоторәсем Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана (101 ф., 2 тасв., 22 эш). Сыйфаты начар булу сәбәбле басмага бирелмәде.



Г. Кәлтиевнең Ә.Фәйзигә язган хатының соңгы бите. Автограф. 1953 ел, 5 нче ноябрь, Уральск // ЯhMMY, 101 ф., 3 тасв., 123 с.б.

# МӘШҺҮР ШАГЫЙРЬ ГАБДУЛЛА ӘФӘНДЕ ТУКАЕВ ХАКЫНДА ХАТИРӘЛӘРЕМ

Мин бик яхшы беләмен ки, иң әүвәл Габдулла Тукаев үзе шикелле яшь кенә Мөхәммәдгали исемле бер йәтим бала берлә Уральскига Галиәсгар Госманов исемле бер байның өенә килеп төшделәр. Шул вакытда Уральскида мәзкүр байның җәмәгате, Газизә апа, мәрхүм Тукаевка бераз якын тиешле булганга күрә, аларны авылдан тәрбия кыйлырмыз дип, чакырткан дип сөйләнде. Дәрвакыйг[1] Госмановлар боларны ятимнәрнең дәрәҗәменә муафыйк рәвешдә, бәлки артыграк да тәрбия кыйлдылар. Аларны безнең мәдрәсәгә бирделәр. Мин ул вакытда үзем дә яшь идем. Габдулла Тукаев белән яшьлектә арамыз тик дүрт кенә ел чамасы булырга кирәк. Мәдрәсә минем әткәм мөдәррис Мотыйгулла хәзрәт карамагында иде. Ул вакытда безнең мәдрәсәмездә бик күп зур хәлфәләр һәм хәтме көтеп кыйлган[2] пишкадәмнәр бар иде. Шәкердләр арасында мин, әлбәттә, бер зур хәзрәтнең углы булуым сәбәпле, бик күп хөрмәтләргә тиешле булган мәхдүм әфәнде булып күренә идем. Шуның өчен шәкердләр мине үзләренең остазларының баласы дип кенә бик кадерләп йөртәләр иде. Мин шул сәбәпле андый-мондый гына вак-төяк шәкердләргә асла илтифат итми торган идем вә алар белән бер дә катнашмый идем. Яшем уналтыга йиткәч, мине әткәй белән әнкәй, үзара киңәшеп, Казанга Касыйм хәзрәт мәдрәсәсенә йибәрделәр. Әткәй үзе Мисырга барганчы Кышкарда укыган булдыгы сәбәпле, Кышкарга йибәрмәкче булса да, әнкәй: юк инде, минем углым синең кеби авыл мулласының углы түгел, шуның өчен шәһәргә барсын, дип, Казанга йибәрүне артыграк күрделәр. Мин Уральскидан Казанга киткәндә Габдулла әфәнде бер ун яшьләрендәге генә бала иде. Шулай да, мәдрәсәмезгә кереп, сабак укый башлаганына берәр ел булган иде. Аның иң әүвәлге сабак укыткан хәлфәсе Уральскида бу көндә дә сәламәт улан Фәтхеддин хәлфә Рәхмәтуллин булды. Ул иң әүвәл шунардан сабак башлады. Уральскига үзе белән бергә килгән Мөхәммәдгали исемле бала да Габдуллага шәрик[3] булып, шул хәлфәдән укыды. Башдарак болар мәдрәсәгә сабак укырга Госма-

---

[1] *Дәрвакыйг* – чыннан да.
[2] *Хәтме көтеп кыйлган* – мәктәпне тәмамлаган.
[3] *Шәрик* – бергә укучы, иптәш.

новларның өендән һәр көн килеп-китеп кенә йөриләр иде. Бераздан соң өй хуҗасы Галиәсгар Госмановның бердәнбер бик зирәк Гобәйдулла исемле бик шук һәм бик кадерле генә угыллары үлеп киткәч, үз өйләрендән боларны бөтенләй мәдрәсәгә торырга күчерделәр. Ахрысы, болар да Габдулла Тукаевның «Исемдә калганнар» әсәрендәге: «Үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр» дия, авылдагы карендәшләренең Габдулланы үзләрендә асрарга шомландыклары кеби булдылар.

Мәдрәсәгә күчкәч, алар икесе бер тугма кардәшләр кеби, кайда барсалар да икәү генә бергәләшеп йөриләр иде. Болар мәдрәсәдә кайда җитте шунда, җәмәгать сәкеләрендә вә мич араларында кунып торырга башладылар. Габдулланың иптәше Мөхәммәдгали күндәмрәк бала булганга күрә, мәдрәсәгә кергәч дә, башка баерак шәкердләргә самоварлар куярга вә аларның төрле хезмәтләренә йөрергә тотынды һәм аның укуга да бик артык дәрте күренмәде. Шуның өчен ул озакламый мәдрәсәдән дә чыкды. Мәдрәсәдән чыкгач, төрле кешеләргә хезмәтче булып ялланды. Хәзерге көндә ул егет Оренбургта торадыр. Әмма Габдулла әфәнде яшь вакытында ук нечкә табигатьле вә назик күңелле булганга күрә, ул һаман уку артындан йөреп, шунарга бик зур ихлас баглаган иде. Мин Казанга киткәндә ул Фәтхеддин хәлфәдә «Коръән» вә «Тәгълимессалатен» кеби гарәпчә китаплар укып калды. Мин, Казанга барып, бер ел йөреп кайтканда, Габдулла әфәндедә байтак үзгәрешләр күренде. Ул инде русчадан да сабак башлап, Әхмәдша Сираҗеддинов исемле мөселман балаларына вә русча укытучы учительгә йөри башлаган иде. Андан ни өчендер исә бөтенләй тәмам итмәенчә чыкды. Зан галибемчә[1], ул вакытда анарга русчаның бик кирәклеге мәгълүм түгел иде. Һәм дә аңарга ул вакытта бик чынлап бу хосуста үгет вә нәсихәт бирүчеләр дә юк иде. Шунарга күрә ул русчаны үзе теләгәнчә генә укыды. Мин, Казандан кайтып, Уральскида өйләнеп, бер ел тагы үземезнең мәдрәсәмездә маташып, соңра Мисыр, Истамбул шәһәрләренә барып укырга китдем. Ул арада Габдулла әфәнде минем берлә аралаша һәм дә утырдаш була башлаган иде. Мин анарга Әхмәдша учительнең китапханәсендән русча вак-төяк китаплар алып кайтырга вә шулардан файдаланырга тиеш идеге хакында бик күп киңәшләр бирдем. Учитель дә аны

---

[1] *Зан галибемчә* – уйлавымча.

бик ярата вә аның зирәк вә гаять зиһенле бала идегенә исе китә иде. Шуның өчен ул барган саен Габдулланың укырга сораган китапларын бер дә туктатмый биреп җибәрә иде. Шул вакытда Габдулла әфәнде рухы гаять күтәренке дәрәҗәдә иде. Чөнки анарга Гурьевдагы карендәшләрендән дә шактый иганәләр килә башлаган иде. Уральскидагы карендәшләре Госмановлар вә башкалары да әүвәлгечә карашып торалар иде. Аның өстенә минем әткәм ул вакытда Уральскида имам вә ахунд булып торганга күрә, кулындагы русча языла торган барча хезмәтләрне диярлек Габдуллага кушып, шул хезмәтләре өчен анарга мәдрәсәдә бер дә ихтыяҗ күрмәслек дәрәҗәдә акчалар бирә иде.

Шуның өчен шул вакытлардан башлап, Габдулла әфәнде хәзрәткә дә якын кеше булып китү рәвешен алып, мәдрәсәдәге шәкердләр арасында да игътибарлы була башлады. Бу вакытларда Габдулланың кәефе бик шат вә һәркемдән мөстәгъни[1] булып, җырлый-җырлый үзе теләгәнчә торырга тотынган иде. Җәй көннәрендә кузна уйнау, оҗмия[2] очырту вә түбә өстләрендә уйнау илә шөгыльләнеп, кыш көннәрендә мәдрәсәдәге атнакич уеннарында кубыз уйнап вә берничә төрле җырлар җырлап маташа иде.

Габдулла әфәнде һәрнәрсәгә дә бик игътибар вә дикъкать берлә карарга өйрәнгән иде. Шул сәбәпле ул башка кешеләрдә булган гадәтләрне бик тиз отып ала торган иде. Кувәи мөхафәзәсе[3] дә ифрат дәрәҗәсендә мәхкәм[4] рәвештә иде, ни генә ишетсә дә ул аны бик озак онытмый торган иде. Җитешлекләр анарда бик мул булганга күрә, ул бик тизлек илә алга китде. Мин Мисырдан әйләнеп кайтканда ул тәмам зур егет кыяфәтенә кергән иде. Аннан соңра шул кыяфәт аңарда үлгәнчегә кадәр һич үзгәрмәде. Мисырдан кайткач да, мин үз мәдрәсәбездә һәртөрле фәннәрдән дәрес әйтә башладым. Ләкин бу вакытларда мәдрәсәбездә шактый үзгәрүләр бар иде. Мәдрәсәбезгә Оренбург вилаятендән Нуриәхмәд исемле бер ысуле җәдидә мөгаллиме килү сәбәпле иске хәлфәләрдә укый торган барча кечкенә шәкердләр шул мөгаллимгә күчкәннәр иде. Шуның өчен иске хәлфәләр арасында байтак низаглар булып, мәдрәсәбездәге бик күп зур шәкердләр мәдрәсәбезнең идарәсенә

---

[1] *Мөстәгъни* – бәйсез.
[2] *Оҗмия* – кәгазъ очырткыч.
[3] *Кувәи мөхафәзәсе* – ятлау куәте, хәтер дәрәҗәсе.
[4] *Мәхкәм* – нык, көчле.

вә хосусан бу эшкә мөсагадә[1] бирүче әткәм Мотыйгулла хәзрәткә ачигъланып, үзләренчә забастовка ясап, мәдрәсәдән чыгып киткәнләр иде исә дә, калган шәкердләр дә байтак бар иде. Менә мин шул калган шәкердләрнең бәгъзесенә нәхү, мантыйк, хәдис, тәфсир һәм дә фикъһе вә яңа әдәбият гарәбиядән дәресләр бирә башладым. Габдулла әфәнде шул вакытларда минем иң сөекле вә миңа иң артык ихлас баглаучы шәкерд булып китте.

Мин мәдрәсәдә вакытда ул даимән минем янда гына ултыра иде. Минем агыздан ни чыкса, шуны хәзер отып алырга вә хифыз[2] кылырга тора иде. Миннән ул ялгызы гына дәрескә утырып, тәфсире «Җәлалин» вә хәдис «Сәхихел-Бохари» һәм дә әдәбият гарәбия укыды. Бонларга башка мәдрәсәдәге әткәм хәзрәтнең дәресләренә вә мәдрәсәбездә карт хәлфә улан мәрхүм Сираҗеддин хәлфә дәресләренә ултыра иде. Әткәем хәзрәт гыйльме гаруз[3] китапларында дәрес бирә вә бунарга Габдулла әфәнде бик иҗтиһад берлә дәвам итә иде. Бу дәресләр илә генә кифаяләнмичә, Габдулла әфәнде минем өйгә йөреп, миндән гыйльме кыйраәт вә Мисыр мәкаме[4] дә өйрәнде.

Шул вакытта минем төркичә вә гарәпчә җырлар җырлаганымны да бик ихлас берлә тыңлап тора иде. Һәм дә миңа килә торган һәртөрле гарәпчә вә төркичә язылган гәзитә вә журналларны укып файдалана иде.

1905 елны мин, Уральскида матбага алып, татарча гәзитәләр чыгарырга уйлагач, Габдулла әфәнде, үзенең үтенүе буенча, минем матбагама хәреф тезәргә (наборщиклекгә) керде. Матбагада иң әүвәл русча вә мөселманча хәрефләр тезәргә өйрәнде. Соңра, мин шул елны 27 нче ноябрьдән башлап, «Фикер» исемле гәзитә чыгара башлагач, аны шул гәзитәгә мөсәххих[5] итеп куйдым. Габдулла әфәнденең хезмәтләре миңа бик ягымлы һәм дә үзе фәүкыльгадә[6] иҗтиһадлы булганга күрә, мин аның жалуньясене һәр ай саен арттыра бара идем. Шөйлә ки, иң әүвәл сигез сумга хезмәт итә башлап, соңыннан бик тиз айга егерме биш сум ала башлады. «Фикер» гәзитәсенең иң әүвәлге номерында аның әүвәлдән

---

[1] *Мөсагадә* – булышу, ярдәм.
[2] *Хифыз* – ятлау.
[3] *Гыйльме гаруз* – шигырь үлчәве турындагы белем.
[4] *Мәкаме* – көе, мотивы.
[5] *Мөсәххих* – корректор.
[6] *Фәүкыльгадә* – гадәттән тыш.

хәзерләп куйган, русчадан тәрҗемә кыйлып язган «Ник йоклыйсың, мужик?» исемле шигыре басылып чыкды. Соңра, 1906 ел башында, мин «Әлгасрелҗәдит» журналы чыгара башладым. Аның да иң әүвәлге номерында Габдулла Тукаевның «Алла гыйшкына» исемле шигыре басылды. Мәзкүр ел ахырында «Уклар» нам һөҗү журналы чыгара башладыгымда анарга да Габдулла Тукаев күп шигырьләр чыгарып бастырды. Шулай итә-итә акрынлап, Габдулла Тукаев минем матбагамда иң әүвәл наборщик булып кергән дәрәҗәсендән мөсәххихлек дәрәҗәсенә менеп, соңра бик тизлек илә шул матбагада басыла торган «Фикер», «Әлгасрелҗәдит» вә «Уклар» исемле гәзитә-журналларның иң моктәдир[1] шагыйре вә мөхәррире дәрәҗәләренә ирешеп, бөтен эшне үз кулына алырга якынлашды.

1907 елның февраль аенда минем матбагам, берничә дошманлар доносы сәбәпле, мәхәлли хөкүмәт мәэмүрләренең әмерилә, аларның миндә бер гаеп табулары сәбәпле ябылып, гәзитә вә журналларым туктатылып вә үзем мәхкәмәгә шул гаеп эше тугрысында хөкем кылынырга тартылдым. Бу эшнең ни нәрсә тугрысында булдыгы бик күп гәзитә укучыларына мәгълүм булганга күрә, бу урында аны тәфсыйлән язуның хаҗәте булмаса кирәк. Минем матбагалар ябылып, гәзитә вә журналларым туктатылган вакытда Габдулла Тукаев, мәдрәсәдән чыгып, Уральскида шул вакытта мөселманнар тарафыннан тотылмакда булган, бик шәп «Казан миһманханәсе» номерларында үзенә бер хосусый номер алып тора башлаган иде.

Инде ул бу вакытларда үзенең кием-салым җәһәтләрен дә хили[2] башкартмыш иде. Мәдрәсәдә вакытта кия торган бүрек вә яки фәсләрне бер якка ташлап, башына кепка киеп, кулга таяк тотып, берәүдән дә курыкмый торган формада йөри иде.

Инде ул тәмәкене дә мәдрәсәдә яткан вакытындагы кеби кешедән качырам дип, ашханәләргә төшеп яки чормаларга менеп тартмый, бәлки теләсә кем алдында рәхәтләнеп тарта иде. Бәгъзе вакытында Толстойча булсын дип, аягына чабата киеп, күлмәкчән генә вә биленә билбау бәйләп вә өстенә җилән генә салып җибәрә торган иде. Толстойга вә башка мәшһүррәк адәмләргә охшарга тырышу Габдулла әфәндедә бик куәтле дәрәҗәдә иде. Шуның

---

[1] *Моктәдир* – көчле, сәләтле.

[2] *Хили* – байтак.

өчен ул шул елларда модада булган, эшчеләрне забастовкаларга котыртучылар мәзһәбенә дә кереп китеп, минем матбагада булган барча эшчеләрне дә миннән жалунье арттыруны сорап, эш ташларга котыртты. Бу хосусда мин, Габдулла әфәндenең бу эшен сизеп, берничә мәртәбә тәһдид кылып куйсам да, файда бирмәде. Ул һаман үзенең котыртуында дәвам итте. Шуның өчен ахирел әмир аны матбагадан (матбагам ябылмастан борын, ике атна гына әүвәл) бөтенләй хезмәтдән чыгарырга тугры килде. Бу эш минемчә бик урынлы булып күренде исә дә, Габдулла әфәндегә бик каты тәэсир әйләмеш иде. Ул шуның өчен үлгәнчә миңа ачуланып һәм кәефе китеп йөрде. Шул ачудан булмалыдыр ки, минем матбагам илә гәзитә вә журналларымны дәвам иттерергә алучы байларга Габдулла Тукаев: «Инде сез Камилне идарәңезгә хезмәт итәргә алмасагыз да ярар, чөнки ул матбагасы үзендә вакытда да бернәрсәгә дә катнашмый иде, бөтен хезмәтләрен мин генә карыйдыр идем», – димешдер. Шул сәбәпле, матбага миндән күчкәч, яңа идарәдә мин хезмәт итә алмадым. Ләкин матбага аларның кулына күчү берлә озакга бара алмады. Байларның хезмәтчеләренә кәефләре китү сәбәпле, эшне бик тиз арада үз ихтыярлары илә бөтенләй туктатып куйдылар. Шундан соңра аларга хитабән Габдулла Тукаев «Матбага берлә уйнаучы бер байга» исемле шигырен язды.

**Матбага берлә уйнаган бер байга:**

Булды кондыз, аслы үзгәрде диеп мин күрсәм үз, –
Хәзрәтеңне белмәдем! – Дуңгыз икәнсең син һәнүз[1] !

Матбага алгач, сине инсане галидер[2] дисәм, –
Кайда галилек сиңа, хали[3] икәнсең син һәнүз!

Тугры юлны тапды бу, тәүфикъ имеш, ярый, дисәм, –
Лотфе Хактан[4] пакь икән, гари[5] икәнсең син һәнүз!

---

[1] *Һәнүз* – һаман.
[2] *Инсане гали* – бөек кеше.
[3] *Хали* – буш.
[4] *Лотфе Хактан* – Алла рәхмәтеннән.
[5] *Гари* – ялангач, шәрә.

Гыйльмә нашир[1] булды бу, яхшы кеше булды, дисәм, –
Нәйләем[2] ки, бик кабих[3], шакшы икәнсең син һәнүз!

Бу сәхи[4], бер бай кеше тәкмил итәр[5] барын, дисәм, –
Бер хәсис, мәгърур икән, карун икәнсең син һәнүз.

Бу ганидер[6], милләтә ярдәм вә гаүнәйләр[7], дисәм, –
Иске Нәмруд, Самри, Фиргавен икәнсең син һәнүз!

«Белдем инде милләтең дәрден», – дисең, борчак атып, –
Файдасы юк бер хәрам корсак икәнсең син һәнүз!

Туктале, бер көн килер дә, өйрәтер, әлбәт, ләхет, –
Миллионың ул тар ләхеттә файда бирмәс, бәдбәхет!

Бу кадәр зур, галишан милләт белән ник уйнадың?.. –
Ахыры, син милләти каткан тирең дип уйладың!

Туктале, алдыңда, дуст, мәхшәр дә бардыр, суд да бар, –
Каһре Хак бар; тиз янар корсагың – анда ут да бар!

Анда хакимнәр дә алтыннарга һич алданмыйлар;
Анда адвокат да юктыр, – акчага ялланмыйлар.

И аягың коргыры! Намусымызны таптадың;
Золмәтеңнең [8] хөрмәтенә шәмсемезне[9] капладың.

Син үзең сүнсәң сүнәрсең, бу кояш сүнмәс әле;
Ул мөкаддәс, залимең әмренә[10] тиз күнмәс әле.

Ташла тиз! Пычратма матбугатны, кит! Бер якга кит!
И печән өстендә өргән һәм талашып яткан эт!

Г.Т.

Дәһи матбага тотдыгым вакытда минем Уральск шәһәрендә бик могтәбәр улан «Прогресс» исемле китап магазиным бар иде.

---

[1] *Гыйльмә нашир* – гыйлем таратучы.
[2] *Нәйләем* (нә әйләем) – нишлим, ни хәл итим.
[3] *Кабих* – кабахәт.
[4] *Сәхи* – юмарт.
[5] *Тәкмил итү* – төгәлләү, җитештерү.
[6] *Гани* – бай.
[7] *Гаүнәйләр* (гавен әйләр) – ярдәм итәр.
[8] *Золмәт* – караңгылык.
[9] *Шәмс* – кояш.
[10] *Залимең әмренә* – явызның боерыгына.

Ул магазиным да матбагам ябылган вакытда ябылды. Шундан Габдулла әфәнде җаны теләгән кадәр русча китапларны алып укый иде. Крылов, Пушкин һәм Лермонтов кеби рус әдипләренең бөек әсәрләре илә Габдулла Тукаев бигрәк дә шул магазин аркылы танышды. Мәзкүр әсәрләр илә файдаландыгы өчен Габдулла әфәнде ул вакытда минем идарәдә хезмәт итүче булганга күрә асла хак да алынмый иде.

1907 елның май аенда, минем матбагамны алучы байлар да эшләрен туктаткач, Габдулла Тукаев бер эшсез калды. Бу вакытда аның янына Уральскиның Гайнеддин кари мәдрәсәсендә укып ятучы Габдулла Хәйруллин (хәзерге «Сәйяр» труппасының башлыгы Габдулла Кариев) күчеп, икесе бергә бер номерда тора башлаганнар иде. Минем китап магазиным ябылгач, мин барча китапларымны шул Габдулла Хәйруллинга (Кариев) сатарга биргән идем, шундан килгән табыш һәм сумманы ике Габдулла, бергәләшеп, июль ахырларына кадәр ашап ятдылар. Мин бу эшне бик яхшы белсәм дә һәм шул вакытларда Тукаев берлә арамызда суыклык булса да, асла әһәмият бирмәдем. Июль ахырларында Габдулла Хәйруллин (Кариев) минем Уральскида сатып бетерә алмаган китапларны сатарга Мәкәрҗәгә алып китде, анда һәм бу китаплардан яхшы гына файда күрде. Шул елны ул китап сәүдәсендән яхшы гына акчалар хасил итеп, Ашказарский тарафындан төзелгән «Сәйяр» труппасына кушылып, соңрадан шул труппага хәзерге баш булып китде.

Әмма Габдулла Тукаев шул елны иптәше Габдулла Хәйруллиндан (Кариев) аерылгач, Уральскида бер ике-өч ай чамасы торып, соңра солдат хезмәтенә каралырга дийә, үзенең Казан губернасындагы туган иленә кайтып китде. Шул китешдән ул Уральскига кире әйләнеп кайтмады, солдат хезмәтенә каралып, ул хезмәткә ярамаслык булу сәбәпле котылып калгач, Казан шәһәренә килеп, «Болгар» номерларында тора башлады. Габдулла Тукаевның бондан соңгы булган хәлләрене инде Казанда булган иптәшләре язар. Минем аның хакында исемдә калганнар ошбу кадәр илә тәмам булды.

И шагыйрь! Габдулла маһир җанымыз
Үлсәң үлдең, рәхәт үлдең, инде калды шаныңыз.

Мөхәммәдкамил Мотыйгый
Төхфәтуллин.

# Г. ТУКАЙНЫҢ БЕР ФОТОРӘСЕМЕ ТАРИХЫНА КАРАТА

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондларында Г. Тукайның фоторәсемнәре шактый. Алар хакында мәгълүмат матбугатта инде басылып та чыкты[1].

Фоторәсемнәр арасында шагыйрьнең түгәрәк йөзле, түбәтәй һәм галстуктан төшкән сурәте шактый кызыклы. Төрле открыткалар, җыентыклар, альбомнар, мәктәп өчен дәреслекләрдә кат-кат басылган әлеге фоторәсем С.И. Иванов фотостудиясендә төшерелә. Семён Иванович Иванов – XX гасыр башында Казан шәһәренең Покровский урамындагы Л.И. Пальчикова йортында урнашкан (хәзерге Лобачевский һәм К. Маркс урамнары кисешендәге йорт) фотостудия хуҗасы. Г. Тукайның бу фоторәсемгә төшү датасы төрле чыганакта төрлечә күрсәтелә: кайбер язмаларда 1908 ел дип билгеләнсә[2], икенчеләрендә 1909 ел тора[3]; әдәбиятта шагыйрьнең бу фоторәсемендә башка кешенең сурәте, дигән версия дә очрый[4].

Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондларында әлеге фоторәсемнең ике нөсхәсе саклана. Ике нөсхәнең артында да шагыйрьнең үз кулы белән язган сүзләр бар. Кульъязмадан күренгәнчә, берсе, шагыйрьнең дусты Габделкаюм Мостакаевка бүләк ителгән – «Габделкаюм әфәндегә ядкяр. 1909 сәнә, 12 июль. Габдулла Тукаев»[5], икенчесе – В. Апанаевка истәлеге : «Иптәшем Вәли Апанаевка ядкяр. Г. Тукаев. 17 нче июль 1909 сәнә»[6].

Фондларда шулай ук К. Мостакаевның үзенә бүләк ителгән фоторәсем артындагы язмага аңлатмасы һәм шагыйрь Г. Тукай турында берничә хатирәсе саклана. 1946 елның 23 февралендә язып

---

[1] Исламов Р.Ф. Тукайның ничә фотосы бар? // Мәдәни җомга. 2015. 10, 17, 24 апрель.

[2] Габдулла Тукай. Фотоальбом. Казан, 1978. Б. 67; Ядкярләрдә – Тукай рухы: Татарстан Республикасы Милли музее җыелмасында татар халык шагыйре Габдулла Тукайның мемориаль тупланмасы каталогы. Казан, 2012. Б. 88.

[3] Исламов Р.Ф. Тукайның ничә фотосы бар? // Мәдәни җомга. 2015. 10 апрель.

[4] Әхмәрова Н. Без дә шагыйрьне күреп калдык // Тукай турында истәлекләр. Казан, 1986, Б. 207; Фридерих М. Габдулла Тукай, как объект идеологической борьбы / пер. с нем. И.А. Гилязова. Казан, 2011. Б. 87.

[5] ЯһММҮ, 9 ф., 3 тасв., 27 с.б.

[6] ЯһММҮ, 89 ф., 4 тасв., 84 с.б.

тәмамланган «Тукай турында исемдә калганнар»ның кыскартылган варианты «Тукай турында замандашлары» исемле җыентыкта басылган[1]. Монда Г. Тукайның татар кәләпүше киеп төшкән фоторәсеме тарихы да кыскача бәян ителә. Хатирәнең авторы (К. Мостакаев) билгеләгәнчә, бу 1909 елның җәй айларында була: «Исемдә калганнар» исемле автобиографик повестен язу белән мәшгуль[2] Тукайны аның янына килгән Гыйльметдин Шәрәф фоторәсемгә төшәргә чакыра.

Бирелә Г. Тукайның дусты К. Мостакаевка бүләк иткән фоторәсеменең алгы һәм арткы ягы, «Тукай турында исемдә калганнар» исемле хатирәдән өземтә (факсимилесы белән) һәм Г. Мостакаевның үз кулы белән язган, Г. Тукай фоторәсеме тарихы турында «Аңлатма»сы (факсимилесы белән) тәкъдим ителә.




Г. Тукайның К. Мостакаевка бүләк иткән фоторәсеме. 1909 ел, 12 июль // ЯһММҮ, 9 ф., 3 тасв., 27 с.б.




Г. Тукайның К. Моставаевка бүләк иткән фоторәсемнең арты. Шагыйрьнең үз кулы белән «Мөхтәрәм Габделкаюм әфәндегә ядкяр. 1909 сәнә 12 нче июль. Габдулла Тукаев» дип язган сүзләре // ЯһММҮ, 9 ф., 3 тасв., 27 с.б.

---

[1] Тукай турында замандашлары / төз. С. Исәнбәй. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. Б. 122–128.

[2] Әсәрнең кереш өлеше 1909 елның 29 сентябрендә язылып тәмамлана, ә 12 ноябрьдә «Исемдә калганнар» исеме белән Казанда, «Үрнәк» матбагасында шагыйрьнең әлеге фотосурәте белән басылып чыга.

## Габделкаюм Мостакаевның «Тукай турында исемдә калганнар»ыннан

*1946 елның 23 феврале*

...[Г. Шәрәф] «Тукай, я хәзерлән әле, хәзер фотографиягә барып киләбез», – дип сүз башлады.

Тукай, шаяру сүзләре сөйли-сөйли, көзге каршына басып «хәзинәдә бар» киемнәрен рәтләп киенгәч, өчәүләп Черек күл башындагы фотографиягә барып чыктык.

Художник Тукайны эскәмиягә утырткач, Гыйльми башындагы салам эшләпәсе эченнән татар кәләпүше алып, Тукайның башына киертте... Тукай:

– Мин яланбаш булуны теләр идем, – диюгә каршы[1].

– Юк, болай аруырак булыр, – диде. Шуннан аппаратны рәтләп маташкан художник янына барып, аңар «нәрсәдер» сөйләнеп үтте. Бу вакыт эскәмиягә утырган Тукай: «Гыйльми нәрсәдер шәрәфли...», – дип куйды.

Рәсемнәрне алып кайтканнан соң, чынлап та, Гыйльминең монда да азрак «шәрәфләгәнлеге» аңлашылды ...

Аның художник колак төбенә барып пышылдавы «син инде рәсемне тулырак – күперенкерәк итеп чыгар...» диюдән гыйбарәт булган икән ...

Шулай да Тукай үзенең бу рәсемен яратты. Номерга кайткач, өстәл кырыена утырып, иркенләп карый башлавына, беренче сүзе:

– Татар кызлары мине шундый «шишман[2]» кыяфәттән күргәч тилмерәләр инде!.. – диюдән гыйбарәт булды[3] [...]

---

[1] Бу күренешкә сәерче (күзәтүче) булып торган миңа калса да, Тукай яланбаш төшкәндә аның рәсеме тагын да матуррак булып чыгар төсле тоела иде, чөнки Тукай үзенең ул рәсемендә күпертелгән кадәр үк тулы булмаса да, шушыңа якын бер кыяфәттә ачык йөзле булу өстенә көдрәләнеп торган «шатенка» чәчләре дә бик күңелле булып күзгә чагыла иде (*К. Мостакаев иск.).*

[2] *Шишман* – таза, симез.

[3] Мостакаев К. Тукай турында исемдә калганнар // ЯһММҮ, 9 ф., 4 тасв., 82 с.б. (Б. 16)

## Г. Мостакаевның үзендә сакланган Г. Тукай фоторәсеме тарихы турында «Аңлатма»сы

*1962 елның 9 гыйнвары*

Аңлатма

Г. Тукай әсәрләре өстендә эшләүче кайбер иптәшләр Тукайның 1909 елда миңа истәлек итеп биргән фотокарточкасының артына язылган сүзләр ни өчен карандаш белән аркылы-торкылы сызгаланган, дип сорыйлар.

Г. Тукайның 75 еллыгы уңае белән нәшер ителгән «Тукай турында замандашлары» дип аталган китапта Тукайның бу – башына татар кәләпүше киеп төшкән рәсеме – кемнең димләве буенча, кайда, ничек һәм ни рәвешле итеп алдырылганлыгын аерым ачык итеп язган идем. Шунлыктан бу турында аны кабатлауны кирәксенмәдем.

...Билгеләнгән вакытта без, Тукай белән бергә барып, бу фотокарточканы алып кайткач та, Тукай беренче буларак, мәгълүм сүзләрне карточка артына язып, миңа бүләк итте һәм ул түбәндә язылганча шул көнгә чаклы сакланып килде дә.

1932 елны, ягъни «шәхес культы» гомуми бер афәт төсен алып тирәнләнә һәм киңәя барган чорда, мин дә шул афәтнең упкынына эләктем: караңгы төннәрнең берендә мине дә татлы йокымнан уятып алып, миңа караган барлык әйберләремне актарып ташладылар... Ниһаять, күп еллар буенча җыйналып килгән ярыйсы гына бай көтепханәмдәге китапларымны йөк машинасына «дыңгычлап тутырып» беткәч, үземне дә шул күз алмасыдай кадерле китапларым өстенә утыртып алып киткән чакта, күп төрле кулъязма әсәрләр, хатлар, фотокарточкалар белән беррәттән, Тукайның да күп еллар буенча җаным кебек саклап килгән хатларын һәм дә рәсемнәрен кычкыртып алып киткәннәр иде...

(...Почет грамотасы белән бүләкләнеп, котылып кайткач, бу әйберләрнең кайтарылып бирелүен берничә кат таләп итсәм дә, «хәзергә алар кайтарылмыйлар...», – диделәр.

Ниһаять, реабилитацияләнгәч кабат шуларның кайтарылуларын, һич булмаса кулъязмаларым, фотокарточкаларның кайтарылуларын таләп иткәндә: «Барысы да яндырылдылар» – дип, җавап бирделәр).

Г. Тукайның бу – башына кәләпүш киеп төшкән рәсеме башка бер урында, ягъни чормада сакланган китап-журналлар һәм



К. Мостакаев аңлатмасының беренче бите. Автограф // ЯhММУ, 9 ф., 3 тасв.. 27 с.б.



К. Мостакаев аңлатмасының икенче һәм өченче битләре. Автограф // ЯһММҮ, 9 ф., 3 тасв., 27 с.б.

кайбер кулъязмалар арасына туры килеп, шулар белән бергә саклангалыктан, «тоткынлыкка дучар ителә алмый» котылып калган иде. Соңынтын тормыш иптәшем әнә шул рәвешле сакланып кала алган китап-журналлар 1905 елда Тифлистә чыгарыла башлап, күп еллар дәвам иткән «Мулла Насретдин» һәм Бакуда чыгарылып туктатылган «Фәюзат», «Яңа Фәюзат» журналлары, Касыйм хан һәм ханзадәләренең Вельяминов-Зернов тарафыннан нык тикшерелеп язылган тарихы һәм башка шуларга ошаулы кадерле китаплар: 1945 һәм 1955 елларда боларның барысын да филиалга тапшырдым һәм кулъязма әйберләрне барлаган вакытта Тукайның шушы рәсеме дә килеп чыккан. Мин кулга алынган чакта бер читтә «җанын учына йомарлап» качынып торган 4–5 яшьлек балабыз моның Тукай рәсеме икәнен әнкәсеннән белеп алгач, читкәрәк авышып китеп кулына карандаш алган да, артына язылган язмаларны сызгалап ташлаган һәм әнкәсе катына килеп:

– Әни, төнлә белән килеп әтине, китапларыбызны алып киткән усал абыйлар тагын шулай килә калсалар, Тукай абый

карточкасының артына язылган сүзләрне укый алмасыннар дип, менә мин ул язуны сызгалап бетердем, дигән бала...

Фотокарточка артына язылган сүзләрнең ни өчен сызгаланган булуның сәбәбе әнә шуңардан гыйбарәт.

*Каюм Мостакаев*
9 нчы гыйнвар, 1962 нче ел.

*Кереш сүзне, текстларны, гамәлдәге язуга күчереп, басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## ВАФА БӘХТИЯРОВ ИСТӘЛЕГЕ

*Вафа Гали улы Бәхтияров (1881–1960) – 1907–1909 елларда Казанда чыккан гыйльми-әдәби атналык Әлислах» газетасының рәсми редакторы һәм нашире, Г. Тукайның якын дусты.*

*1985 елны Казанда Вафа Бәхтияровның хатыны Разия апа белән очрашу булды. Ул безгә Вафа Бәхтияровның сакланып калган кайбер язма истәлекләрен тапшырды. Алар арасында шагыйребез Г. Тукайга да багышланганнары бар. Бүгенге көндә әлеге мирас Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИнең ЯһММҮендә саклана (42 ф., 1 тасв., 15 эш).*

### Г. Тукаев турында

I

Тукайның күп торган урыны «Болгар» номерасы булды.

«Болгар» номерасы Татарстан белән Мәскәү урамнары чатындагы 14/59 йортның Татарстан урамына караган якта почмактагы 3 нче тәрәзә, 40 нчы бүлмә – номер булды. Шул ук «Болгар»да урнашкан «Әлислах» газетасында 7, 8, 9 елларда эшләде. Бу яшьләр органы «Әлислах» газетасы Тукай (һәм) Париж коммунасы урамнары чатындагы 37 йортта Кәримовлар типографиясендә басылды.

II

8 нче елның июль аенда яшьләр органы «Әлислах» газетасы редакциясе хәзерге Тукай урамы 63 нче номер йортка күчте. Тукай биредә дә бик бирелеп эшләде.

III

1907 елда ноябрь, декабрь, 8 нче елның январь айларында Тукай хәзерге Париж коммунасы урамы, йорт номеры 9 «Сарай» номерасында 14 нче бүлмә-номерда торды. Монда торуны яратмады,

яңадан «Болгар» номерасына 40 нчы бүлмәгә күчте. (Бу йорт хәзер дә бар. Автогаражга каршы, 3 катлы йорт).

8–9 нчы елларның җәй айларында, хәзерге Һади Такташ урамы Литовченко йортында бер катлы агач йортта – дача итеп Ф. Әмирхан, Тукай, Бәхтияров бергә өчәү тордык.

IV

8 нче елның көзендә Г. Камал тарафыннан юмористик «Яшен» чыгарыла. Тукай бу юмористик журналда бик актив катнашты. «Яшен» туктатылды. «Яшен» журналы урынына «Ялт-Йолт» журналы чыгарылды. Тукай бу журналда да актив рәвештә катнашты. Бу ике юмористик журналның редакциясе «Болгар» номерасында Мәскәү урамы ягында 18 нче бүлмәдә булды. Бу ике журнал Харитонов типографиясендә басылды.

1909, 10, 11 елларда Тукай Г. Дәүләтшиннең «Китап» нәшриятында корректор, экспедитор булып эшләде.

Бу издательство Мәскәү урамы, 52 нче номерлы йорт, 7 нче бүлмәдә булды. Бу йорт хәзер дә бар.

1913 нче елда Тукай каты авырый башлый. Эшли алмас хәлгә килә. Иптәшләре хәзерге Островский, Международный урамнары чатында 6/11 урнашкан Клячкин больницасына урнаштыралар. Клячкин больницасында бераз ята һәм шунда үлә. Хәзер бу больница урынында «Акушерская».

Карт учитель Вафа Бәхтияров
1957, 29 март.

*Вафа Бәхтияров кәгазьләре арасыннан Тукайга багышланган икенче язманы да бу урында тулы килеш китерәбез.*

«1908 нче ел, март ахырларында Тукай экономик яктан авыр хәлгә төшә, «Әлислах» идарәсе ярдәм итә алмый. Шагыйрьнең якын иптәшләре «Болгар»дан Тукайны Кабан күленең уң ягында шушы йортта торучы (уң яктан 1–2 тәрәзәләрдә) частный прачка бер рус хатыны фатирының бер бүлмәсенә урнаштыралар. Монда Тукайга бик күңелсез була, иптәшләреннән бөтенләй аерыла. Янына баручылар булмый. Бер көн Сәгыйть Рәмиев Тукайны безнең Дальний Архангельский урамындагы (хәзерге Лазовский урамы) Ботанический садка каршы безнең фатирга алып килә. Тукай берничә көн тора. Без бер бүлмәбезгә Тукайны урнаштырмакчы булдык. Тукайның әйберләрен алырга барылса, фатир хуҗасы күчеп, үзе

белән Тукайның бөтен әйберләрен алып киткән. Тукай бөтен әйберләреннән мәхрүм кала. Бары тик өстендәге бер пальтосы гына кала.

Вафа Бәхтияров
1.07. 1944».

*Вафа Бәхтияровның «Милли моңнар» шигыре язылу тарихына кагылышлы мәкаләсе:*

## «Милли моңнар»

1908 елның декабрь аеның ахыргы көннәрендә Хөсәен Әбүзәрев (таңчы, «Таң мәҗмугасе»нең редакторы) Москвадан кайту мөнәсәбәте белән, үзенең квартирасында (Дегтярный урамында, хәзер ул йорт урынында бакча) яшьләр мәҗлесе ясый. Шул мәҗлестә ислахчылардан Фатих, Тукай, Вафа була. Таңчылардан шагыйрь Сәгыйть абзый Рәмиев һәм өч-дүрт казак, кыргыз укучыстудентлар бар иде. Мәҗлес табыны бик мул итеп хәзерләнгән. Мәҗлес җанланды, шау-шу, үзара сөйләшүләр башланды. Мәҗлес күңелле, җанлы, рухлы рәвештә бара. Мәҗлестә булганнардан бары тик Сәгыйть абзый Рәмиев кенә әллә ничек күңелсез, рухсыз хәлдә утыра. Ул гына бер кем белән сөйләшми, дәшми, утырган урныннан торып, идән буйлап йөри, тагын килеп утыра, тагын торып йөри... Шул арада, мәҗлес хуҗасы Хөсәен абзый Әбүзәрев тарафыннан тагын рюмкаларны күтәрергә, чәкештерергә тәкъдим ителә. Сәгыйть абзый да урынына утырып, рюмкасын күтәрә дә, тагын урыныннан торып йөрергә тотына. Шул арада Сәгыйть үзе утыра торган урындыкның артына килеп баса. Башын урындык башына куя, тагын күтәрелә, тагын куя... Шул арада янәдән аякка басып, башын югары күтәреп, чәчен кулы белән артка сыпырып, ике кулы белән утыргычның артына тотынып, иң әүвәл кыска көйгә «Әминә, гүзәлем» җырын җырлап җибәрә. Мәҗлес халкына бик ошый. Шау килеп кул чабалар. Искиткеч бер гайрәт, көч, дәрт, йөрәк белән үзенең «Аллам» шигырен «Ашказар» көенә җырлый.

«Ашказар»дан соң акыллар хәйран булырлык көч, дәрт, йөрәк белән «Әллүки» җырын башкара.

Сәгыйть абзыйның «Ашказар», «Әллүки» көйләрен җырлаган чакта мәҗлестә булган шау-шулар, сөйләшүләр, ашау-эчүләр онытылды. Мәҗлес тынып калды. Һәркем тирән уйга калды. Мәҗлес халкының кайберәүләре ике кулы белән өстәлгә таянып тора, кайсы Сәгыйть абзыйга карап, хәйран булып тора. Кайсы өстәлгә башын куеп тыңлап тора.

Кыскасы: мәҗлестә булган бөтен халык, икенче галәмгә киткән хәлдә, икенче төрле әйткәндә, адәм баласы белми, яхуд аңлап җитми торган бер исерү белән исерәләр. Хәтта татар көйләреннән ямь-тәм тапмый торгандыр дип уйланган йорт хуҗасы карт рус Сергеев та утырган урыныннан торып, Сәгыйть абзый янына барып, Сәгыйтьне аркасыннан сөеп, маңгаеннан үбеп җибәрә.

Сәгыйть абзый җырлап бетергәч тә, мәҗлестә булган тынлык берничә минутка кадәр дәвам итә. Сәгыйть абзый «Ашказар», «Әллүки» җырларын җырлаган вакытта Тукай, башын бер югары күтәрә, бер түбән төшерә, бер артка китә, бер алга килә, бизгәк тоткан авыру кеше кебек үз-үзен тота алмаган хәлдә үткәрде.

Бу Әбүзәревларның мәҗлесе, мәҗлестә шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең искиткеч көч, дәрт, йөрәк белән «Ашказар», «Әллүки» җырларын җырлавы Тукайга бик нык тәэсир итеп, мәҗлестән соң, ике-өч көн үтми, Тукайның моңлы, зарлы йөрәгеннән «Милли моңнар» шигыре килеп туган.

Сүз ахыры итеп минем әйтергә теләгәнем шул: бу «Милли моңнар» шигыре ялкынлы, давыллы йөрәк белән моңлы, зарлы йөрәкләрнең уртак йөрәк җимеше диясем килә.

Вафа Бәхтияров.<br>8.11.1945.

Кереш сүзне, текстларны басмага<br>ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать<br>институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге<br>баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы,<br>профессор, Марсель Әхмәтҗанов әзерләде

## ШАКИР МӨХӘММӘДЪЯРОВ ИСТӘЛЕГЕ

Тукай замандашы, гыйбрәтле тормыш юлы үткән юрист, журналист, педагог Шакир Зариф улы Мөхәммәдъяров (1883–1967) шагыйрьне 1907 еллардан башлап иң якын белүчеләрдән берсе. Ул аның иҗатын чын йөрәктән яратып, эченә үтеп кергән, аңлаган укучылардан. Истәлекләрендәге аерым детальләр Тукайның иҗаты һәм тормыш юлын өйрәнүдә мөһим роль уйныйлар.

Тукай 1912 елда Петербургка килгәндә, Шакир университет студенты була. Ул авыру һәм боек Тукайның күңелен күтәрү өчен кулыннан килгәннең барын да эшли. Тукай яшәгән номерга медицина профессоры Александр Робертович Польне алып килә.

Докторга күрсәткәне өчен соңыннан Тукай да Шакирны хөрмәт белән кат-кат искә ала торган булган. Мәсәлән, 1912 елның 12 маенда Уфадан Петербургка дусты Кәбир Бәкергә язган хатында Тукай Шакир Мөхәммәдъяровка «пәйгамбәр» төсле кешесе өчен (ягъни Поль өчен) аеруча рәхмәтен белдерә.

Шакир Мөхәммәдъяров Тукай шигырьләрен яттан белгән. Аның иҗаты турында күп язган, күп мәртәбәләр докладлар белән чыккан.

Мәскәүдә 1917 елның октябрендә татар яшьләренең «Ташкын» исемле музыка һәм драма түгәрәге оеша. Түгәрәк 1918 елның 15 апрелендә Габдулла Тукайның вафатына 5 ел тулу мөнәсәбәте белән искә алу кичәсе үткәрә, анда яшь юрист Шакир Мөхәммәдъяров чыгыш ясый. Шул ук елны бу доклад «Тукай кем?» исеме астында китап булып басылып чыга. 22 генә битлек, бик сирәк очрый торган бу китап халык шагыйре Тукай иҗатына һәм тормышына карата шактый квалификацияле бәя бирүе белән дә кызыклы.

Шакир Мөхәммәдъяровның «Габдулла Тукай турында кыскача истәлеге» Г.Ибраһимов исем. ТӘҺСИның ЯһММҮендә саклана (9 ф., 4 тасв., 81 эш). Гарәп графикасында төп нөсхәдә сакланган әлеге кулъязма ядкәр, эчтәлеккә зыян китермичә, берникадәр кыскартулар белән китерелә:

**Габдулла Тукай турында кыскача истәлек**

(Тукай дәвере тарихына кайбер мәгълүмат)

Тукайның беренче шигырьләре чыгуы белән үк халкының күңелендәге уйларын, өметләрен ачып биргән кебек булды. Бу шигырьләрне укыгач, мин Тукайны яшь көрәшчеләрнең юлбашчысы итеп, үзе әйткәнчә, «яшь көтүнең чупаны» (*көтүче*) дип таныдым. Тукай дигән исемнең үзенең калын әйтелүе, яңгыравы, шигырьләренең җитдилеге бу күпне күргән, күпне белгән ир уртасы кешедер дип уйлый идем. Тукай Казанга килгәч, «Таң» гәзите идарәсендә күрештек. Ул яп-яшь, кечкенә генә гәүдәле егет булып чыкты. Күңелдә утыртылган сурәт белән реаль күренешнең аермасы, әлбәттә, минем хөрмәтемне киметмәде. Тукайның «Тавыш» идарәсенә килүе исемдә. Вакытында күп шау-шу күтәргән «Вакыт» гәзитәсе белән Тукай арасында аңлашылмаучылык тудырган «Мөтәшагыйрьгә» дигән шигырен алып килеп укыды. Идарәдә эшләүчеләр бу шигырьдәге «вакты гаҗзе» гыйбарәсен «Вакыт» белән көрәштә

үз файдаларына эшләтү, корал итү нияте белән Тукайдан вакыт дигән сүзне (ковычка) куштырнак эченә алуын сорый башладылар. Ләкин Тукай моңа ачыктан ризалык бирмәде. Терәүдә калган төсле күренде. «Мөтәшагыйрьгә» шигыре «Йолдыз» газетасында басылды. «Вакты гаҗзе»дәге вакыт сүзе ничектер җәя эчендә чыккан. Газетта исемнәрне куштырнак эчендә язу гадәт булганга, җәя эчендәге сүзне «Вакыт» газетасына каратылган дип уйларга йитәрлек әсәс юк иде югын. Телче галимнәремез бәлки монда вакыт дигән сүзне «вакты», «вакту» дип укылырга кирәклеген анықларлар. Тукай «Мөтәшагыйрь»дәге вакыт сүзеннән «Вакыт» газетасы ирадә ителмәгәнлеген бәян итеп җавап язды. Башта ук «Вакыт» газетасы күздә тотылган булса, үз сүзеннән кайту кебек түбәнчелекне Тукайның вөҗданы кабул итмәс иде. Һәрхәлдә, бу мәсьәләдә Тукай уңайсыз хәлдә калган кебек тәэсират туа. Шагыйрь Дәрдемәнднең «Нәдән бу хиддәт, и шагыйрь» дип, Тукайга нәсыйхәт бирүгә хәтле йиткергән. Бу аңлашылмаучылыкны шәрехләп үтүне бурычым дип санадым.

2. Тукай иҗатын җентекләп өйрәнүче «Тукайчыларымыз»ның шагыйрьнең һәрбер юлының бер сәбәпкә бәйле булуын белергә теләүләрен күздә тотып, Тукайның бүгенгәчә һичбер төрле изахлауга (*аңлатуга*) очрамаган ятим генә «Вәгазь» исемле шигыре турында кечкенә генә бу вакыйганы язып үтәсем килә. Яшьлектә һәркемнең диярлек башыннан үтә торган сөешү-аерылышу кайгысы белән йөрәк януларын шагыйрь Тукай гына аңлар дип, Казанның болытлы бер ямьсез кичендә Тукайга бардым. Тукайның «Болгар»дагы бүлмәсе «Әлислах»ның бер шөгъбәсе булгандырмы, өстәл өсте төрле язулар, гәзитләр белән тулы. Тукай минем зарлануларымны сабырлык белән, бер сүз дә дәшми тыңлап утырды да, кинәт бүлмәдән чыгып, янына бер шәкерт ияртеп керде. Мин шагыйрь Тукай да бу мәсьәләдә җәяүле икән дигән уй белән чыгып киттем. Берничә көннәр узгач, Тукай белән очрашканымда ул: «сиңа «Вәгазь» дигән шигырем белән җавап яздым, диде.

Шигырь Лермонтовтан диелгән, 1907 ел, 17 декабрьдә язылганы күрсәтелгән. «Вәгазь» мине канәгатьләндермәде, мәхәббәт авыруына үгет-нәсыйхәт дәва була алмый инде. Бу шигырьТукайның мәхәббәткә карашын күрсәтүе белән әһәмияте дә юк түгелдер дип язып үтәргә уйладым.

3. Тиздән миңа Тукай белән мәҗбүри аерылышырга туры килде. Мине Казан полициясе арестовать итеп, Пләтәндәге 5 часька ябып куйды. Һәркем дә арестлар көтеп торганга, иптәшләрнең

берсе дә килмәде. Тик язучы Борһан Шәрәф[1], пешкән үрдәк алып килеп, хәл белеп китте. Үрдәк итләрен без азатлыкта да күрми идек. Пләтән частеннән Воскресенский урамындагы баш управлениегә озаттылар...

4. Мин Зөягә килдем. Кыш көннәре. Тирә-як ап-ак кар. Менә калын стеналы кальгәгә охшаган монастырь, кечкенә генә шәһәрдә егермеләп чиркәү. Бу Казан алынган заманнарда салынган, Казанга каршы корылган Иван Грозныйның колониализм бастионын күрү мине көчле дулкынландырды. Шундый кризис, авыр кичерешләр үткәргән көннәрдә Казандагы «Әхбар» гәзитәсенә берничә мәкалә йибәрдем. Хәзер инде ни язганымны үзем дә белмим. Хаталары да булгандыр. Кабан күленә батып үлгән революционер Морадов турындагы мәкаләмне басмадылар. Күп еллар үткәч Галимҗан Ибраһимов: «Аң» журналында (1915) минем турыда «табигатендә шигърият чаткысы бар. Теле матур, әдәби, табигый булган әдиплек истигъдады күренеп тора», дип язган иде. Казанда яшәп Тукай, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камаллар мөһбирлегендә әдәбият өлкәсендә үсүемә манигълар чыкты.

5. «Шагыйрь белән без бик дус идек, еш күрешә идек» дип истәлек язучылар кебек Тукайга якын торуым белән мактанып карьера ясарга, Бәдигъ мәзин[2] күркәсе кебек шөһрәт алырга омтылу миндә юк. Казаннан китүнең уңай ягы да булгандыр. Илдә дәһшәтле реакция баш күтәрде. Столыпин. Уку эшләрендә Шварцлар[3] дәвере килде. Тукай:

Җанлырак тормыш та бетте
Шанлырак бер эш тә юк,
Бер-берен чәйни бишенче
Елдагы күп әүлия» ди...

Мин рус телен, рус әдәбиятын чынлабрак өйрәнү өчен Петербургка киттем.

6. Тукай белән ара тагы да озаклашты. Тукай хәлен тик хатлар аркылы гына белеп тора идем. Габдерахман Дәүләтшиннең модага ияреп нәшрияткә керешкәнен язалар. Аның бастырган китапларын посылка итеп тегеп, почтага илтү, китап магазиннары-

---

[1] Борһан Шәрәф (1883–1942) – җәмәгать эшлеклесе
[2] Бәдигъ мәзин – Яңа Бистә мөәзине Бәдигъ Әхмәров.
[3] Шварц Александр Николаевич (1848–1915) – 1908–1910 елларда халык мәгарифе министры.

на тарату кебек хезмәттә Тукай йөргәнен язалар. Дәүләтшиннең Тукай чаклы Тукайны эшкә җигүенә хурланып үлә яздым. Әхмәд бай Хөсәеновның асраугa алган баласы, бай үлгәч, мирас тимәгәч, адвокат белән килешеп, Мәхмүд бай Хөсәеневтән шантаж юлы белән 60 мең сумны эләктергәч, капиталист булып Питерга килеп, Голенищев-Кутузов фамилиясендә боярның роскошный фатирында яшәвен беләм... Тукайны эксплуатировать итми, бушка килгән меңнәрдән Тукайга әз генә ярдәм итсә булмас идемени? Минем Тукай өчен хурлануымның урынсыз булмаганын 1908 елда Тукайның Дәүләтшингә язган хатындагы сүзләре раслый:

«Менә сезгә артык мәртәбә мөрәҗәгать итәм. Әгәр сездә миңа тиешле акча, үзегез әйткәнчә, беткән булса да, пожалуйста, сез хәзер 25 сум биреп җибәрегез әле, пожалуйста, кире кайтармагыз. Бер җәйлек пальто алмакчы идем бу көннәрдә», – ди Тукай. Бу хаттан тәрәкъкыйпәрвәр буржуаның Тукай белән честно рәвештә хисап өзмәгәне дә аңлашыла. Тукай:

«Нигә мәнфүр бу татарларның китап нәширләре бер тиен китсә, җылыйлар, агълашубән: «Әлфиракъ», ди..

7. Каникул вакытларында Казанга кайтып Тукай, Фатихлар[1] белән күрешә идем. Бу күрешүләрнең берендә Тукай минем алдымда кечкенә кәгазьгә карандаш белән «Кадер киче» шигырен язып, укып бирде. Эчтәлегенең дини төстә булуына карамастан, хыялый булса да, мәлаикләрнең һавада очып йөрүләре картинасы матур художестволы күренеш икәнен әдәбият сөйгәннәр инкар итмәсләр

Ул мәлаикләр җыярлар тол, ятимнәр яшьләрен,
Барча көчсезләр, зәгыйфьләрнең аһын, каргышларын.
Күз яшеннән, төрле рәнҗештән ясап зур энҗеләр,
Ул мәлаик гарше-көрсине бизәр һәм энҗеләр.

Мисрагълардан һаман да шул халыкчыл, көчсезләрне яклаган батыр көрәшче Тукаемыз рухы аңкып тора. Шигырьне мактадым. Үзенә дә ошаган булырга кирәк, елмаеп куйды. Тукайның бүлмәсе тәртипсез иде. Тукай тормышта иске тәгъбир кулланылса – «шәехләрчә» иде. Тик Гомәр Хәйам мәзһәбендәге шәехләрчә иде. Тукайның заманына, укучыларның аңына карата язылган дини төстәге шигырьләре аз түгел. Әмма мирасларының дини ягын гына күргән кеше культура мирасы өлкәсендә, марксизмнан читкә

[1] Ф. Әмирхан (1886–1926) – прозаик, драматург, публицист.

тайпылып, борынгы культура байлыгын юк итү юлына аяк басачак», ди Җәвад Алмаз[1] (Совет әдәбияты, 1960 ел, февраль).

8. Тукай белән озаграк күрешүебез Петербургта булды. Кайбер кешеләр Тукай Петербургта вакытны әдәби сохбәтләр, фәлсәфи вә сәяси бәхәсләр белән генә үткәргән төсле итеп күрәселәре килә. Болар, бердән, Тукайның Питерга нинди авыру хәлдә килеп чыкканын истән чыгаралар. Хәзерге заман күз карашыннан чыгып, Тукай кебек зур шагыйрьне очратканда, бер көтү репортерлар аны чормап алып, аннан бик гыйбрәтле, шаккатырлык сүзләр язып алуларын аңлыйлар шикелле. Икенчедән, шагыйрьнең замандашларына бик мәгълүм булганча, Габдулла турында «душа парень», эчендәге тышында, дип әйтер хәл юк. Тукай үзен зыярәт итүчеләрнең кыйммәтен үтә күрүчән, сизгер, сак кеше иде. Ул үзенең каләменә генә ышана, кәгазенә генә эч серләрен ача. Тукайны комментировать итүчеләрнең күбесе чынбарлыктан ерак. Менә шагыйрь Сәйфи Кудаш «Язны каршылаганда» дигән әсәрендә Тукайның Уфадагы көннәрен, Тукайның авыруын, зәгыйфьлеген, хәтта үзенең бизгәгеннән сыра белән генә җиңәм диюен искитәрлек художество белән тасвир итеп, без Тукай замандашларын канәгатьләндерсә дә, Тукайның Петербургта үткәргән төннәрен язганда чынбарлыктан бик ерак чуалчык, надуманный нәрсәләрне язганын күрәбез.

«Совет әдәбияты»нда басылган Ибраһим Нуруллинның «Тукай Петербургта» драмасы ни булып очланыр әле, мин белгән Кәбир Бәкер[2], Сафа «мәхзүм», Галим абзый Максудовлар турында дөрес бара.

9. Тукайның Петербургтагы хәрәкәтен аңлап йиткереп булмый әле. Илебездә, татар дөньясында йөз биргән реакционерлар белән тәрәкъкыйпәрвәрләрнең бер-берсенә каршы ике лагерьга, сафка юлынуларын Питерның Мойка каналы буендагы ахун Баязитов мәсҗеде белән Демидов 2 дәге Лотфый Исхак мәхәлләсе, сату итүче Нижгород халкы «узелчы нижгарларның» мәркәзе тәҗәссем иттерә иде. Лотфый, Мусаларның чакыруы белән Питерга килгән Тукай ничек булса да Сафа[3] мәхзүмнең монафикать күрсәткән мосафирпәрвәрлеген кабул итте? Тукай Казаннан Уфага, Уфадан Питерга китүеннән, жандармериянең күзәтеп торуыннан хәбәрсез

---

[1] Алма́зов Җәвад (1916–1979) – тел галиме, текстолог, археограф.

[2] Кәбир Бәкер (1885–1944) – язучы, журналист.

[3] Сафа мәхзүм – Сафа Гатаулла улы Баязитов – ахун, «Нур» газетасы редакторы.

булмагандыр. Жандармнар белән тулган пайтәхеттә авыру шагыйрь үзен тыныч, хәвефсез дип хис итә алмагандыр дип уйлыйм. Өстән генә караганда Сафаның «Нур» гәзитендә эшләгән Тукайның электән белгән Кәбир Бәкер белән танышлыгы Сафаларга тарткандыр дип юрап куярбыз инде.

10. Тукайның килүен миңа Кәбир Бәкер белгертте. Тукайның минем белән күрешергә теләгәнен сөйләде. Очрашу Питерда Понизовский фирмасында хезмәт иткән приказчик, татар гәзитәләренә ярдәм иткән Кәрим Сәгыйтьнең[1] бүлмәсендә тәгаенләнде. Мин килгәндә Тукай караватта ята иде. Торып самими күреште. Мин Тукайның халкыбыз тарафыннан хөрмәт ителгәнен сөйләп, «күп яттык без мәдрәсәдә» хәзер дә татар гимны кебек җырланганын әйтеп, шагыйрьдән берәр стих китергәндә, Тукай «я, куй әле шул Американ хулиганлыгын», диде. Тукай мактауны да күтәрә алмый иде. Минем 6 нчы елларда Уральскига йибәргән мәкаләм турында: «Мәкалә бик үк грамотный булмаса да, үз партиямез кешесенеке булгач, төзәтеп, шомартып баскан идем, күргәнсеңдер», диде. Мин: «Нигә «Вәгазь» шигыре язылуга сәбәп булган күрешүебездә бүлмәгә чит кешечакырып килдең?» – дигәндә, – «Мин синнән курыктым», – диде.

Тукай сөйләшкәндә тиз арый иде. Пальтодан утыра, тиз-тиз таблеткалар йота, суыктан зарлана иде. Кәбир Бәкер җылыну өчен сез ярдәм итә дип ресторанга китүен тәклиф итте. Минем күлмәктәге манжетны икегә ярып, Тукайга яка ясап кидердек. Мондый ресторанда утырышлар берничә мәртәбә хәзерләнде, шуларны искә төшереп булса кирәк, Тукай Уфадан 1912 елда Кәбир Бәкергә язган хатында: «... кайларга барырга киңәш бирә? Шакиргә... шундый пәйгамбәр төсле кешесе өчен рәхмәтемне әйтим. Кәрим Сәгыйдевкә сәлам, Сафа әфәндегә хат яздым», – ди.

Пәйгамбәр кебек кеше – Петербург университеты врачы Л.Р. Польга көннәрнең берендә Питерның атлар белән йөри торган вагоннарының берсендә югары катына чыгып, Васильевский островка киттек. Врач Тукайны чишендереп бик озак кына тыңлаганнан соң, врачларның вазифасы булган рецепт язып бирде. Тукай чыккан арада миңа: «Авыруы куркынычлы, үпкәнең берсе бөтенләй эштән чыккан, икенчесенең дә яртысы белән генә сулыш ала», – диде. Тукай үзендә тб-з[2] (туберкулез) булганын белде. Моңарчы

---

[1] Кәрим Сәгыйть (1883–1939) – журналист, педагог.
[2] Бу сүз чыганакта шулай бирелгән.

күкрәк авыруына мөбталә булуына ышанмый йөргән, миндә башка авыру бардыр дип уйлый идем», – диде. Мин Тукайның күкрәк авыруы наследственный булгандыр дип шөбһәләндем, чөнки әтиәниләре безгә мәгълүм булмаган авырудан яшьли үлгәннәр бит.

11. Тукай турындагы кайбер очрашулар турында замандашының истәлеге шуның белән тәмам. Аның иҗаты турында язуны вазыйфам итеп куймадым. Кырык ел элек «Тукай кем?» дигән бер истәлек Мәскәүдә басылган иде. Тукайның вафатына биш ел тулуга мөнәсәбәте илә Мәскәүдә Асадуллин мәктәбендә ясалган мәҗлестә мин сөйләгән речьтән гыйбарәт иде. Анда азрак Тукайның иҗатына кагылып үткән идем. Тукай белән авыр заманнарда яшәдек. Казан ул вакытларда козгыннар оясы диярлек тә иде...

24.03.1960.

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәрләре, филология фәннәре кандидатлары Заһир Шәйхелисламов, Ләйлә Гарипова әзерләде*

## ИБРАҺИМ БИККОЛОВ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

*Журналист, мөгаллим, тәрҗемәче Ибраһим Җамалетдин улы Бикколов 1884 елда Сембер губернасы Буа өязе Яңа Тинчәле авылында туган. Буа мәдрәсәсендә белем алганнан соң, Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Аны тәмамлап, Томскида мөгаллимлек итә. Монда аның журналистлык эшчәнлеге дә башлана. 1914 елда И. Биккулов Казанга кайта. «“Шура”, “Мәктәп”, “Сөембикә”, “Аң”, “Ак юл” журналларында, “Казан мөхбире”, “Йолдыз”, “Әлислах”, “Ил” гәзитләрендә языша. “Сибирия” гәзитәсенең үзхәбәрчесе була. “Кояш”та, Ф. Әмирхан белән бергә, гәзитәнең төп хезмәткәре булып эшли. Аның “Хәзрәт”, “Әкмәли”, “Мөгаллим”, “Ислам улы” дигән яшерен имзалары билгеле»[1].*

*1926 елда И. Бикколовның «Мәктәптә тән тәрбиясе» исемле китабы чыга, аның тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшләве мәгълүм.*

*И. Бикколовның «Габдулла әфәнде Тукаев» исемле мәкаләсе 1913 елның 7 апрелендә «Сибирия» газетасының 96 санында басылып чыга.*

---

[1] Ибраһимова Ф. Ибраһим Биккулов // Казан утлары. 1994. № 6.

## Габдулла әфәнде Тукаев

Бармыни бездә чын
кеше кадерен белү?!
Без аны кайдан белик,
Мескин үлеб аңлатмагач?!

«Г.Т.»

Башыбызга бәхетсезлек килә генә тора, бер кайгыны онытырга өлгермибез, аңардан куркынычрак вә аңардан да күңелсезрәк булганнары килеп торадыр. Тәкъдир бер кешегә яки бер халыкка каһәрен салса, сала да сала гына, аны изгәннән изә генә бара.

Менә иң талантлы шагыйребезне, иң беренче әдибебезне дә югалттык. Габдулла Тукаев – бу зат бит һәрбер татарның иң сөйгәне вә иң якын күргәне бер зат иде. Һәрбер укый белгән татар, һәрбер шәкерт, дүрт стена эчендә бикле калса да, язарга өйрәнүгә яңа гына рөхсәт вә права алган һәрбер татар кызы бу затны бит үзенең күңеленә иң якыннардан итеп белә вә анарга үзенең иң гали рәхмәтен саклыйдыр иде. Менә явыз тәкъдир шушы бөтен милләтнең чын күңеле илә сөеп тоткан иң кадерле бер кешесен күзен дә йоммыйча алды да китте. Яшь кенә сабый хәлендә булган татар әдәбияты вә татар теленең бик яшьли үксез калам бит, диеп елавына да илтифат итмәде, миллионнарча рухларның гали татар поэзиясе илә гыйзаланудан[1] мәхрүм калуларына да игътибар итмәде. Аларны акыртып-бакыртып үксез итеп калдырды.

Габдулла әфәнде хакыйкатьтә безнең өчен зур вә кадерле иде. Ул бит безгә мәңге укылып туймаслык «Печән базары», «Шүрәле», «Бәйрәм бүген» кебек нинди гали поэмалар калдырды. Аның кайсы гына шигырен алма, аны укыган вакытта әллә нинди бер матурлык астында күмелеп каласың, аны һаман кайтарып укыйсы килә, укыган саен аның шигырьләрендәге шигърият вә андагы матур төзелгән күбесе татарча сүзләрнең һәрберсенең шамил улдыкы тирән мәгънәләре вә йөрәкне өзәрлек тойгылары сине үзенә мөсәххәр итә[2] генә баралар.

Габдулла әфәнденең болай безне иртә ташлавы, анарда киләчәктә бик зур өметләрнең булуы бу матәмне безгә ике өлеш авыр итәдер. Ул әле бик яшь, аңарда киләчәктә бик зур өметләр бар иде. Хосусан, Габдулла әфәнденең рухындагы еш алышынулар һәм бу алышынуларның көннән-көн Габдулла әфәндедә шигърият куәтенең

[1] *Гыйзалану* – күч. мәгъ. канәгатьләнү.
[2] *Мөсәххәр иту* – буйсындыру.

арта баруына хезмәт итүе бу өметләрне куәтлидер иде. Фәкать бичара мөбтәля улдыкы авыруыннан терелә алмыйча безне шулкадәр иртә ташларга мәҗбүр булды. Бу соңгы вакытларда Габдулла әфәнде үзе дә әллә ничек хәяттән туя төшкән иде, әллә мөбтәля улдыкы авыруының үзен тиз алып китәчәген хис итепме, Габдулла әфәнде соңгы язган шигырьләрендә, үзенең хәяттән туйганын, мәңгелек рәхәт галәменә ашкынганын бик ачык белдерәдер. Ул:

«Өйләнә бит, үтми-бетми гомере дә,
Җәй килә, утлар чәчеп, син кышласаң» –

диеп, гомернең тиз бетмәвеннән зарлана һәм:

«Катле нәфситсәм, Ходайдан куркамын
Ләкми чир, авырып та булмый, ичмасам!» –

диеп, тизрәк бозыклык, фәхеш илә тулы былчырак хәятне ташларга ашыгадыр, гүя шагыйрьнең пакъ вә саф булган илаһи кальбе, аның илаһият катышлы рухы, алдашудан, бөтен барлыгы ялганнан гыйбарәт булган тормышны ташлыйсы килә, җәүһәрнең нәҗес арасында торуы ярамаганы шикелле, шагыйрь дә үзен бу былчырак тормышта торырга тиешсез күрәдер.

Габдулла әфәнде бик сирәк шагыйрьләргә насыйп була торган рәвештә, үзен бик тиз шагыйрь итеп таныткан иде. Ул Уральскида нәшер ителгән «Фикер» газетасында беренче мәртәбә язган шигыре белән үк үзенә күп кешене мәхәббәт куйдырырга муафикъ була алды. Соңра «Әлгасрелҗәдид» журналында чыгардыкы «Мөридләр каберстанынннан бер аваз» исемле шигыре илә ул үзен чын шагыйрь итеп таныткан. Аның шушы шигыре, теленең төрек әдәбияты тәхете тәэсирендә булуына карамыйча, Габдулла әфәндегә «шагыйрь»лек таҗыны кидергән иде.

Габдулла әфәнде үзе рәсми бер мәктәп күрмәгән булса да, төрек, гарәп, рус әдәбияты илә бик яхшы таныш иде. Аның әүвәлге шигырьләре кирәк тел вә кирәк мәгънә җәһәтеннән төрек әдәбияты тәэсире астында булыналар. Соңра шагыйрь бик тиз ул әсарәттән[1] котыла. Ләкин рус әдәбияты тәэсиреннән ул бик тиз котыла алмыйдыр. Шулай да Габдула әфәнденең мөстәкыйль, һәртөрле тәэсирдән хөр шигырьләре дә юк түгел.

Габдулла әфәнде үзе гали табигатьле, мөстәкыйль фикерле иде. Габдулла әфәнденең әдәбияттагы вкусы бик назлы, ул әдәбияттагы кимчелекләрне үзенең бик үткен хисе илә бик тиз сиздерәдер иде.

[1] *Әсарәт* – әсирлек.

Шуның өчен ул хәзерге әдәбиятыбызның бик күбесеннән разый булмаган кебек, үзе язган нәрсәләренең күбесеннән дә разый түгел иде. Бу соңгы елларда аның рухы бик югары ашып, ул әллә нинди гали поэзияләр вөҗүдкә китерергә ашкына, фәкать аңарга үзендә куәт юклыкны хис кыладыр да, бөтен хәяттән туя, дөньядан бизә, үзен хәяттә артык – лишний күреп, хәятне терек итәсе киләдер иде. Габдулла әфәнденең бу халәт рухиясе соңра шигырьләрендә бик ачык күренеп торадыр. Аның больницадан мәкаләсе дә («Кояш» газетасында) шушыны тәэкид итә[1], фәкать ул үзендә инде ул гали куәтне тапкан кебек буладыр, ул шуны тапканлыгына ышанып, безгә тагын бик күп нәрсәләр вәгъдә итәдер. Фәкать аңардагы булган бу яңадан терелү, йокыдан уйгану, аңарга табигать тарафыннан инсанга үлем алдыннан гына бирелә торган бүләк булганга, былчырак тормыш, пәс[2] инсаннар ул гали хакыйкатьтән истифадә итү[3] дәрәҗәсеннән бик түбән булганга, без йокыдан уянган Тукаевны күрә алмадык.

Габдулла әфәнде, кирәк авыруыннан терелер өчен, кирәк үзендәге шигърияте арттырыр өчен табигать җәһәтеннән бай булган, Данте, Гомерларны җитештергән, Лермонтов вә Пушкиннарны тәрбияләгән җир йөзенең иң матур бакчаларында торуга, ул җирләргә сәяхәт итүгә бик мохтаҗ иде. Фәкать үзенең икътидары булмаганга, башка бер кешенең ярдәме илә файдалануны гали табигате кабул итмәгәнгә, ул аны булдыра алмады.

Габдулла әфәнденең шигырьләре идея вә мөндәриҗаты[4] һәм теле җәһәтеннән берничә дәверләргә бүленсә дә, ул иң баштан алып иң ахыр көненә кадәр татар шагыйре, татарлыкны бөтен нәрсәдән артык сөюче, шушы татарлык өчен үзен фида итүчедер. Аның һәрбер шигырендә, һәрбер сүзендә татарлыкка, аның теленә, аның әдәбиятына вә аның музыкасына мәхәббәт, гыйшык балкып торадыр. Ул үзе халкын шулкадәр сөйгәнгә күрә, халык та аны артык сөядер, артык яратадыр, бары үзенең яшьлеге илә ул мәхәббәтне изһар итә[5] генә алмыйдыр иде.

Габдулла әфәнде үзе китте. Фәкать аның поэмалары, аның туңган йөрәкне эретерлек сазлары калды, алар мәңгегә калдылар һәм мәңге онытылмаслар. Шулар илә бергә Габдулла әфәнденең

---

[1] *Тәэкид итү* – раслау.
[2] *Пәс* – түбән.
[3] *Истифадә итү* – файдалану.
[4] *Мөндәриҗат* – эчтәлек.
[5] *Изһар итү* – күрсәтү.

исеме дә мәңге яшәячәктер, мәңге татар йөрәгендә иң гали урында сакланачактыр.

Хәзер безгә Габдулла әфәнденең Толстой хакында әйтдеке «Тәсбих өзелде» сүзләрен тәкърарлап, Гаяз, Әмирхан, Сәгыйтьләр вә Гафурилар кебек мөхтәрәм затларыбыздан төзелгән тәсбих өзелде, шушы тәсбихнең иң кыйммәтле бер төймәсе дә җиргә төшеп югалды, мәңге табылмаска югалды, диеп тәкъдирнең бу каты золымына баш кына ияргә калды.

«Шадман ул мәркадеңдә!
Без онытмыйбыз сине,
Белмәсәк вакытыңда кадереңне
Инде котлыйбыз сине.»
«Г.Т»

Ибраһим Бикколов

*Текстны, гамәлдәге язуга күчереп, басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре,*
*филология фәннәре кандидаты Ләйлә Гарипова әзерләде*

## ВОСПОМИНАНИЯ О ЖИЗНИ Г. ТУКАЯ В АСТРАХАНИ

В 1961 году (в конце мая – начале июня) в различных населенных пунктах Астраханской области сотрудники научной экспедиции ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова (в то время – Казанский филиал института языка, литературы и истории) занимались записью материала по фольклору, этнографии и истории края. Эта деятельность осуществлялась в соответствии с планом, принятым для группы научных работников по татарскому фольклору. В экспедиции участвовали филологи Х. Ярмухаметов (руководитель), И. Надиров, Э. Касимов, Х. Гатина и музыковед М. Нигмедзянов. Так же, как и во время других подобных поездок, удалось зафиксировать интересные образцы вербального и музыкального народного творчества, в данном случае, астраханских татар, ногайцев и русских. Среди них: баиты, различные песни, сказки, пословицы, примеры детского фольклора. Уже в ходе проведения записей обратили на себя особое внимание свадебные песни, в частности, причитания невесты, и жанр «хушаваз», присущий татарам именно этой области.

Участники экспедиции стремились к широкому охвату информации по культуре исследованного региона. Автору этой статьи удалось обнаружить привезенные ими материалы, касающи-

еся жизни и творчества выдающихся татарских поэтов (Г. Тукай, М. Джалиль), артистов и режиссеров (С. Байкина, З. Солтанов, Г. Кариев), астраханского татарского театра. Все они хранятся сегодня в Центре письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. К документам, посвященным жизнедеятельности Г. Тукая в Астрахани и ее окрестностях, можно отнести снимки двух зданий (ЦП и МН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. Ф. 71, оп. 2, ед. хр. 59; 61), в которых жил или побывал поэт, его фотопортрет в виде почтовой открытки и фиксация воспоминаний о нем от трех горожан. Напомним, что в Астрахани Г. Тукай находился с конца апреля по начало июня в 1911 году для лечения в связи с ухудшением своего здоровья. Новые факты о пребывании Г. Тукая в Астрахани предоставляют упомянутые воспоминания и фотопортрет. Остановимся на них подробнее. Почтовая открытка (ЦП и МН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. Ф. 71, оп. 1, ед. хр. 35) снимка поэта, с указанием ее издателя – Ш. Гайфи – учителя, в доме которого жил Г. Тукай, имеет внизу надпись, состоящую из следующих авторских строк:

Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

Она была подарена Х. Ярмухаметову жительницей Астрахани – Нурджихан Вагаповой. Некоторые сведения об этой женщине содержит текст на обратной стороне данной фотооткрытки. Оказывается, она работала в свое время учительницей и в связи с этим повстречалась с Г. Тукаем в Астрахани. Вероятней всего, что фотография, оформленная в виде такой открытки, не самостоятельна и не оригинальна (как утверждают составители книги «Габдулла Тукай: Тормыш һәм иҗат елъязмасы». Казан, 2003, с. 185), а извлечена из группового снимка, запечатлевшего Г. Тукая, вместе с Ш. Гайфи и поэтом С. Рамиевым, но в другом антураже. Отметим также, что это – не единственная обработанная под открытку фотография театрализованных представлений стихотворений Г. Тукая, устроенных в доме Ш. Гайфи. Из опубликованных воспоминаний известно, что получила распространение цветная почтовая фотооткрытка, представившая атрибуты одной разыгранной сценки, со строками поэта из стихотворения «Бер шәехнең мөнаҗаты» на татарском и русском языке (Тукай турында хатирәләр. Казан, 1976, с. 119):

И ходай! Мәгълүм сиңа, тик яхшылыкта касдымыз.
Зикремездер: казы, кузый, яшь кенә кыз, каз, кымыз.

Все воспоминания о пребывании Г. Тукая в Астрахани были записаны в этом городе фольклористкой Х. Гатиной. В ее рукописях, до сих пор еще не опубликованных, повествуется об отдельных эпизодах из жизни поэта в этом городе в 1911 году, очевидцами, а порой и непосредственными участниками которых были сами информаторы. Эти три мемуариста отличались по своей социальной принадлежности и профессиональной ориентации. Самая известная среди них – заслуженная артистка РСФСР, народная артистка Татарстана Сара Байкина, воспоминания которой окрашены в шутливые тона (ЦП и МН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. Ф. 71, оп. 1, ед. хр. 31). Ее рассказ уточняет, а иногда и опровергает некоторые факты из жизни Г. Тукая в Астрахани. Например, она утверждает, что в честь поэта в Астрахани был устроен банкет представителями городской интеллигенции (видимо, не З. Султановым – как отмечают некоторые авторы). По ее словам оказывается, что она на нем не присутствовала (хотя в опубликованных рассказах о Г. Тукае других астраханцев об этом говорится).

Еще одна мемуаристка – Камаева Гайша – оказалась связанной по театральной деятельности с Сарой Байкиной. В своих воспоминаниях о Г. Тукае она конкретизировала некоторые факты, поведанные упомянутой народной артисткой Татарстана, например, то, что поэт посетил спектакль «Яшә, Зөбәйдә» по пьесе С. Рамиева в исполнении труппы «Мохтариять», в которую Г. Камаева тоже входила. Большой интерес представляет ее рассказ о личной встрече с Г. Тукаем. Г. Камаева была музыкально одаренным человеком и по этой причине ее специально познакомили с поэтом. Надо заметить, что с этим информатором возникли определенные проблемы. В связи с музыкальным талантом Г. Камаевой возникло желание идентифицировать ее с солисткой татарского радиокомитета. Но года рождения у них разные. Татарстанская певица Гайша Камаева появилась на свет в 1912 году в Алексеевском районе республики (Хәйруллина З. Радио җырчысы // Социалистик Татарстан. 1989. 7 май). Но некоторая неразбериха все же осталась. Дело в том, что согласно нотным публикациям музыковеда М. Нигмедзянова, получается, что он сделал в этой экспедиции записи вокальной и инструментальной музыки от Камаевой Гайши 1891 года рождения, но в разных местах: в деревне Тияк Нариманского района (Нигмедзянов М. Татарские народные песни. М., 1970, с. 50, № 48) и в Астрахани (Нигъмәтҗанов М. Татар халык җырлары. Казан, 1976, с. 167, № 245),

как и Х. Гатина. Создалось впечатление, что он записал двух разных женщин, имеющих одинаковые имена, фамилии и год рождения, но проживающих в разных местах. Причем горожанка, сыгравшая М. Нигмедзянову наигрыш на сазе, и мемуаристка Х. Гатиной – это явно одно и тоже лицо. Именно в своих воспоминаниях о Г. Тукае, Г. Камаева, проживавшая в момент записи в Астрахани, сообщила, что она играла поэту на сазе (разновидность гармони астраханских татар), например, мелодию песни «Баламишкин». Из ее рассказа можно узнать о некоторых музыкальных пристрастиях поэта и самих астраханских татар. Так, например, он предложил ей играть на маленькой тальянке и скрипке. Это вызвало протест с ее стороны, т.к. у астраханских татар тальянка в то время не была модным инструментом, а на скрипке играли только юноши. Незнание Г. Камаевой названий народных песен, о котором она сообщила в ответ на вопрос Г. Тукая о деревенских напевах, подтвердило наблюдение Э. Касимова, зафиксированного им в отчете. Он обратил внимание на то, что информанты пользуются указанием жанра, но не названиями песен. В этих воспоминаниях Г. Камаевой, а также в опубликованных ранее, есть невыясненные моменты, связанные с музыкой. С ними предстоит еще разобраться. Например: какое стихотворение написал Г. Тукай для школы, в которой учился племянник Ш. Гайфи – Х. Гайфетдинов, привозивший ему кумыз? С какой мелодией исполняли школьники это стихотворение по окончании занятий? Х. Гайфетдинов отметил, что она была похожа на турецкий марш (Тукай турында хатирәләр. Казан, 1976, с. 120). А какие песни спел поэт под аккомпанемент Г. Камаевой? Она запомнила начальные строки одной из них. В приведенных ниже ее воспоминаниях (ЦПиМН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. Ф. 71, оп. 1. ед. хр. 31) есть их текст.

И, наконец, третье воспоминание (ЦПиМН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. Ф. 71, оп. 1. ед. хр. 31) об астраханском эпизоде жизни Г. Тукая, принадлежит Ибрагиму Махмудовичу Махмудову (1893 г.р.), работавшего в прошлом на различных руководящих должностях. Он дал описание внешнего вида поэта, его одежды, а также сообщил сведения о Салихе Алееве, с которым общался Г. Тукай.

В Центре письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ хранится много раритетов по духовному наследию татарского народа. Поэтому можно с уверенностью предположить, что будут еще обнаружены новые материалы по жизни и творчеству Г. Тукая.

* * *

***С. Байкина***: «1911 елда Г. Тукай Әстерханга кымыз эчәргә килгән иде ул. Безнең шәһәрдә ул вакытта мөгаллимнәр бар иде, шулар бик зурлап каршыладылар аны. Без аның хөрмәтенә кышкы театрда (зимний театр) спектакль куйдык.Точно хәтеремдә юк «Яшә, Зөбәйдә» исемле спектакль куйдык бугай. Спектакль беткәч барыбызны да тәбрик итте. Кечкенә генә буйлы, нечкә генә,үзе бик оялчан гына икән. Бик мөлаем гына каравы уйнаучыларда бик нык тәэсир калдырды. Бер вакытны, спектакль беткәч, без гримне сөртеп утырабыз, Тукайны эзлиләр. Эзлиләр-эзлиләр, һич юк бит. Кергән кеше дә, чыккан кеше дә күренмәде, Тукай югалды. Ул нишләгән бичара. Сәхнә артында чүгәләп утырган килеш йокыга киткән. Сәхнә эшчеләре тегене күрмичә өстенә декорацияләр өйгәннәр. Иванов дигән сәхнә эшчесе бар иде, шул әйтә: «Туктагыз әле, – ди, – гырылдаган тавыш килә», – ди. Барып карасак, декорацияләр астында гырылдап йоклап ята. Шуннан тартып чыгардылар, үзе чыга да алмады. Шул вакытта бик кызык булган иде, үзе дә көлде, без дә көлдек. Тукай әйтә: «Менә бит, – ди, – шулкадәр тәэсирле уйнадыгыз, сезнең уйнавыгыз турында хыялланып йокыга кителгән», – ди.

Шуннан соң ул безнең барыбыз белән дә исәнләшеп, бик зур рәхмәт әйтеп, тәбрик итеп, киләчәк эшләребездә иҗади уңышлар теләп, алырга килгән иптәшләр белән чыгып китте. Шуннан ул Әстерхан һавасы ярамаганлыктан Кырымга китәргә тиеш иде, кайчан китүен белмим. Без шул спектакльдән соң 2–3 көннән районга китәргә тиеш идек, шунлыктан мин аның китүен күрә алмадым.

Шул вакытта Тукайның Әстерханга килү шәрәфенә зур банкет ясадылар, кайсы җирдә булуын белмим, чөнки мин барып катнаша алмадым. Ул банкетны Әстерхан мөгаллимнәре эшләгәннәр.

Мин шуннан соң Тукайны күрә алмадым».

* * *

***Г. Камаева:*** «Г. Тукай 1911 елда Астраханьга килгән иде. Ул вакытта мин “Мохтарияъ” труппасында уйнап йөри идем. Г. Тукай килүенә багышлап “Яшә, Зөбәйдә” исемле, С. Рәмиев әсәре булса кирәк, спектакль куйдылар. Г. Тукай башына кара маһмалдан (бархат) кәләпүш кигән иде.

Әстерханда Сабир Бикманбетов дигән бер кеше бар иде (трамвай йөрүтүче). Бер вакытны шул Сабир абый мине чакырырга килгән. Мин әле ул вакытта оялам. Ул вакытны без әле чапан белән генә йөри идек. Сабир абый әйтә: “Ул бик матур итеп татар

көйләрен уйный белә, – ди. – Без аны өеннән тартып чыгара алсак, артистка булырга да ярый торган кеше ул”, – ди. Мин инде үзем белән сазымны да (гармонемны) алып барам. Башта мин «Баламишкин» көен уйнадым. Аннан Тукай әйтә:

– Син, – ди, – авыл көйләрен дә уйный белә торгансыңдыр, туташ, –ди.

– Минем исемем, “туташ” түгел, Гайшә, – дим мин.

– Ярар алай булгач, авыл көйләрен дә уйный белә торгансыңдыр, Гайшә, – ди.

– Мин көйләрне уйный беләм, исемнәрен белмим, – дим.

– Уйнап кара әле, – ди Тукай.

Уйный башлаган идем, мин уйнаган көйгә Тукай ике җыр җырлады. Хәзер сүзләрен хәтерләмим, берсенең башын болай, дип башлаган иде:

Уйсы җирнең сазы идем,
Сулы җирнең казы идем...

Тукай әйтә миңа шуннан соң:

– Син бу көйләрне онытма, сазда уйный тор, – ди. – Син кечкенә генә тальянка алып җибәр, – ди.

Мин әйтәм: Бездә тальянка муд тегел, – дим.

– Без сине скрипка уйнарга өйрәтербез, – ди Тукай.

– Әй, аны ирләр генә уйный, кызлар уйнамый, – дим. Аннан мин әйтәм, – Мине бит өйдән чыгармыйлар, – дим.

Тукай әйтә:

– Без сине тагы да чакырырбыз, килергә тырыш, – ди.

Мин бер сүз дә әйтмичә өйгә кайтып киттем. Мине Сабир абый озата барды.Ул вакытта бездә шулай иде бит, чакырып алып киткән кеше өйгә китереп әниләргә тапшырып китә иде.

Шуннан соң инде мин Сара Байкиналар белән катнашып, шәһәрнең зимний театрында куела торган спектакльләрдә катнаша башладым. Ул вакытта губернатор рөхсәтеннән башка спектакльләр куярга ярамый иде. Без рөхсәт алырга язу язып, спектакльнең исемен күрсәтеп, Сара Байкинаны җибәрә торган идек. Губернатор «революцион спектакльләр куймасагыз, рөхсәт итәм», – ди торган иде. Ул вакытта Сара Байкинаның ире Җәләл Байкин да безнең белән уйный иде. Бу 1913–15 еллар иде».

* * *

***И. Махмудов***: «Ничәнче ел икәнен хәтерләмим: я 1912, я 1913 еллар булды. Ул вакытта миңа 20 яшьләр булды. Мин Әстерханның

хәзерге Нариман районында тора идем. (Ул вакытта хәзерге Нариман районын татарча Тияк, ә русча Царев дип йөретәләр иде). Безнең үзебезнең хуҗалык, кечкенә генә бакчабыз бар иде. Безнең йортыбыз Царевның үзендә, ә бакчабыз Царев елгасы (Тияк суы) буенда татар зиратыннан ерак түгел иде. Безнең бакчабыз ул вакытта сабан сыяр дигән урында иде. Безнең бакчабыз Салих Алеев бакчасы белән беррәттән иде. Бакча арасында кура (3 тактадан) гына бар иде. Менә бер көнне (июнь айларында булса кирәк) мин бакчада эшли торганда Салих Алеевлар бакчасы янында, яр буендагы зур гына тал тирәге астында, ике кеше утырганын күрдем. Болар чәй эчеп утыралар иде. Шунда Салих Алеев мине үзләре янына чакырып алды. Мин алар янына бардым. Салих Алеев мине чәй эчеп утыручы кунакчы белән таныштырды: бу безнең атаклы шагыйребез Габдулла Тукай, диде. Мин Г. Тукай белән күрештем. Ул да минем белән исәнләште. Салих Алеев үзенең Г. Тукай белән бергә укыган булуын әйтте. Безнең арада ниндидер сүзләр булды, ләкин хәзер мин аларны хәтерләмим. Тукай кечкенә генә кеше икән, ябык кына, очлы борынлы, битендә әз генә чәчәк таплары булган кебек күренде. Өстендә озынрак кәзәки кебек бер әйбер иде. Яга буенда самавар куеп чәй эчеп утыралар иде. Ул җир бик матур урын, анда, шул яга буенда бик күп кеше килеп ял итә иде. Мин алар янында бик озак утырмадым. 10–15 минутлар утырганнан соң бакчага киттем. Мин бакчада канау казып су кертергә йөри идем. Алар кичкә хәтле утыручылар һәм кичкә таба ат белән килеп аларны алып киттеләр. Салих Алеев ул вакыттагы укымышлы яшьләрдән саналган бер кеше иде һәм Казанда укый иде. 1893 елда туган. Ул 1917 елда партиягә керде. Монда революцион эштә актив катнашты. Соңыннан военком булып, учком секретаре булып, губисполком члены, Губком члены булды. Күп еллар Предволисполком булып эшләде. Гомумән, Салих Алеев Әстерхан Нариман районында партия совет эшләрендә актив катнашкан кеше. Хәзерге көндә исән-сау, Ленинградта тора, персонал пенсионер. Салих Алеевны Мөслим Шакирович Фәтхуллин бик яхшы белә.

Шулай итеп, мин Г. Тукайны Әстерханда күрдем, ләкин бу очрашу бик кыска вакытлы гына булды».

*Гүзәл Юнысова,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

# ШАКИР МОСТАЕВ ИСТӘЛЕГЕ

*Тукайның үлеменә өч ел тулу уңаеннан «Сүз» газетасының 1916 елгы 3 апрель (41 нче) саны шагыйрьгә багышлана. Газетаның әлеге санында Шакир Мостаев (Шакир Мостафа)ның «Рәхмәтле Тукай» исемле язмасы урын алган. Мәскәүдә яшәгән касыйм татары прозаик, шагыйрь, публицист Шакир Мостаев белән Тукай якыннан таныш булганмы, юкмы, анысы билгесез. Әмма «Актык сүзләр» мәкаләсендә («Яшен», 1909, № 6), «Әхбар» газетасында (1908, № 65, 66, 68, 69, 71, 73, 76, 78, 79) дөнья күргән «Замана хикәясе» исемле әсәренең төп геройлары Фәүзи, Ләмигалар телгә алыну, Тукайның Ш. Мостаев әсәрен яхшы белүе хакында сөйли.*

*Ш. Мостаевның әлеге мәкаләсендә Тукайга «XX гасырда Идел буе шагыйрьләренең таҗын» кидерүе, аңа булган зур хөрмәтен, чиксез ихтирамын күрсәтә.*

## Рәхмәтле Тукай

Бөтен, барлык дөньясына берьюлы яки берәмләп, кирәк тышкы күренешенә, кирәк эчке рухи хәлләренә күз салсагыз – каршыгызда, күзләрне камаштырган, хыялыгызга иксез-чиксез мәйдан ачкан, фикерегезгә тиңсез азыклар биргән тәгьбире өчен *(фразасы өчен)* санаулы хәрефләрдән ясалма сүз җиткерә алмаслык бер хәл, бер мәгънә барлыгын күрерсез, тоярсыз.

Бу хәл, бу мәгънәне күрүче, тыючы, үзе мәнсүб булган *(караган)* мәсләге, мәнсүб булган сыйныфы, сыйдыра алган кадәр хәвасләсе *(хисләр)* даирәсендә, каршысындагысын аңларга, тәгъйин итәргә *(ачыкларга)* көчләнә.

Үзенең санаулы белеме, чикле мие, тарафдар мәсләге, сыйнфый мәгълүматы арасыннан мөнасиб *(яраклы)* мохит тәгъбир таба алмыйча җөдәп исергәнгә, иң мөкатдәс белгән исем белән ятлап, шул исемне аңар тагып юанмакчы була. Я бөтенләй гыйсъян итә. Һәр барлыкны инкарь итәргә тотына.

Күктәге йолдызлар, җир йөзендәге матур табигать, матур киенгән гүзәлләрне күргән бер илаһи, «кайда карасам Алланы күрәм, башкаларны буш хыял, я көзгедә гакесләр *(чагылышлар),* я җиргә төшкән күләгәләр генәдер» ди башлый.

Җаны үзенә татлы булган бер динче, бу мәгънәдә чиктән тыш бер нәрсә табып куркына, ут газабыннан сакланыр өчен Аллага сыгына башлый.

Бер фән мөтәхассыйсы *(белгече)*, кирәк табигатьче булсын, кирәк риязы *(математик)* булсын, берсе каршысындагысының гәүдәсендәге кисәкләрне җентекләргә керешә, икенчесе аның аркылысын буен үлчәргә башлый. Ләкин берсе дә шуңар мөнасиб *(яраклы)* мохит, бер тәгъбир белән күз алга ясап чыгарып бирә алмыйлар. Берсе дә табигать галименең һәммәсенә бертигез мөнәсәбәттә тора алмыйлар. Һәркайсы үзенә якыныракны, хәвасләсенә *(күңеленә)* сыйганыракны, тормышы өчен файдалыракны сайлый, шуны гына аңлый, шуны гына тәкъдир итә.

Барлык галимнең һәммәсенә: зурысына, кечесенә, көчле-көчсезенә барында да туктаган, һәммәсен дә бер күз салу белән эченә кереп күргән, Алланың үз кулы белән, үз табигате белән җитештергән бер шәкерте бар – шагыйрь. Бу шәкерт пакъ тойгысы, үзенә аерым бер күрү белән, табигый бер мәһарәт *(осталык)* белән әлеге санлы сүзләр теземеннән ад *(исем)* бирә. Күзгә күренми, кулга тотылмый торган әйберләрне мөҗәссәм иттереп *(гәүдәләндереп)* күрсәтә ала.

Гади күзләр төшке кояш, я шуның кебек ялтыравыклы, шалтыравыклы әйберләргә генә, һәр ягы килгән, киенгән гүзәлләргә генә сәҗдә итсә, шагыйрь күзе сулгач, аяк астына ыргытылган букетка сәгатьләрчә тукталып, йөзләрчә сәхифәгә җитәрлек дәһшәтле нәрсәләр күрә.

Урам чатында сөялгән, ташландык татар кызына карап, бер сания *(секунд)* эчендә бөтен мәнсүб булган халкының рухи, иҗтимагый тормышларын иң назик *(гүзәл)*, иң тирән почмакларын күз алга китереп сала.

Бер фән кешесе чикерткәнең ботын «дүлә»ләп *(доля)* үлчәсә, бер чебеннең күзен җентекләсә, канатындагы төсләрен тәхлил итсә *(аерса)*, бер мачының тырнаклары эчкә батуындагы серләрне уйласа, бер сәүдәгәр аның тиресен кайда күбрәк сатарга мөмкинлеген эзләсә, шагыйрь, бөтен җир шарын оясына ташыр дәрәҗәдә комсызлык күрсәткән кырмысканы сөйләтә. Язып утырган җирендә кибеп бетмәгән язуларыннан карасын суырырга юлышкан чебен белән иптәшләрчә сохбәт итә *(әңгәмә кора)*. Мачының йомшак түшәп, каты йоклатуындагы интригаларын бер карауда үзеннән игътираф иттертә *(гаебен таныттыра)*. Һәммә бу сүзләрне, җанлы-җансыз, телле-телсез әйберләрне халык теле, халык аңы, аның садә, табигый, эчсез-керсез аңына ягымлы рәвештә сөйләтә. Гади күзләрнең гакылларын шашырган көч белән үзләшә, аның телен,

рухын төшенә, соңыннан аны адәм баласы аңларлык калыпка куеп ясап чыгара.

* * *

Шагыйрь табигате белән һәр галим, һәр мөтәфәннин *(энциклопедист)*, һәр хаким, һәр мөтәсәллитъдан *(изүчедән)* өстен, көчле булганга, күп вакытта көчсез якка чыгып, көчлеләргә каршы мәйдан укый. Аларга һөҗүм укларын яудырырга башлый.

Буның белән шагыйрьнең көче кимеми. Сауган саен килгән сөт кебек өстәлә генә бара. Шуңар күрә җан көйдергеч туп утларына каршы күкрәк киергән командан, бөтен мәхәлләсенә фиргавен ролен уйнаган кама якалы дамелла, кечкенә бер капризы өчен кибеттәге приказчикларын пыр туздырган, ияк асты түшенә тоташкан зур корсаклы купец, мәгърур аксөяк, аполитлы *(искитмәүчән)* бер чиновник шагыйрьнең икеюллык шигыре каршысында баш ияргә мәҗбүр булалар.

Адәм углы җир шары хәятындагы тарихтан элекке дәверләрдән бирле, көчлеләр белән тартышкан шагыйрьләрдән буш тормады. Бу кыйсем шагыйрьләр табигать сөреше белән араларындагы дәһшәтле хәлләрне азмы-күпме тәгъдил итә *(йомшарта)* килделәр.

* * *

Шигырь – садәлек *(гадилек)* эчендәге нәзакәтьтән *(матурлыктан)* гыйбарәт булганга шагыйрьләрнең рухларындагы нәзакәть дә садәлектән гыйбарәт була. Шуңар күрә шагыйрьләр, табигатькә якын булган «халык» аталган сыйныфка якын торалар. Халыкның садә рухы шагыйрь рухы өчен, җир шарын вакытлыча мескен итеп, ихтыяр иттерә. Шагыйрь аның хыялына киләчәктә хакыйкатькә әйләнәчәк иттереп көч, азык бирә.

Башук рухы шигырьдән башка хыялга китерү мөмкин булмаганга, җанлы вә җансыз һәр әйбер шигърияттән буш түгелдер.

Табигый хәяттә бу шулай булган кебек, мәдәни-иҗтимагый хәрәкәтләрнең инкыйлаб дәверләренең башын, гамәлен, җеп очларын җентекләсәк, тарихларын тикшерсәк, сүнәр-сүнмәс шәм янында төн уртасында сулган йөзле шагыйрьнең нәзек бармаклары арасыннан түгелгән сәтырларга *(юлларга)* килеп терәлгәнен күрерсез.

Татар әдәби, милли инкыйлаб дәверендә дә бу җепләрнең бер очы «Ислах» идарәханәсендә һәм «Болгар» мөсафирханәсенең 40 нчы номерында баркадәр гәүдәсе бер рухтан гыйбарәт Тукайның каләм очына килеп тукталадыр.

* * *

Тукай – бер шагыйрь. Бер сәнгатькәр булудан өстен бер татар милли шагыйре иде. Дөрест, аның татар рухын сугару юлындагы шигырьләрен санамаганда да, бер сәнгатькәр булуы гына да, Тукайга XX гасырда Идел буе шагыйрьләренең таҗын кияргә хак бирәдер. Чөнки Тукайның язган шигыре генә түгел, гади сөйләгән сүзендә, хосусый мәктүбләрендә, 24 сәгать эчендә йөз кат телгә кереп чыккан гади сохбәтләрендә *(әңгәмәләрендә)* дә бер аһәң, үзенә аерым бер шигърият, бер нәзым табигыйлек бар иде. Бунның өстенә ул татарның мәдәни уйгану дәверенә тәсадеф иткәнгә *(кагылганга)*, яшь татарга аның мәктәпле, телле, әдәбиятлы, мәгарифле татар милләте булып, борынлавы өчен нык өмид орлыклары чәчте.

Тарихта онытылыр дәрәҗәгә төшкән бетә-батам дип чайкалып торган татарның бу фаҗигасенә сәбәп булган гамәлләренә каршы кискен вә парлак *(данлыклы)* сугыш ачты.

Гаиләләрдәге иҗтимагый дорфалыкларны мәйданга куйды.

Мәдрәсәләрдәге Бохара калдык-постыкларын селкеп салды.

Мазыйсыннан *(үткәненнән)* сукыр татарга, тарихын, шан вә шәүкәтен исләтте.

Яшь татарның өмет гөлләрен сугарды, гая әмәл *(ышаныч)* тудырды, рухын сыйпады.

Татар үз шагыйрен һәммәдән элек шул ноктадан таный. Аны бер пәйгамбәрдән, бер реформатордан көткән кебек, халык хамисы *(яклаучысы)* итеп күрә.

Үз рәтендә Тукай боларны, аңар татарның сыгынуын күрсә дә, сизсә дә мәгърур булмады. Ул «башыннан сыйпап үстергән милләтенә» каршы үзендә бер вазифа шинаслыктан *(белгечлектән)* артык әйбер, «бер татар углы» булудан өстен нәрсә танымады.

Һәр шагыйрь кебек Тукай да бөеклекне, матди бөеклектә, дәрәҗә зурлыгында, акча күплектә дип ышанмаганга, бәлки хөлусда *(ихласлылыкта),* сафлыкта, садәлектә икәнен нык сизгәнгә, борынгы черегән татар гонсыры *(токымы)* карашында «бөек» танылган һәйкәлләргә исе китмәде. Җаннарына сугылмады. Үзләре кагыла икән «Гадәмең *(юклыкның)* улы!» диде, якын юллатмады *(җибәрмәделәр)*.

* * *

Тукай бер татар углы булса да, халис *(чын)* табигать баласы, тирә-якның төрле дорфа тәэсиреннән котылырга муафикъ бул-

ган, халис табигать баласы, тирә-якның төрле дорфа тәэсиреннән котылырга муафикъ булган хирыс *(комсызлык)* вә тарафдарлык белән күзне сукырайта торган сыйнфый мәсләк тәэсирләреннән югары табигать җимеше иде.

Бәхетенә каршы кечкенәдән үк кем химаясенә *(яклавына)* да сыгынырга туры килмичә, чикләнгән канат астында калмыйча рухан ялгыз җитешү аңарда һәрнигә сынап карау, ышаныр-ышанмас карауны тудырган. Булачак шагыйрьгә, кечкенә башыннан ук үзенә генә таяну, үзеннән генә көтү игътикадын *(ышануын)* нык беркеткән.

Тирә-яктагы кара көч, гәүдә көчләренә ышанычсызлык тойгысын үстергән. Аз сүзле, уйчан, шыпырт кына, тавышсыз-нисез генә һәммә тирә-ягын, бара торгач, бөтен хәят агымын каш астыннан сынап торучан, барысы хакында үзенә аерым бер караш асраучан итеп хәзерләгән.

Ата-анасыз җитешкәннәрнең берәр юлда каһарман булып чыгулары, киресенчә әйтсәк, каһарманнарның күп чакта ата вә аналарсыз үскән булуы тәрҗемәи хәлләрдә очралган кебек татар инкыйлаб дәверендә дә Тукай тәрҗемәи хәлендә очраладыр.

* * *

Икенче апрельдә рәхмәтле Тукайның сөйкемле рәсеменә карап, талып утырган чактагы тәэсириятемне шагыйрьнең гали рухына багышлыйм.

*Кереш мәкаләне һәм текстны басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре,*
*филология фәннәре кандидаты Эльмера Галимҗанова әзерләде*

## «ЕРАК ШӘРЫК» ЖУРНАЛЫНДА ДӨНЬЯ КҮРГӘН КАЙБЕР ЯЗМАЛАР

Ерак Көнчыгыш илләрендә яшәүче төрки-татарларның тормышы Русиядә булып узган 1917–1920 елгы Октябрь инкыйлабы һәм Гражданнар сугышы вакыйгаларыннан соң шактый үзгәрешләр кичерә. Русиядән килгән яңа мөһаҗирләр хисабына сан ягыннан шактый күбәю белән беррәттән, биредә яшәүче татарларның милли, сәяси, мәдәни яшәешендә дә шактый җанлану күзәтелә. Яшьләр, хатын-кызлар өчен милли оешмалар, балалар өчен яңа мәктәпләр эшли башлый.

1920 еллардан башлап Ерак Көнчыгышта, бигрәк тә Кытайда һәм Япониядә татар эмигрантларының вакытлы матбугаты барлыкка килә. Шул басмаларның беренчесе итеп Харбин шәһәрендә нәшер ителгән «Ерак Шәрык» журналын атарга мөмкин. Ул 1920–1922 елларда Гыйниятулла Әхмәди, Хөсәен Габдүш һәм Рәшит Рәхмәтиләр тырышлыгы белән дөнья күрә. Журнал гарәп хәрефләре белән кулдан язып әзерләнә, ташбасма ысул белән басыла. 1922 елда журнал чыгуыннан туктап тора, 1924 елда исә шул ук исем белән газета буларак чыга башлый. Әмма 1925 елны бу газета да нәшер ителүдән туктый[1].

Журналда икътисади, иҗтимагый-сәяси, дини эчтәлектәге мәкаләләр басылу белән беррәттән әдәби әсәрләргә дә шактый урын бирелгән.

Журналда басылган мәкаләләр арасында Г. Тукайга мөнәсәбәтле язмаларны да очратырга мөмкин, шуларның берсе – «Ерак Шәрык» журналының 1921 елгы 21 нче санында «Тукай кичәсе» дип аталган, «Берәү» имзасы басылган билгесез автор мәкаләсе.

Икенчесе – журналның 1921 елның 22 нче санында басылган Хатыйп Халидинең «Габдулла әфәнде Тукай (вафатына 8 ел тулу мөнәсәбәте белән)» исеме белән дөнья күргән Тукай турындагы хатирәсе. Язманың авторы Хатыйп Халиди (1893–1977/1978), тумышы белән Татарстан Республикасы Апас районы Карамасар авылыннан. Әлеге автор турында мәгълүмат татар матбугатында юк дәрәҗәсендә. Шулай да, Төркиядә чыккан «Төрек культуру», «Казан» журналларында дөнья күргән кайбер язмаларга таянып язылган «Безнең мирас» журналында басылып чыккан мәкаләбездә Х. Халиди турында шактый мәгълүмат бирелде[2].

Әлеге басмада «Ерак Шәрык» журналында, басылган бу ике мәкалә гарәп язуыннан гамәлдәге язуга күчереп, укучыга тәкъдим ителә.

## Тукай кичәсе

16 апрель 1921 ел, шимбә көн шагыйремез Габдулла әфәнде Тукайның вафатына 8 ел тулу мөнәсәбәте берлә Харбин мөселман төрек-татар яшьләре түгәрәге тарафыннан Тукай кичәсе ясалып

---

[1] Насыйров Т. Татар мөһаҗирләре матбугаты // Казан утлары. 2001. № 7. Б. 161–162.

[2] Ханнанова Г. « Нинди батыр бала!» // Безнең мирас. 1915. № 4. Б. 24–25.

үтте. Һәр елда аның вафат көнен хәтерләп килгән Харбин, бу ел да шул көнне искә алып, сөекле шагыйрен алкышлады.

Кичәнең беренче бүлеменең башында Гыйниятулла Әхмәди Тукайның кыскача гына тәрҗемәи хәлен сөйләп, халыкның аңа булган карашларын һәм шуларның эчендә күбрәгенең олуг кешемезне тиешле рәвешдә тәкъдир итә белмәүемезне күрсәтүләрен вә ул карашларның да Тукайны танымаганлыкларындан гына килеп чыкканларын әйтеп узды.

Мондан соң Тукай тәрҗемәи хәленең бөтенләе берлә диярлек, мөмкин кадәр кызганыч манзараларын гына алып, аның көндәлек тормышына гына гаид булган[1] якларын ачды.

Хатибның үз сүзендәге берничә җөмләләр берлә файдаланып, берничә теләк әйтеп китү урынсыз булмас, дип уйлыйм. Тукайның кем икәнлеген һәм аның безнең иҗтимагый хәятымызда вә әдәбиятымызда тоткан урыны нидән гыйбарәт икәнлеген белмәгәнлекемездән шагыйремезгә тиешле бәһа куя белмибез, ди. Һәм бу кыйсмән[2] дөрест дә. Тукай үлгәч тә аның хакында язылган нәрсәләр һәм һәр ел эшләнгән Тукай кичәләрендә сөйләнгән сүзләрнең бары да диярлек аның: яланаяк бәрәңге казуы, кулдан кулга күчеп йөрүе, үги анасының «Үксез бала асрасаң – авызың-борының кан итәр, үксез бозау асрасаң – авызың-борының май итәр» дигән сүзләрен кабатлап, җыелган тыңлаучыларның бөтен дикъкатьләрен аның тормышының шул ягына гына тартдырыла, халыкның уен, зиһенен шулай матур җыештырылган кызганыч манзаралар кузгата торган сүзләр берлә сихерләнә килде. Шулай булгач, аның әсәрләре берлә якыннан таныш булмаган бер кешедә нинди тәэсир кала һәм аның Тукай хакында фикерендә тудырган аңы нидән гыйбарәт булып кала.

Сүз кем хакында? Ул нинди кеше? Ни өчен аның хакында сөйләнә? Ул халык үзе төшенергә, бу мәсьәлә берлә бәйләнгән башка сөальләргә дә үзе җавап хәзерләргә тиеш.

Тукай кем соң? Ни өчен без аны сөямез? Ни өчен ел саен аны хәтерләп алкышлыймыз?

Хәзерге көндә безне Тукайның бала вакытда кичергән эшләре түгел, менә бу көнге мәүкыйгы[3], аның эшләгән эшләре,

[1] *Гаид булган* – караган.
[2] *Кыйсмән* – өлешчә.
[3] *Мәүкыйгы* – тоткан урыны.

иҗтимагыятемездә калдырган эзе кызыксындыра. Без, Тукайны бала вакытда яланаяк йөреп, үксез булып, кулдан кулга күчеп, ярым ач, ярым тук хәленчә, егълап, сыгътап, төрле нахак сүзләр ишетеп хурлануы өчен кызгану урынына аның эшләгән эшләрен, үземезнең милләт уларак берләшдергән әдәбият, телемезне ислах юлында күрсәткән хезмәтен белеп, аны алкышларга, аны кызганыч бала хәлендән чыгарып, шадлык берлә мәгърур хәлдә исемен әйтергә өйрәтергә тиешмез.

Тукайны кызганычрак күрсәтер өчен булырга кирәк, сөйләүче тарафыннан кулланылган «Тукайны сату, Тукайны .....[1] шикелле сүзләр дә колакка ят ишетеләләр һәм ислам мәдәниятен, төрек-татарларының инсан уларак оешканлыкларын күрмәскә тырышучылардан башкаларда рух рәнҗүе чыгаралар иде.

Кичәнең бөтен программасы, берничә Тукай хөрмәтенә җырланган җыр вә шигырьләр укуларны алмасаң, Тукайның үз шигырьләрендән тәртип ителгән иде.

Шигырьләрне уку вә алардан алган тәэсирдән артык бөек иде.

Берничә яхшы эшләнгән күренеш вә укуларны истисна иткәндә[2], бигрәк тә Тукайның үз әсәрләрендән берничәсен укуны өстләренә алган әфәнделәр Тукайга шулкадәрле игътибарсыз кыландылар ки, сәхнәдән ишетелгән сүзләрнең Тукай шигырьләреме яки шул башкаручыларныкымы икәнлегендә шөбһә туды. Шигырь бүлемләре арасындагы кул, йөз кыланышлары урынына әйтелеп торган берничә ят сүзләр һәм вакыт-вакыт шигырьнең сүзләрен бер урындан икенче урынга күчерүләр, соңынтын, бигрәк дә хөрлек сизеп, берәр юл артдырып йибәрүләр һәм шундый эшкә булган шаблонный карашның башка бер кичәдә булмый, Тукай рухына багышланган кичәгә тугры килүе тыңлаучыларда, әдәбият мөхибләрендә начар тәэсир калдырды.

Тукай шигыренең зуррак әһәмияте дә аның телендә, шигыренең чын халык сүзе берлән колакка тигез музыка тудыруында булганга күрә, ул нәрсә югалу берлә шигырьнең дә әдәби кыйммәте югала.

---

[1] Күп нокталар урынындагы сүз укылмады.

[2] *Истисна иткәндә* – аерып алганда.

## Габдулла әфәнде Тукай
## (вафатына 8 ел тулу мөнәсәбәте белән)

Ни өчен әдипләремездән Габдулла Тукайны башка әдипләребезгә караганда артык искә төшерелә? Чөнки Габдулла Тукай бөтен вөҗүде белән[1] халкын сөеп, чын ана телендә тирән мәгънәле, мәктәпләребезгә дәрес итеп кертерлек, мисал вә дәлил итеп күрсәтерлек, халкыбыз арасында булган каралык, гакыл вә дингә хилаф гореф вә гадәтләрне халкының кәеф вә хәтерен калдырмаслык ачык вә матур гыйбарәләр белән тасвир вә тәгъбир итеп, милли вә дини хис белән язылган кыйммәтле шигырьләрен бөек хатирә итеп калдырды. Шуның өстенә вакытсыз, яшьли вафат булуы ныграк искә төшертә.

Бер кеше үзенең бик файдалы вә кыйммәтле нәрсәсен югалтса, ничек кайгыра вә аны вакытында саклый алмавына үкенә, шуның кебек Тукайны югалткан татар милләте дә кайгыра вә аны вакытында саклый вә кадерли алмавына үкенә һәм вафаты көннәрендә матәм тота. Шуның өчен татар милләте үзенең шагыйрен искә төшерә, мәктәп балалары ул көн дәрестән туктап, матәм көне ясыйлар, догалар кылып рухына багышлыйлар. Бәгъзе бер гәзитә вә журналлар шул вакытта чыккан саннарында Тукайның татар шагыйре икәнен, халыкның нечкә хисләрен, моң вә зарларын, телен әдәби итеп мәйданга куюын тәкъдир итеп язалар вә аның хакында булган хатирәләрен зикер итәләр[2].

Мин дә мөхтәрәм затның вафатына сигез ел тулу мөнәсәбәте белән аның хакында булган кечкенә генә хатирәмне язып үтәм.

Тукай садә табигатьле[3], ачык чырайлы, һәрвакыт нәрсә булса да көйләп, яхуд[4] Коръән аятьләре укып йөри иде.

Бер вакыт 1908 елда «Сабах көтепханәсе»ндә утыра идем, кечерәк кенә, өстенә гади генә тужурка кигән, ялан баш, бала сымак кеше көтепханә ишеген җелтерәтеп ачып, «Вәш-шәмсе тәҗри ли-мөстәкаррин ләһа...» [5] аятен кычкырып укый-укый, еш-еш атлап эчкә керде дә, минем янымда тора торган «Сабах көтепханәсе»

---

[1] *Вөҗүде белән* – барлыгы белән.

[2] *Зикер итәләр* – искә төшерәләр.

[3] *Садә табигатьле* – эчкерсез.

[4] *Яхуд* – яисә.

[5] Коръән, «Йасин» сүрәсе, 38 нче аять. Мәгънәсе: «Кояш Аллаһ билгеләгән вакытка чаклы үзенең юлында йөреп торадыр...» (Ногмани. Коръән тәфсире // http://kitap.net.ru/sura/36.php).

ширкәтенең әгъзасы белән күреште. Ширкәт әгъзасы, аның белән таныш булмавымны белгәч: «Танышыңыз, менә Габдулла әфәнде Тукаев», – дип мине таныштырды. Мин, ул ишектән кергәндә: «Бу нинди батыр бала, ишекне җелтерәтеп ачып керә, җитмәсә тагын Коръән укый-укый керә», – дип уйлаган баласымагым, шагыйрь Тукай булып чыкты. Шушы Габдулла әфәндене беренче мәртәбә күрүем вә танышуым иде. Минем Казанда беренче ел мөгаллимлек вазифасын үтәп торган вакытым иде. Шуның өчен ул миннән ана теле дәресләре хакында бәгъзе бер нәрсәләрне сорашты. Соңра, озак вакыт үтмәде, дәфгатән[1]: «Тизрәк, тизрәк, карандаш бирегез әле», – дип карандаш сорады, вә үзе китаплар төреп йибәрә торган кәгазьдән бер кисәк кәгазь җыртып алды да, әллә нәрсә тиз-тиз генә язып кесәсенә салды һәм: «Күңелемә бер шигырь килде дә, шуны онытылмасын өчен язып куйдым әле», – диде. Соңра җомышын җомышлады да, кергән вакыттагы адымнары белән әллә нәрсә көйли-көйли чыгып китте.

Аннан соң номерында берничә мәртәбә булырга тугры килде. Һаман ана теле вә әдәбиятымыз хакында кайгырта, мәктәпләребездә ана теле дәресләренең юлга куелып бетмәвенә эче поша иде. Бервакыт номерында, тәрәзә төбендә әллә никадәр төрле шигырьләр язылган кәгазь кисәкләрен күрдем дә: «Габдулла әфәнде, кыйммәтле шигырьләрегез язылган бу кәгазь кисәкләре югалгалап та бетә торгандыр», – дидем. Ул: «Туган, мин күңелемә килгән берен язган да, шунда вакытлы гына ташлаганмын, теләгән вакытымда мин аларны җыеп бер дәфтәргә яза барамын», – диде.

Шулардан аңлап була, Габдулла әфәнде үзенең шигырьләрен күп вакыт көчләнеп язмаганлыгы, кайда гына булса да аның күңеленә килгән вә аны шул ук вакыт кәгазь кисәкләренә яза барганлыгы. Моны Тукай белән якыннан таныш затларның күбесе шулай сөйлиләр.

Алла тарафыннан татар милләте бәхете өчен бүләк ителгән талантлы шагыйрь аз вакыт эчендә халкына ничә миллионнар торырлык кыйммәтле хатирәсен калдырып, вакытсыз дөньядан китте.

*Кереш сүзне һәм текстны басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге*
*фәнни хезмәткәре Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

---

[1] *Дәфгатән* – кинәт.

## *Шигырьләрдән килер миңа кирәк җылы*

**Тукай кабере янында**

Ята рәхәт кенә сулыш алып,
нурланган ай монда,
Сөйәм соң каберине, күңлем якын
күргән Тукай монда.
Чыга яшерен генә моңлы сүрән
алсу булып мондан.
Вакыйга шагыйрь өчүн хасыйл
истирахәтгяһ җай монда.
Очып килде күгәрчен бу кабергә
кайгы-моң берлә,
Диде күкләрдә очкан иң якын
дустым, һай, монда.
Йыглыйм күз яше берлә, бигрәк
сагындым бу Тукай кабрен,
Бу төшдән элек күңлем кабул
иткән аның кадерен:
Күңел әрни, йыглый, сыкрый,
тибә, безнең Тукай кайда?
Ничек шул хәлләр тар йиргә
сыйдырган ул җиһан зәһрен.
Гарешдә очды ак җаны төшәргә
хурланып йиргә.
Вәләкин бу фәлән дошман икән
күкдә очар иргә.
Зарар йук инмәкендин йир
йөзинә гарешдән Җабраил.
Гарешдән йиргә күк инде ни
ноксан булды Җабраилгә.
Үбәм кабреңне кайнар күкрәгем
Берлә, газиз йулдашым,
Сине төшдә күрермен, ихтимал
туфракка куйдым башым.

М. Фәйзи

*Текстны, гамәлдәге язуга күчереп, басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре, филология*
*фәннәре докторы, профессор Марсель Әхмәтҗанов әзерләде*



1

مرحوم شاعر توقایف روحینه .

ای بو ملتنڭ قدرلی گلنیازی الفراق !
ای بتون آدملرنڭ کوڭل قیاشی الفراق !

ای یورەك باغندە غمی بلبل ثناسی الفراق !
خدمت ایتدنڭ ملتە غیرتلرنڭ هیچ سونمیچە
کیچلرن کوندزلرن هیچ بر طنچلق کورمیچە
کوڭللڭ اویلاندی خلق آغی بلەن بر توقتامی
قویمادی آلتون قولڭ آخر قلمنی اولمیچە
رحلتڭ مجروح قلبکە صالدی بر دهشتلی الم
آه! نیچك بو قطرەیە یازغان وقت تتری قلم
منگو اوزلماس قلبدن
منی ریاض الجنە اولسون مرقدڭ ای محترم !
تا قیامە صایراسن ایندی روحڭ گلگە قونوب
مغفرت استەب سیڭا ربم خدا نە یولقونوب
سیناتڭ ایزگیلك برلەن کیچرسن دە خدا
یوقلانغل ایندی الهی نعمتە نوره چوموب !

٤ آپریل . ا. عابدی .

Библиотека С. Г. ВАХИДОВА

И. Габидинең «Мәрхүм шагыйрь Тукаев рухына» шигыренең кулъязмасы.
Автограф // ЯhММҮ. 53 ф., 5 тасв., 7 с.б.

## Мәрхүм шагыйрь Тукаев рухына*

Әй, бу милләтнең кадерле гөлниязы[1], әл-фирак[2]!
Әй, бөтен адәмләрең күңел кояшы, әл-фирак!
Әй, йөрәк багындагы былбыл шинасы[3], әл-фирак!
Хезмәт иттең милләтә гайрәтләрең һич сүнмичә.
Кичләрен, көндезләрен һичбер тынычлык күрмичә
Күңелең уйланды халык агымы белән бер туктамый
Куймады алтын кулың ахыр каләмне үлмичә.
Рихләтең[4] мәжрүх[5] калебкә[6] салды дәһшәт, әләм[7]
Аһ, ничек бу тәгъзия[8] язган вакыт тетри каләм
Мәңге онтылмас калебтән
Мин рийазил-җәннәулсын[9] мәркадең[10], әй мөхтәрәм!
Та кыямәт[11] сайрасын инде рухың гөлгә кунып.
Мәгъфирәт эстәп[12] сиңа Раббым Ходага йолкынып
Сынаттың изгелек берлән, кичер Син дә, Хода,
Йоклагыл инде, илаһи нигъмәтә, нурга чумып!

4 апрель,
И. Габиди

*Текстны, гамәлдәге язуга күчереп, басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге*
*фәнни хезмәткәре Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

---

* ЯһММҮ, 53 ф., 5 тасв., 7 с.б.
[1] *Гөлниязы* – тансык, кадерле гөле.
[2] *Әл-фирак* – «Аһ, аерылышу» .
[3] *Былбыл шинасы* – былбылны аңлаучы.
[4] *Рихләтең* – (ахирәткә) күчеп китүең.
[5] *Мәҗрүх* – яралы.
[6] *Калебкә* – күңелгә.
[7] *Әләм* – кайгы, хәсрәт.
[8] *Тәгъзия* – күңел юату (кайгы белдерүче язма).
[9] *Мин рийазил-җәннә улсын* – җәннәт бакчаларының (берсендә) булсын.
[10] *Мәркадең* – кабереӊ.
[11] *Та кыямәт* – кыяматкәчә.
[12] *Мәгъфирәт эстәү* – (Алладан) кичерүне үтенү.

**Хөрмәтле шагыйремез Тукаевка***

Җан биреп, кочтың ләхет – үлдең шагыйрь, булдың фида,
Калды егълап бәгъре илең, мәрсия итеп сиңа.
Белмәдек кадереңне без тик сау көнеңдә, аһ ... шагыйрь,
Тик хәзер белдек соңыннан куенына кыскач кабер.

Җолкынып очтың фәләктән, ташладың син йир йөзен.
Иң элек ил бәгырьне җырлап йоткан син идең,
Яра иде үткен тойгың тауның ярын, диңгез төбен.
Әрчегән бердәй күреп упкынлы төн, якты көнен.

Ялгызың калдың елап яшьтән моңайдың, җырладың.
Яндырып күкрәк утын, очты гарешкә инде җаның.
Тән генәң йоклар ләхеттә, көн үтәр, кабереңбасар.
Ядкәреңүлмәс, ләкин һич ул калыр, бездә яшәр.

Өстеңдә йолдыз карап, ай да карап еллар үтәр,
Уйланып кабереңбашында кап-кара таш та көтәр.
Һәм шулай таудан карар, чыккач кояш та иртән үк,
Әмма син юксың аларга, аштың гарешкә күптән үк.

Ягъкуб Айманов

---

* Кояш. 1913. 9 апрель.

**Инна лиллаhи вә иннә иләйhи ражигун**
**Мәрхүм Тукайга матәм***

Югалды нурлы бер йолдыз арадан,
Хәзер югалды бер ак йөз, карадан.
Әйтеп «Әрҗигый ...» әмеренә итагать,
Фәна йортыннан бәкага кылды рихләт.

Күмелде җисеме туфракка – пракка,
Вә ләкин калды мәңге ядка.
Тукай исеме әбәд китмәс күңелдән;
Ничек балланмасын корт иске гөлдән.

Аның хисе белән исеме күземдә;
Җиhанның хәсрәте әйткән сүзендә!
Аның hәрбер моңында утлы ялкын,
Сараенда зөбәрҗәт, энҗе, алтын!

Аның ялкыннары – ялкыннармыдыр,
Аның алтыннары – алтыннармыдыр.
Бүген күз яшьләрен калдырды безгә;
Гаҗәпме, булса дәрман, хаста күзгә?

Бөтен зары, бөтен аhы шагыйрьнең,
Кәчүк hәм яшь кенә даhи шагыйрьнең,
Сурәтләнгән күз алдымда кояш күк.
Тәәссеф, мең тәәссеф, күчте инде;

Шәрабыннан әҗәлнең эчте инде.
Үзе күчкәндә гөлзары калды.
Бөтен фөрьяды, үткен зары калды.
Сыйдырмас тар кабер шул диңгез аhын.
Гаҗәпме? Җуйса бар аhы, гөнаhын!
Ходай рухыңны итсенче рәхәт,
Шагыйрь, кабереңдә ит бер истирахәт.

Мөхәммәдвакыйф Җәлал

* Йолдыз. 1913. 4 апрель.

**Габдулла Тукай хәзрәтләре өчен***

И фәләк, золымың биек таудан биек, аннан авыр!
Ләкәнрә авылы матур, былбылны да корган увың.
Сулды бит чын чәчкәсе, иң чын гөле бер бакчаның.
Көл, яса бәйрәм фәләк! Булды хәзер зур максадың.

Сүнде бит иң нурлы кояш, каплады көнне болыт.
Бар мәләкләр кайгырып егълауда, бик мәэюс булып.
Нурлы кояш, исле гөл, былбыл кошы да ул иде.
Сүнде кояш, үлде былбыл, сулды гөл мәңге булып.

К. Хамадов

* Йолдыз. 1913. 4 апрель.

**Шагыйрьнең соңгы аһлары***

«Юк, үләм!» ди моңлы көйләр патшасы,
«Тормышым караңгы, әрни яшь җаным...
Кара көчтән куркынычрак алдагы
Көннәр... рухсыз чыга бар язганым!..
Мин күрәм – комсыз үлем алда тора,
Юк йөзендә аслан шәфкать чаткысы,
Тырыша кыскартырга көнне, уй кора.
Күзләрендә юк мәхәббәт яктысы...
Ак кәфенлектә алып килгән, күрәм..
Бу ни? Әллә ачыла каберем тактасы?..
Бер бурычлы кеше төсле әрнешәм –
Файда юктыр: булса сүнгән яктысы
Тормышымның... Аһ! Рәхимсез бу үлем
Мине халкымнан аермакчы була,
«Бетмәгән халыкка минем әйтеп сүзем!»
Килсә шул хәтергә, күзгә яшь тула..
Мин шигырь яздым.. Язудан максатым:
Халыкны үгетләү, нәсыйхәтләү иде;
Булмады... Тик ихтыярсыз ташладым:
Нәрсә илһам сөйләде, рух хушлады..
Тик мине шатландыра бер ак фикер:
Бәлки мин чәчкән мәхәббәт орлыгы
Буш югалмас; бер сабый ядына керер
Һәм үсәр – булса да энҗе зурлыгы!»

Фәхрелислам Агиев

---

* Йолдыз. 1913. 4 апрель.

**2 нче апрель тәәссефе***

Кайгырып, рухсызланып нурсыз кояш чыккан бу көн.
Күк йөзендә саф фәрештәләр йөзен чыткан бу көн.
Җир йөзендә милли күзләр яшь илән тулган бу көн.
Саргаеп, рухсызланып милләт йөзе сулган бу көн.

Сигез оҗмах капкасын ачкан фәрештәләр бу көн,
Егълыйлар тәүбә, тәзәррыгта гарештәләр бу көн.
Хезмәт итеп милләтенә, җан аямай төн вә көн.
(Иржагый) хитабәнә ул, буйсынып өченче көн,

Бер бөек шагыйрь җиһан берлән видаглаша бу көн.
Җир йөзендә барча җаннар егълап агълаша бу көн.
Миллият хисе йөрәктә бераз булса бу көн,
Ул кеше түзмәс, җылап күңелләре тулса бу көн.

Пакь тәнен ләхеткә, тар бүлмәгә салалар бу көн.
Саф җанын иманлы рухлар каршы алалар бу көн.
Дөньяда язды шигырь, тотлыкмады төннәр вә көн.
Әй Ходай! Тел ачкычы бир инде мәрхүмгә бу көн.

Г. Сәмигуллин

* Кояш. 1913. 4 апрель.

## Габдулла әфәнде Тукаев җәнапләренең вафат хәбәрен ишеткән чакта миндәге әрнелү*

Туган ил дип түбән һәр моң, көй, җырны, бөек ул, яшь йөрәк җырлап кичерде.

Вафа итте, сүзен тотты, эш итте;
Мәхәббәт, чын мөкатдәс юлга сөрде.
Кызыл, ал кан эчендә ил дип үлде,
Онытты үз-үзен – дәрман эчерде.

Аһ иткән, дәрман иткән гали ирне,
Бу көн милләт вакытсыз «аһ» очырды!
Йугалттык аһ! Шагыйрь, шир, япь-яшь ирне
Татар бәхетен вакытсыз йир яшерде!

Г. Нияз

* Идел. 1913. 5 апрель.

## Шагыйрь Габдулла Тукаев дарелбакайа рихләт итү мөнәсәбәтилә 4 нче апрель киченең матәме[1]*

Моң тавышлар яңгырата күк йөзен аһлар белән,
Балкыган ай җир йөзенә сиптереп яшьләр белән.

Нәрсәне җуйган бу төн, ай эзләнә сыкрау белән.
Юк, табалмый, мәңге тапмас җир йөзен эзләү белән.

Тик рухын тапса, табыр да, сөйләшер шатлык белән,
Салса күзен нурлы оҗмах багына дикъкать белән.

Тик фәкать кошлар тагы матәм тота кайгы белән,
Сайрыйлар хәсрәт утында ялкын очкыннар[ы] белән.

Юк йокы, очкан тәмам хәсрәтле кич тетрәү белән,
Ага кайнар яшьләре кошларның аһ-зарлары белән,

Аллага сәҗдә кылып, башны бөгеп сыгыну белән,
Аһ тәәссеф, мең тәәссеф[2] дип җылау, әрнү белән.

Йир йөзен баскан тәхәссер[3] мәңгегә килү белән.
Ни генә соң нишләсәң дә, йокла шул күңел белән.

Ә. Сәгыйди

---

* Кояш. 1913. 7 апрель.
[1] *Дарелбакайа рихләт итү* – вафат булу.
[2] *Тәәссеф* – кызганыч.
[3] *Тәхәссер* – кайгыру

**Мәрхүм иптәшем шагыйрь Габдулла Тукаев хакында**

Тәәссеф, мең тәәссеф безгә һәм милләткә бу көндә!
Түгәдер канлы яшь иптәшләре, һәр бәндә бу көндә,

Ничек түкмәскә, милләт үстереп кыйммәтле шагыйрен,
Югалтадыр, озата дөньядан бу көн кара гүргә.

Бар иде милләтен җырлап җырлаткан кты көннәре,
Хәзер инде җиһанда исеме бар, юк җисеме бу көндә.

Кичен көн дә шапырган: «Пушкиным бар дип», безем милләт,
Чигә һәртөрле хәсрәтләр бу кайгылы кара көндә.

Күрәм мин матбугатта җырларын җырлап рәхәт тапкан,
Күңел инде хәзер сынык вә рухсыз җыглый бу көндә.

Гомердә бер таралмаган былтыр да бирәләр юл.
Итән рухын шагыйрьнең изге фәрештәгә бу көндә.

Тырыштык милләтнең чун кыска гомерең кичмәде рәхәт,
Шуның чун һәрбер инсан теле җәннәт сиңа бу көндә.

Күтәрми сәҗдәдән баш һәр фәрештә һәм чигәләр гам,
Күреп изге шагыйрьнең нурлы рухын күктә бу көндә.

Галимҗан Акчурин

---

* «Йолдыз». 1913. 7 апрель.

## Тәгъзия
## Мәрхүм Габдулла әфәнде Тукаевка*

Шадыман[1] ул мәркадеңдә[2]! – Без онытмыйбыз сине;
Белмәдек вактында кадрең, инде котлыйбыз сине.
Яшьтәнүк бу милләтне син яктылыкка өндәдең,
Мәңге онытылмаслык эшләр, бик зур эшләр эшләдең.

И Ходаем, бир Син ул шагыйрьгә җәннәттә урын!
Ул синең колларыңа күп яхшылык кылган колың.
Шул шагыйрь берлән иде бу милләтнең бик күп эше.
Милләтә хезмәт кенә иде аның бар тормышы.

Киттеләр аны алып, агач табутка салып,
Хәсрәтеннән ничек түзик, безләр бу йирдә калып.
Китте ташлап шагыйремез, хәсрәтеннән янамыз,
Инде безләр бу көннән соң үги-ятим каламыз.

Аитова мәктәбе шәкертләреннән:
Г. Юнусова, Ф. Барышева

---

* «Бәянелхак. 1913. 10 апрель.
[1] *Шадыман* – шат, бәхетле.
[2] *Мәркадь* – кабер, гүр.

**Мәрхүм остаз шагыйрь Г. Тукаевка ядкәр**

Башка яктан аз кебек хәсрәт йотып яшь түккәнем,
Канлы хәнҗәр укларыңнан куркынып баш бөккәнем,
«Үлде ул!» дип кычкырып ярдың йөрәкне тетрәтеп,
Иң кара, кер көннәремдә ошбу сүзем көткәнем?
Элеккеге бар кайгылар китте, күңелдән очтылар,
Беттеләр һәм сүнделәр һәм кайгылыктан төштеләр,
Анлар урынын чолгады ялкын, җәһәннәм утлары,
Кальбемә зур кайгының керде зәһәрле уклары.
Аптырап әйтә алмадым бер башка сүз, тик «Аһ» дидем.
Хәл җыеп һәм көчләнеп бер кат тагын да «Ваһ» дидем.
Әй татар! Мескин татар! Очты сәгадәт байрагың,
Чын мөкатдәс сандугачың, җуйдың инде сайравын.
Ул иде чын-чын кояш тергезмәгә җанландырып,
Синдәге ярты үлекләрне тәмам канландырып,
Саргаеп, хәлсезләнеп калган үләннәр сахрасын,
Саф чәчәк аттырмага, пакь су иде аллаңдырып.
Нур иде ул, Тәңредән безгә бәһасез нур иде,
Җисмән ул гади иде, мәгънән вә рухан зур иде.
Язмый артык кулларым, күңелем сынык, кардәшләрем,
Чын күңелдә барчаңызны тәгъзия, кандашларым!

Бәдретдин Киләчи

---

* Идел. 1913. 12 апрель.

## Тукаев вафатилә мосыйбәт*

Исмидер җилләр бу көн, әкрен генә тынган җиһан;
Выж-выж итеп шаулаган җилләр исеп торган җиһан!
Ялтырап тормый кояш та, күк йөзендә нурланып,
Нурлары сүнгән, тора хәсрәтләнеп һәм моңланып.
Балкыган ай берлә йолдызлар да моңланган кебек;
Бу кара йир өстенә күз яшьләре тамган кебек.
Бездәге һәрбер матәмнәрне күреп эчтән генә,
Һәммә тау ташлар да сыкранган кебек эчтән генә,
Сайрамый кошлар да, былбыллар да шатлык җырларын,
Җырлыйлар анчык хәфа[1], хәсрәт вә госса[2] моңнарын.
Мин күрәм: саф һәм табигый яктылыкта тормый көн;
Төн катышкан төсле көнгә һәм күренгәндәй төтен!
Шылтырап аккан суларның да эче пошкан кебек,
Ниндидер бунларга да хәсрәт вә гамь төшкән кебек.
Күк йөзендәге болытлар бар да качканнар бу көн,
Гарше әгълядан[3] бу йиргә юлны ачканнар бу көн.
Әллә кайда шаулыйлар... моңлы авазлар иштелә...
Әйтә һатиф[4]: «Бер заман инсан үлә, инсан үлә!»
Мин бу көн күрдем табигатьнең тәмам үзгәргәнен,
Иске төсләр юк булып, бер үзгә төскә кергәнен.
Шул заман калдым тәхәйердә, дидем: «Ник соң болай?»
Бер аваз килде һатифтән: «Күчте дөньядан Тукай!»

Вакыйф Җәлал

* Аң. 1913. № 9. Б. 146.
[1] *Хәфа* – борчу, кайгы, хафа.
[2] *Госса* – кайгы, хәсрәт, көенеч.
[3] *Гарше әгъля* – күкнең иң югары катлавы.
[4] *Һатиф* – кычкыручы, тавыш бирүче.

## Тукайга дога*

Мәгъфирәтеңне Ходаем сал шагыйрь гөнаһына,
Рәхмәтеңне түк зөбәрҗәт күк бөтен моңнарына.
Аһ белән нурланды аның тамчы-тамчы моңнары,
Бар гөнаһысын сеңдер аның зәррә мыскал аһына.
Мәгъсуманә[1] бар мәләкләр Коръән укый каберенә,
Хак Тәгалә, рәхмәтеңне сал зиярәтгяһенә[2].
Ля мәкян[3] Тәңрем, бу көн мин йөз юнәлдердем сиңа,
Җәннәтеңне бирсәнә моң гаскәренең шаһына.
Рихләт итте[4] мәңгелеккә бу мөсафирханәдән,
Куш аны ахирәттә җәннәтнең матур әрбабына[5].
Милли былбыл сайрасын анда шатлыклар белән,
Монда хәсрәт түкте ул хикмәте әдәп бостанына.

В. Җәлал

* Кояш. 1914. 2 апрель.
[1] *Мәгъсуманә* – гөнаһсызларча.
[2] *Зиярәтгяһ* – зиярәт кыла торган урын.
[3] *Ля мәкян* – урыны билгеле булмаган (Алла яки шундый исеме бар, гәүдәсе юк нәрсә.)
[4] *Рихләт итте* – күчте.
[5] *Әрбаб* – әһелләр.

## Нинди көн бу?*

Нинди көн бу? Ник караңгы, ник кояш чыкмый тора?
Нигә яктыртмый татарны? Башка якта яктыра.
Ник бу көн барча татар халкы Коръән укый, барысы көйгән,
Бар сабыйлар ник бу көн туктап дөрестән егълыйлар,
Барча кызлар кайгылы йөз берлә нәрсә тыңлыйлар?
Әллә бу көн изге Әхмәднең җәфа күргән көне?
Яисә аның әсхабилә Мәккәдән качкан төне?
Кычкыра кемдер һатифәдән[1]: «Юк ятим үлгән бу көн,
Мәңгелеккә, ямьле нурга, гаршигә күчкән бу көн.
Сүнде лампа, ул да йоклый, нәгышенә[2] типмәлгән,
Йоклады бер ел, тагын йоклар, шулай кушкан хәким.
Егълыйлар барча сабыйлар, ул ятим үлгән өчен.
Тыңлый кызлар, егълыйлар һәм барысы да шуның өчен.
Алдыйсың син, үлмәгән ул, ул хәзер безнең белә,
Тик тәне шул җир эчендә, әмма рух уйный, көлә.
Юк икәнсең, тик җаным рәсемеңдә ул пакь күзләрең.
Берлә йөзеңә кычкырамын, син ишет үз сүзләрең:
«Бул тыныч кабереңдә, җаным, йокла рәхәт шатланып,
Яхшы исемең мәңге калды күңелемездә ятланып».

Г. Еникиев

---

* Кояш. 1914. 2 апрель.
[1] *Һатифә* – яшерен тавыш.
[2] *Нәгыш* – эчендә үлек ята торган табут.

**Китте шагыйрь!***

Хатыннар хамисе мәрхүм шагыйрь
Габдулла Тукаевка ядкәрән язылды

Китте инде дөньядан бу милләтнең чын шагыйре,
Йом мәхшәр файдасына шигъре улсын шаһиде,
Тезде шигърен милләтенә төрле якны уйлатып,
Язды ишгар[1], кылды ашгар[2] моң күңелне егълатып.
Армый-талмый итте хезмәт милләтнең рухына ул,
Барсын алга милләтем дип, төрле яктан ачты юл.
И, шагыйрь, ямьле шагыйрь, милли шагыйрь –
син чын шагыйрь,
Күземездән түктереп яшь, хәсрәткә салган шагыйрь,
Иттерә яд сине безгә шул гүзәл шигырьләрең,
Берсе артыннан бересе тагы җан азыкларың.
Моңлы шигырьләреңезне без укый идек яратып,
Тагы күңел йимешеңезне чын күңелдән җан атып,
«Тукаев вафат!» дигән ачы хәбәрне ишетеп,
Егъладык: «Аһ, алтын таҗымыз башымыздан төште!» – дип.
Безне үксез калдырып, син киттең инде айрылып,
Калдык инде кош шикелле канатларымыз кайрылып.
Ник болай тиз туйдың син арамызда торудан,
Сала идең чын фикерне кальбемезгә тугрыдан.
Стенадагы сәгать кич сигезне суккан вакыт,
«Аһ» димез, «Сөекле шагыйрь, син вафат булган вакыт».
Чын күңелдән кайгырамыз, кайгыручылар белән,
«Аһ» димез, «Китте яшьләй, милләтен никтер ташлап!»
Алмасы бик татлы булган бер алмагач идең син,
Калды милләт бик ялангач, алмагачы булмагач.

---

* Аң. 1914. № 7. Б. 133.
[1] *Ишгар* – белдерү, язу белән хәбәр итү.
[2] *Ашгар* – шигырьләр, бәетләр, җырлар.

Милләтнең рухын күтәргән хуш чәчәкле гөл идең,
Милләтемезнең ландышы син, йә миләүшәсе идең.
Бакчамызда сайрый торган бик матур былбыл идең,
Барча гөлләр арасында иң ләтыйф[1] бер гөл идең.
Барган идем урманына, килде чыкты Шүрәле:
«Мине сезгә белдерүче китте шагыйрь», – дип сөйли.
Ул нарат, чыршы агачлар һәрберсе кайгылы:
«Китте чын шагыйремез», – дип, хәл теле илә сөйли.
Төшкән идем су буена, Су анасы утыра:
«Китте милли теле үткен шагыйрең!», – дип ул тора.
Су эчендәге балыклар барчасы бик моң йөзә,
Гүя әйтерсең алар да ошбу кайгыны сизә!
Су буенда сайрый торган төрле-төрле кошлары,
Барсы да кайгыралар, ул Ходай былбыллары.
Тагы Алтын әтәче дә кычкыра канат кагып:
«Ул кадерле шагыйрең китте хәзер, дөньяда юк!»
Милләтнең каһарманы, чын шагыйремез калмадың,
Бары калды безләргә ядкәр әсәрләрең.
Һич тә чыкмас исемездән, Тукаев исмең синең,
Керсә дә шул кара йиргә вакытсыз җисмең синең!

Рокыя Ибраһимия

---

[1] *Ләтыйф* – гүзәл, нәфис.

**Хатирә**
**(Габдулла Тукаевка багышлыйм)***

Таң алдында матур Чулпан матурлап яңа калыкканда,
Караңгы кичле йир, илгә бәхетлек таңы атканда,
Халык – йир халкы тынлыкта вакыт, тик изге җаннарны
Ходаның рәхмәте – былбыллар сайрап уятканда,
Йир өстеннән, ил өстеннән матур җыр, ямьле көй көйләп
Җырында йирнең, илнең шаннарын, зур ханнарын сөйләп,
Матурлык, сафлык, аклык, ямьле, пакьлек «Алла»сын мактап,
Фырылдап очты бер «рух», калды артында матур ак тап...

* * *

Ишеткән изге җаннар, тынмый әле дә, әле дә тынмыйлар,
Һаман да шул сөекле «Рух» җырын тын алмый тыңлыйлар.
Йир өстендә, ил өстендә гомергә ул тавыш чыңлар,
Күңелләр тибрәнер мәңгегә, мәңге туймый җан тыңлар...

М. Әхмәтшаһ угылы

---

* Сүз. 1916. 22 апрель.

*Үзем үлсәм дә, гаҗиз исемем үлмәсен,*
*югалмасын;*
*Минем тырышлыгым һәм эшләрем*
*бушка китмәсен*

## КИТАБИ БАСМАЛАР

Татар халкының бөек улы шагыйрь Габдулла Тукай бай иҗади мирас калдырды һәм ул гомум халык тарафыннан хөрмәт белән кабул ителеп, бүгенге көнгә кадәр аның әсәрләренә ихтыяҗ кимемәде. Алар хәзер дә актуаль, бу заман вакыйгаларына аваздаш яңгырыйлар, бүген дә күпсанлы иҗат кешеләре өчен төрле жанрларда яңа әсәрләр тудырганда кыйммәтле чыганак булып хезмәт итәләр.

Октябрь инкыйлабына кадәр, ягъни 1907 елдан 1917 елга чаклы Г.Тукай әсәрләре, башлыча, вак җыентыклар рәвешендә, татар телендә 55 мәртәбә басылган. Шулардан Тукай үзе исән чагында 20 исемдә 32 китап дөнья күрә. Иң әүвәлге китап 1907 елның 15 ноябрендә, бертуган Шәрәфләрнең китап нәшриятында, «Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр буларак, «Г.Тукаев шигырьләре» исеме астында нәшер ителә (1 нче кыйсем, 48 бит). Шул ук елны бу сериядән Тукайның 4 нче дәфтәре – «Габдулла Тукаев шигырьләре» исеме белән (2 нче кыйсем, 56 бит) басылып чыга. 1909 елда шушы ук китаплар «Үрнәк» матбагасында яңадан бастырыла. Казан шәһәрендәге «Мәгариф», «Сабах», «Үрнәк», «Өмет», «Милләт» нәшриятларында шагыйрьнең һәр елны диярлек китаплары нәшер ителә. Әйтик, «Җуаныч» (1908), «Алтын әтәч» (1908), «Балалар күңеле» (1909, 1911), «Күңелле сәхифәләр» (1910), «Халык әдәбияты» (1910), «Күңел җимешләре» (1911), «Мияубикә» (1911), «Халык моңнары» (1912) кебек китапларны «Сабах» көтепханәсе бастырса, «Габдулла Тукаев диваны» (1909), «Энҗе бөртекләре» (1909), «Яңа кыйраәт» (1909, 1910), «Әдәбият» (1909), «Исемдә калганнар» (1909) «Үрнәк» матбагасында дөньяга чыга. «Әдәбият» (1910), «Җан азыклары» (1912), «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» (1914) китапларын «Мәгариф» көтепханәсе, «Яшен ташлары» (1911, 1912), «Балалар күңеле» (1912) исемле китапларны «Өмет» матбагасы нәшер итә. «Яшен ташлары» (1911) исемле җыентыкның кереш сүзендә Тукай бу китапны «Башыңдагы чабата», «Матбугат клоуны» дип атарга теләвен, 1908–1909 елларда «Яшен»дә бастырган «чүп-чарын» журналга хөрмәт йөзеннән «Яшен ташлары» дип исемләвен әйтә. Шагыйрь-

нең 1908 елда Пушкиннан иҗади тәрҗемә иткән «Алтын әтәч», 16 битлек «Күңелле сәхифәләр» (1910) басмалары балалар өчен төсле рәсемнәр белән бизәлгән китапларның матур үрнәге булып тора. Аерым басмаларда китапның тышлыгында бастырылуы турында бертөрле дата күрсәтелсә, эчендә икенче төрле дата язылган була. Мәсәлән, «Габдулла Тукаев шигырьләре» (4 нче дәфтәр) титулда – 1908, эчтә – 1907 ел, «Алтын әтәч» тышлыкта 1909, эчтә – 1908, «Балалар күңеле» тышлыкта – 1910, чынлыкта 1909 елда басылган. Китапларга кереш сүз бастыручы ширкәт яисә Тукай тарафыннан язылган. Мәсәлән, «Балалар күңеле» беренче җөзьә (1910) китабында кереш урынына язылган «Бер-ике сүз»не «Сабах» ширкәте идарәсе язган. «Г. Тукаев шигырьләре»нең 3 нче басмасында (1913) «Икенче табгыга даир» исемле сүз башын 1909 елның 11 сентябрендә наширләр төзегән булган. «Яңа кыйраәт» (1910) китабында «Мөгаллим әфәнделәр дикъкатенә» дигән кереш наширләр тарафыннан булса, шул китапның 1913 елгы басмасында кереш сүзне автор үзе язган. Басылып чыккан китапларның ахырында, арткы тышлыкның эчке ягында Тукайның һәм башка авторларның басылган һәм басылачак китапларының исемлеге бирелгән, кайсыларының сатылып беткәнлеге дә күрсәтелгән. Бу чордагы басмалар китап бастыру культурасы ягыннан бик үк камиллеккә ирешмәгән булалар. Бер китапта эчтәлек күрсәтелә, икенчесендә бөтенләй юк. Яисә, эчтәлек бар, ләкин китаптагы шигырьләрнең урнаштырылу тәртибе эчтәлектәге күрсәтелешкә туры килми. Кайбер очракларда китапның кайчан бастырылуы да күрсәтелми. Әдәбият галимнәре андый очракларда китапның нәшере вакытын ТР МАындагы (420 ф., 1 тасв.) «Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының дөньяга чыккан барлык басма әсәрләрне теркәү дәфтәре» буенча билгелиләр. Кабат бастырган китапларда бераз кыскартулар, шигырьләрнең урыннарын алмаштыру, яки сүзләрдә «җ» авазын «йы»га алыштыру кебек төзәтүләр күзәтелә. Мәс., «Габдулла Тукаев диваны» (8 нче дәфтәр) (1908) исемле китапны 1913 елда «Мәгариф» нәшрияты кабаттан бастырганда «Егет илә кыз», «Вак-төяк», «Яшен» журналы хакында», «Мәддахе Истамбул шагыйрьләре», «Булмаса», «…гә» кебек әсәрләрне төшереп калдырган. «Әдәбият» (10 нчы дәфтәр) китабының 1913 елгы басмасы 1909 елгы басмасыннан кайбер шигырьләрнең урыннары алмашыну һәм «Вөҗдан зарары» исемле шигырьнең исеме «Вөҗдан хөррияте»нә үзгәртелү белән аерылып тора. «Җан

азыклары» җыентыгының 1914 елгы басмасында 1912 елгысыннан аерма фәкать «җ» авазын сүзләрдә «йы»лаштырудан гыйбарәт («Егетләр» – 9 б., «Көзге йилләр» – 17 б., «Йил тавышы» – 40 б.). «Җан азыклары» (1912) китабының шагыйрь үзе исән чагында чыккан соңгы шигырьләр җыентыгы икәнлеген дә искәртеп китик. «Исемдә калганнар» (1909), «Әдәбият» 10 нчы дәфтәр (1909), «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» (1914, 1918) китаплары Тукайның рәсеме һәм Кырлай, Кушлавыч, Өчиле авылларының күренешләре, замандашларының фоторәсемнәре белән баетылган.

Г. Тукайның 1909–1911 елларда чыккан «Яңа кыйраәт», «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» кебек дәреслек-хрестоматияләре татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен уку әсбабы буларак та кулланыла. «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»ндә (1911) шагыйрь үз әсәрләрен генә түгел, бәлки башка язучыларның үзе уңышлы дип тапкан әсәрләрен дә туплап укучыга тәкъдим итә. Шулай итеп, шагыйрь мәктәптә татар әдәбиятын системалы рәвештә өйрәнүгә нигез сала. Тукайның вафатыннан соң да бу китапларның берничә тапкыр басылуы аларга булган ихтыяҗның кимемәве турында сөйли.

Совет хакимияте елларында да Тукай әсәрләре басылуын дәвам итә: 1917 елдан 1956 елга кадәр шагыйрьнең татар телендә 79, 1956 елдан 1970 елга кадәр 9, 1970 елдан 1980 елга кадәр 5 басмасы билгеле.

Җ. Вәлидинең кереш мәкаләсе белән Казанның «Мәгариф» нәшриятында 463 битле булып нәшер ителгән «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» шагыйрьнең вафатыннан соң 1914 елда басылып чыга. Анда Тукайның үз заманында китап-рисаләләрдә, газета һәм журналларда дөнья күргән әсәрләре тупланган. Үз катнашында төзеп калдырылган бу җыентыктагы әсәрләр җитди шигырьләргә, көлке вә һөҗү, балалар кыйсемнәренә, нәсерләргә бүлеп бирелсә дә, хронология сакланмаган. 1926 елда Ф. Бурнаш «Габдулла Тукай шигырьләре» дигән тагын бер җыентык төзеп, Казанның «Гажур» нәшриятында гарәп язуында бастыра. Ул шагыйрь кульязмаларыннан моңа кадәр мәгълүм булмаган 4, башка басма чыганаклардан 9 шигырь табып, мәҗмуганы баета. Татар язуы латин графикасына алышынгач, Тукайның дүрттомлык басмасын әзерләү язучы, «Яңалиф» җәмгыяте рәисе Фатыйх Сәйфи-Казанлыга тапшырыла. Басма «Г. Тукай әсәрләре» дип исемләнә. Җыентыкны төзүче аны «Академик нәшер» дип атый һәм шагыйрьнең матбугат битләрендә чыккан бөтен әсәрләрен эченә алуын, шигырьләрнең

тарихы күрсәтелүен, мәкаләләре һәм хатлары да кертелүен, «әсәрләре хакында киң күләмдә тәнкыйть анализы» бирелүен әйтә. Басма 4 китаптан торачак булса да, чынлыкта 3 томы гына дөнья күрә: 1 нче томына (1929) шагыйрьнең 1905–1908 елларда, 2 нче томына (1929) 1909–1913 елларда язылган, 3 нче томына (1931) алдагы 2 томына керми калган шигырьләре, «Исемдә калганнар»ы һәм 91 мәкаләсе кертелә. Төзүче, 1914 елда дөнья күргән «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре»ндәге текстларга өстәп, тагын 76 шигырен китерә. Икенче аерма – ул Тукай әсәрләренә аңлатма һәм искәрмәләр яза һәм шигырьләрне, басылу вакытын истә тотып, хронологик тәртиптә урнаштыра. Тик аерым шәхесләр турында язганда төзүченең карашларында вульгар социологизм, сыйнфыйлык күзлегеннән чыгып бәяләү сизелә. 1939 елда, шагыйрь вафатына 25 ел тулу көнен билгеләп үтү максатында, Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институтына аның ике томлы Академик басмасын әзерләү бурычы куела. Бу эшне Якуб Агишев белән Хәй Хисмәтуллин башкарып чыгалар. 1 нче томда (1943) Тукайның барлык шигъри әсәрләре хронологик тәртиптә урнаштырыла, 2 нче томда (1948) проза әсәрләре 4 бүлеккә җыйнап бирелә: 1) автобиографик очерклар, истәлекләр һәм хатлар (барлыгы 13 хат); 2) иҗтимагый-политик һәм әдәби-критик мәкаләләр; 3) хикәяләр, фельетоннар һәм памфлетлар; 4) мәсәлләр һәм дидактик материаллар. Әдәбият галиме Нил Юзиев «Икетомлыкның үзенчәлекләре» (1998) исемле мәкаләсендә әлеге басманың төзелү, редакцияләнү тарихын ачыклый һәм анда Тукай әсәрләренең текстологиясе өстендә фәнни эшләрнең җитәрлек дәрәҗәдә башкарылмавын билгеләп үтә. Шуңа күрә дә ул гадәти фәнни басма дәрәҗәсендә кала. Шагыйрьнең тууына 70 ел тулу көннәре якынайганда, ТӘһТИдә Х. Хисмәтуллин һәм Я. Агишев әзерләгән Тукайның дүрттомлык «Әсәрләр»е дөнья күрә (1955–1956). Бу басмада икетомлыкта булган «Алла гыйшкына», «Кадер кич», «Иртәнге азан», «Мигъраҗ» кебек дини, милли мотивлар чагылган 21 шигырь төшереп калдырыла, 50 ләп «яңа» текст урнаштырыла. Тагын бер әһәмиятле як – 4 нче томның кушымтасында «Г. Тукай әсәрләренең һәм аның турындагы әдәбиятның кыскача библиографиясе (1907–1956)» бирелә. 1975–76 елларда Тукайның 90 еллыгына икенче дүрттомлык басыла. 1985–1986 елларда, шагыйрьнең 100 еллыгына багышлап биштомлык нәшер ителә. Ике басма да Академик басма түгел, бәлки «Әсәрләр» исеме белән дөнья күрә. Икесенең дә төзүчесе,

текстларны, аңлатма һәм искәрмәләрне әзерләүчесе – Рашат Гайнанов (материалларны текстологик яктан әзерләүдә сеңлесе Лена Гайнанова да катнаша). Ул, басмадан басмага туплана килгән тәҗрибәне үзләштереп, Тукай текстологиясен тагын да югарырак баскычка күтәрә. Шунысы ачык, биштомлык, шул заман идеологиясе басымы нәтиҗәсендә, кайбер әсәрләрнең басмада урын алмавына, текстларның кыскартылып кертелүенә, аңлатмалар һәм искәрмәләрнең сыйнфый карашлар «яктылыгында» язылуларына карамастан, һаман да актив кулланылышта.

XX гасыр ахырында илдә башланган радикаль үзгәрешләр татар әдәбиятының үткәнен бернинди чикләүләрсез өйрәнергә мөмкинлек ачты. Көн тәртибенә Тукай әсәрләренең Академик басмасын төзү бурычы куелды. Бу эшкә Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ текстологлары алынып, алтытомлык булып чыгачак Академик басманың 2011 елда шигъри әсәрләрдән торган 1 нче һәм 2 нче томнарын бастырып чыгардылар. Алар биштомлыктан нәрсә белән аерыла соң? Элек Тукайныкы саналган, чынлыкта башка авторларныкы икәнлеге дәлилләнгән «Сөй гомерне, сөй халыкны…» дип башланган, «Экспромт», «Аһ идәрсәм…» кебек әсәрләр томга кертелмәгәннәр. Биштомлыкның 1–2 томнарындагы кушымталарда бирелгән 6 өйрәнчек шигырь («Приемныйның ишекләре…», «Шура» шигырьләреннән», «Әхмәтсафа әфәнде…», «Тугъды, көн тугар кеби…», «Рөшеде вар…», «Мәгатыйль кыйлды милләтне…»), Тукайныкы булуы тәмам ачыкланып һәм хронологиягә буйсындырылып, бу юлы томның башына урнаштырылган. Шулай ук элекке басмалардан читтә калган 6 шигырь («Әнвәр бәк», «Кем ул?», «Фәләннең фәләне», «Булмый», «Тәмсил», «Ана илә Бала») өстәлгән. Төзүчеләр барлык текстларны чыганаклар буенча тикшереп, аларга күпсанлы төзәтмәләр керттеләр, искәрмә һәм аңлатмаларны тулыландырып, совет чорында тагылган ярлыклардан, бәяләрдән арындырдылар. Болардан тыш, иске госманлы телендә язылган шигырьләр (1906) хәзерге татар теленә яңабаштан тәрҗемә ителгән. Тукай исән чагында чыккан китапларга үз чорының рецензияләре, наширләрнең бәяләмәләре, реклама текстлары файдаланылган. Шагыйрьне теге яки бу әсәрен язуга этәргән рус телендәге шигырь текстлары, тәрҗемәчеләргә, әдәбиятчыларга чагыштырып карау өчен, искәрмәләр өлешендә китерелгән. Томнарга Тукай исән чагында чыккан китаплардагы иллюстрацияләр, «Яшен», «Ялт-йолт» журналларындагы карикатуралар (янында

Тукай шигырьләре булганнары) урнаштырылган. 2015 елда проза һәм публицистик әсәрләрдән гыйбарәт 3 нче һәм 4 нче томнарны бастырып чыгардылар.

***Әдәбият:*** *Беренче дүрттомлык.1956. Т. IV. Б. 257–276; Габдулла Тукай: Библиографик күрсәткеч (1956–1970). Казан, 1974. 116 б.; Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. Казан, 1989. С. 92, 95, 105, 107, 111, 125; Гобәйдуллин Л.И. Габдулла Тукай мирасы (шагыйрьнең ТР Милли китапханәсендә саклана торган сирәк басмалары турында) // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар: Казан, 2001. Б. 181–183; шунда ук: Вәлиев М. Тукай һәм «Мәгариф» нәшрияты. Б.153–154; Рәмиев З. Шагыйрьнең күптомлы басмалары // Әсәрләр. Алты томлы Академик басма. Т. I. Б. 25–30.*

*Зөфәр Рәмиев,*
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре,*
*Заһир Шәйхелисламов,*
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль*
*мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

## Г. ТУКАЙ ТЕЛЕНЕҢ ӨЙРӘНЕЛҮ ТОРЫШЫ

Халык шагыйре Габдулла Тукай – татар әдәби телен үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән күренекле шәхесләрнең берсе. Ул – сүзнең иң яшерен яңгырашын да тоеп алып, үз иҗатында бар нечкәлекләре, мәгънә төсмерләре белән оста итеп файдалана белгән талант иясе. Шуңа күрә дә Г. Тукай әсәрләре шагыйрь үзе исән вакытта ук татар әдипләре һәм галимнәренең игътибарын җәлеп итә. Бу җәһәттән, Ф. Әмирхан, Гали Рәхим, Җамал Вәлиди, Г. Сәгъди хезмәтләрен мисалга китерергә мөмкин. XX гасыр урталарында һәм соңрак Л. Җәләй, Ш. Рамазанов, Ә. Исхак, С. Поварисов, Ю. Вәлитова һ.б. мәкаләләре дөнья күрә. Әлеге хезмәтләрдә бөек шагыйрьнең иҗаты, грамматик, фонетик, лексик һәм стилистик үзенчәлекләре яктыртыла, Г. Тукай иҗатының халыктан аерылгысыз булуы дәлилләнә. Шуңадырмы, аларда Тукай һәм әдәби тел төшенчәләре һәрчак янәшә карала. Г. Тукай иҗатын өйрәнгән телче галимнәр шагыйрьнең халыкның җанлы сөйләм теленә нигезләнеп иҗат итүен, татар теленең сүзлек байлыгын бик оста файдалана белүен игътибарга алалар.

Фәнни хезмәтләрдән күренгәнчә, татар тел белемендә Г. Тукай иҗатының лексикасын тикшерү берничә юнәлештә алып барыла:

1. Г. Тукай әсәрләрендә гади сөйләм лексикасы, көнкүреш сүзләре, диалекталь һәм архаик сүзләрнең кулланылышын өйрәнү.

Шагыйрь татар теленең сүзлек байлыгы белән бик оста эш итә, лексик берәмлекләрнең семантик төсмерләрен иркен файдалана һәм иң мөһиме халыкның җанлы сөйләм теле үзенчәлекләрен әдәби телгә кертеп җибәрү юнәлешендә зур эш башкара. Г. Тукайның көнкүреш һәм гади сөйләм лексикасын иҗатына кертүе байтак галимнәрнең хезмәтләрендә телгә алынса да, бу мәсьәләгә тукталып, киңрәк яктырткан галимнәрдән Ш. Рамазанов, Г. Әмиров, Ә. Исхак, В. Хаковны һ.б. атарга мөмкин. Г. Тукайның телен, лексикасын тикшерү юнәлешендә Ш. Рамазанов үзенең «Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле» дигән мәкаләсендә Г. Тукай хакында «халык телен, җанлы сөйләү телен төп чыганак итеп файдаланды» дип, шагыйрьнең гади сөйләм һәм көнкүреш лексикасына таянып иҗат итүенә басым ясый, «Ишан», «Эштән чыгарылган татар кызына», «Өч хакыйкать» һ.б. шигырьләреннән мисаллар китерә. Галим шагыйрьнең *каргау, капшау, маташу, кибәк баш, чыпчык баш* һ.б. кебек меңнәрчә гади көнкүреш сүзләрен әдәби телгә кертүгә Тукайның роле зур булуын ассызыклый: «Гади сөйләү һәм көнкүреш сүзләре әдәби телгә килү өчен Тукай киң юл ачты, һәм алар «китап теле» элементлары белән кушылып, әдәби тел тукымасы булып әверелделәр» [Рамазанов, б. 142 – 143].

Бу җәһәттән, Ә. Исхак шагыйрьнең соңгы чор иҗатындагы тел үзенчәлекләрен башка әдипләр белән чагыштырып, болай ди: «Ләкин алар халык теле байлыгыннан Тукай кадәр үк файдалана алмадылар, аларның теле китап теле булудан ары китмәде» [Исхаков, б. 22]. Шул рәвешчә, Ә. Исхак та, Ш. Рамазанов фикерен куәтләп: «Тукай татар поэзиясен халыкның үз сөйләү теленнән алынган образлы сүзләр белән тулыландырды. Аның бу тырышлыгы ...җанлы әдәби тел тудыруга хезмәт итте» [Исхаков, б. 24]. Автор Г. Тукай иҗатында, халык сөйләм телендәге берәмлекләре белән беррәттән, *дөрлү* (төрле), *уйку* (йокы) һ.б. борынгы төрки тел сүзләренең киң кулланылуын да искәртә, соңрак чорда язылган әсәрләрендә «шагыйрь телне бик нык сафландыруга ирешә» дигән фикерен уздыра [Исхаков, б. 16].

Г. Тукай иҗатында кулланылган гомумхалык сүзләре Г.С. Әмировнең докторлык диссертациясендә шактый тулы яктыртыла, хезмәтнең тулы бер бүлеге шагыйрь иҗатындагы көнкүреш лексикасын төрле яклап анализлауга багышланган. Автор Г. Тукай

иҗатының төп нигезен аның туган ягында киң таралган көнкүреш лексикасы алып торуы турында, Тукайның туган теле, сөйләм теле хакындагы фикерләренә таянып, тәфсилләп яза. Галим шагыйрьнең гади сөйләм сүзләрен киң кулланылышка кертүен, иҗатын көнкүреш лексикасы белән баетуын аңлатып, Тукай иҗатында кулланылган төрки-татар сүзләрен сүз төркемнәре ягыннан анализлый. Шулай ук шагыйрьнең туган телнең барлык мөмкинлекләрен файдаланып, яңа сүзләр ясау осталыгын да игътибарга ала, шигърияттен халык арасында киң таралган «Бәдавәм», «Нәүрүз бәете», «Сак-сок бәете» кебек халык авыз иҗаты әсәрләренең лексикасы белән баетуын искәртә [Әмиров, 1968, б. 25–28].

Соңрак шигъри сөйләмне җанландыру, аның динамизмын арттыру һәм стилистик максатлардан Г. Тукайның гади сөйләм сүзләрен иркен куллануы Ф.С. Сафиуллина хезмәтләрендә игътибарга алына: «Халыкның җанлы сөйләмен Тукай бөтен байлыгы, көче, рухы белән публицистикасына, аеруча сатира әсәрләренә алып керә» [Сафиуллина, б. 266]. Г. Тукайның татар сөйләменең эчке мөмкинлекләрен оста итеп куллана белүе, татар милли әдәби теле формалашуда Г. Тукайның роле зур булу күренекле тел галиме И.Б. Бәширова хезмәтләрендә искәртелә: «Тукайның даһилыгы, аның илаһи шигърияте нәкъ менә халкыбызның үз – милли сүзләре белән тәсвир итү юнәлешендә ачыла, әлеге нигездә татар әдәби теленең иң гүзәл – нәфис стиле дә формалаша [Бәширова, 2011, б. 209].

Сүзләрнең кулланылыш катламнарыннан Ш. Рамазанов, В. Хаков, Ф. Сафиуллина кебек галимнәр үзләренең хезмәтләрендә Г. Тукай шигъриятендә, гади сөйләм сүзләренннән тыш, архаик сүз һәм формалар, диалекталь берәмлекләрнең дә кулланылуына игътибар итәләр. Алар фикеренчә, әлеге берәмлекләр шагыйрь тарафыннан, нигездә, стилистик катлам рәвешендә, ягъни сурәтләү чарасы буларак, сатирик һәм ироник максатларда кулланыла, шул сәбәпле алар чагыштырмача аз очрый [Рамазанов, б. 155–160; Хаков, 1993, б. 281–282]. Тукай иҗатындагы диалекталь үзенчәлекләрне тикшергән Д.Б. Рамазанова *бәхер, эшкяра* һ.б. берәмлекләрнең бүгенге көндә дә диалектларда очравын искәртә. Галимә шагыйрь иҗатында Кол Галиләр чорыннан килә торган кайбер морфологик һәм фонетик чаралар белән бергә лексик берәмлекләрнең дә булуына игътибар итә [Рамазанова, б. 206].

Шулай итеп, галимнәр үзләренең хезмәтләрендә Г. Тукай иҗатындагы гади сөйләм лексикасын һәм бик аз дәрҗәдә генә

чагылыш тапкан диалекталь лексиканы өйрәнү барышында шагыйрьнең поэтик стильгә көнкүреш лексикасын кертүен, шигърият телен халыкка якынайтуын югары бәялиләр: «Тукай кебек татар телендә җиңел һәм көчәнмичә язган, шуның белән бергә гаять аһәңле һәм матур итеп язган башка бер шагыйрьне күрсәтү кыен... Тукай иҗатында татар теленең байлыгы да, сәләте дә, матурлыгы да гәүдәләнде» [Рамазанов, б. 140].

2. Г. Тукай шигъриятенең лексик байлыгын килеп чыгышы ягыннан тикшерү.

Ш. Рамазанов Г. Тукай лексикасын тикшерү барышында, шагыйрь кулланган лексик берәмлекләрнең килеп чыгышы ягыннан төрләренә дә туктала. Галим фикеренчә, Тукай иҗатында төп лексика татар теленең үз сүзләре булса да, шагыйрь гарәп, фарсы, рус һәм Көнбатыш Европа сүзләрен дә иркен файдаланган. Г. Тукай иҗатында очрый торган гарәп-фарсы алынмаларының да байтагы – көнкүреш телендә очрый торган, ягъни халыклашкан сүзләр һәм аларның күп өлеше бүгенге көндә дә телебездә кулланылышта йөри. Тукай кулланган «китап гарәпчәләре» исә, галим искәрткәнчә, асылда иҗтимагый-икътисадый, сәяси, фәнни-техник һәм дини терминнардан гыйбарәт, яисә аларны шагыйрь ритм-рифма таләпләре һәм синонимик параллельләр ясау, яисә сарказм-ирония максатыннан файдаланган. Рус һәм Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләргә килгәндә, Г. Тукай аларны, башлыча, татар телендә төгәл эквиваленты булмаган яисә татарчага тәрҗемәсе әлеге мәгънәне биреп бетерә алмаган очракларда кулланган. Шулай да арада, галим фикеренчә, Г. Тукайның рус сүзләрен көлке – ирония тудыру максатыннан файдаланган очраклар да бар. «Тотса мәскәүләр якаң» шигыре шуның бер мисалы булып тора [Рамазанов, б. 150–155].

Г. Тукай иҗатының башлангыч чорында гарәп-фарсы алынмаларының күп кулланылуы Ә. Исхак хезмәтендә дә игътибарга алына. Автор Г. Тукай иҗатында *чук, дулашу* һ.б. кебек госманлы төрекләреннән кергән сүзләрнең һәм рус теленнән алынган лексемаларның да булуын ассызыклый. Ә. Исхак бу күренешләрне, башка галимнәр кебек үк, шул чорның иҗтимагый-сәяси вәзгыятенә бәйләп аңлата [Исхак, б. 15–17].

Г. Тукай иҗатында кулланылган алынма сүзләр шактый тулы итеп Г.С. Әмировнең докторлык диссертациясендә анализлана. Галим хезмәтендә шагыйрь иҗатында кулланылган гарәп, фарсы, рус, рус теле аша кергән Европа алынмалары, интернациона-

лизмнар, төрек-угыз теле элементларын анализлый, калькаларга да туктала. Гарәп-фарсы алынмалары мәгънәләренә нигезләнеп егерме төркемгә бүлеп бирелә, шулай ук биредә гарәп һәм фарсы телләреннән кергән ономастик берәмлекләр дә анализлана. Галим гарәп-фарсы алынмаларының ике телдә эшләнгән сүзлеген дә кушымта итеп тәкъдим итә [Әмиров, 1968, 32–35]. Рус алынмаларына килгәндә, автор Тукай тарафыннан барлыгы 1600 ләп лексик берәмлек кулланылган дигән фикердә тора. Шунысы кызыклы, шагыйрь рус алынмаларын, башлыча, публицистик һәм сатирик әсәрләрендә файдаланган һәм байтагы бары тик берәр тапкыр гына кулланылган. Рус теленнән кергән ономастик берәмлекләр дә рус алынмалары белән бер бүлектә тикшерелә. Галим русизмнар арасында иҗтимагый-сәяси һәм публицистик лексиканың күп булуын игътибарга ала. Г.С. Әмиров Тукай иҗатында кулланылган рус алынмаларын динамикада тикшереп, шуны ачыклый: әлеге русизмнарның байтагы татар әдәби телендә урнашып кала. Интернационализмнар исә галим тарафыннан ике төркемгә бүлеп анализлана: гарәп-фарсы һәм рус, рус теле аша Европа телләреннән кергән алынмалар. Калькаларның, башлыча, тәрҗемә әсәрләредә кулланылуы искәртелә [Әмиров, 1968, б. 35–42]. Гомумән, галимнәр Г. Тукайны рус сүзләрен калька юлы белән тәрҗемә итүнең гүзәл үрнәкләрен биргән беренче татар әдипләреннән саныйлар [Ахунҗанов, 1965, б. 164 – 167].

Халык арасында киң таралган рус гыйбарәләренең Тукай иҗатында киң кулланылуы тел галимнәре тарафыннан соңрак та телгә алына. Мәсәлән, Ф.С. Сафиуллина халык арасында киң таралган рус гыйбарәләрен куллануын Тукайның төп үзенчәлеге итеп күрсәтеп, болай ди: «Шигырь тукымасына Тукай рус сүзтезмәләрен дә кертеп җибәрә. Җанлы сөйләмдә генә мөмкин булган мондый тезмәләр тәнкыйть уты астына алган шәхесләргә карата кулланылалар» [Сафиуллина, б. 260]. Тел белемендә шагыйрьнең иҗатында кулланылган алынма сүзләрнең сан ягыннан күләмен билгеләү дә күзәтелә. Дөрес, югарыда телгә алынганча, бу күренеш узган гасырда Г.С. Әмиров хезмәтендә чагылыш тапса, соңрак Р.Р. Хәмидуллин тарафыннан башкарыла. Ул шагыйрьнең «Голүмең бакчасында...» шигырендә кулланылган сүзләрнең гомуми санын ала, аларның ничәсе гарәп, рус, татар, төрек телләренә каравын ачыклый, ягъни сүзләр кулланылышына статистик анализ ясый [Хәмидуллин, б. 52]. Ә.Ш. Йосыпова исә алынма сүзләрне тикшергәндә,

шагыйрь иҗатында рус алынмаларыннан иҗтимагый-сәяси темага караган сүзләрнең күплеген игътибарга ала [Йосыпова, б. 312]. Иҗтимагый-сәяси лексиканың китап теле аша кергән рус алынмалары арасында күп булуы Л.Г. Хәбибов тарафыннан да искәртелә. Ул үзенең мәкаләсендә Тукай иҗатында кулланылган рус сүзләренә генә түгел, ә рус теле аша кергән Европа алынмаларының да күп булуына игътибар итә. Автор, Ш. Рамазанов һәм Г. Әмиров фикерләрен дәвам итеп һәм аларга таянып, Г. Тукай иҗатында рус һәм рус теле аша кергән Европа сүзләре 1600 дән артып китә дип күрсәтә, аларны ике төркемгә бүлеп бирә: а) язма китап теле аша кергән сүзләр; б) сөйләм теле аша кергән сүзләр. Л.Г. Хәбибов хезмәтеннән күренгәнчә, беренче төркемне тәшкил итүче алынмалар бик аз үзгәреш кичергәннәр яисә бөтенләй дә үзгәртелмичә кулланылалар һәм алар Тукай иҗатында шактый еш күзәтелә. Бу аңлашыла да, чөнки Г. Тукай рус телен яхшы белгән: «Г. Тукай русча сөйләшә, аңлый гына түгел, ә яза һәм рус язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итә торган булган» [Хәбибов, 230–232].

Югарыда искәртелгәнчә, Г. Тукай иҗатында галимнәр алынма сүзләрдән гарәп, фарсы, рус, Көнбатыш Европа һәм төрек телләренең алынмаларын күрсәтәләр. Шагыйрьнең аеруча башлангыч чор иҗаты гарәп-фарсы һәм төрек сүзләре белән чуарланган була. Галимнәр бу күренешне язма тардициягә бәйләп аңлаталар. Гомумән, Г. Тукайның язма традициягә нигезләнүе табигый күренеш һәм ул тел белгечләре тарафыннан да телгә алына. Мәсәлән, Ф.М. Хисамова Г. Тукайның башлангыч чор иҗатының теле турында болай ди: «Бу – безнең шул чордагы әдәби телебез, язмыш ирке белән төрле сурәтләргә, төсмерләргә керергә мәҗбүр булган, күп гасырлар гамәлдә йөргән иске язма телебез, иске татар теле» [Хисамова, б. 254–255]. И.Б. Бәширова үзенең хезмәтләрендә Г. Тукайның төрек сүзләре белән чуарланган «Тәрҗеман» гәзите телен инкарь итсә дә, иске татар теле – традицион төркидә язуын, алга таба әкеренләп халыкчан милли телгә күчүен шактый үтемле итеп дәлилли. Бу аңлашыла да, чөнки, « шигырьне һәммә кеше дә аңлап бетерә алмый торган гарәп-фарсы алынмалары, гомумтөрки сүз, сүзформалары күп кулланыла торган классик иске татар теле – традицион төркидә, аның да югары стилендә генә иҗат ителә ала торган бөек, илаһи шигърият дип инану дәвам итә [Бәширова, 2011, б. 209]. Г. Тукайның традицияләргә нигезләнеп иҗат итүе соңрак Б.К. Миннуллин мәкаләсендә дә искәртелә. Тукайның

башлангыч чор иҗатының теле шактый чуар булуын, гарәп, фарсы һәм төрек сүзләренең күп кулланылуын автор, бер яктан, шагыйрьнең беренче шигырьләре дөнья күргән «Фикер», «Әлгасрелҗәдид» басмаларына бәйләп аңлатса, икенчедән, шагыйрьнең күп гасырлар дәвамында формалашкан поэтик традицияләргә нигезләнеп язуын искәртә: «Также в рассматриваемый период в татарской литературе уже имелись устоявшиеся за столетия поэтические традиции, которые не могли не повлиять на языковой стиль произведений Тукая на начальном этапе его творчества» [Миннуллин, с. 235].

3. Г. Тукай әсәрләрендә сәнгатьчә сурәтләү чарасы буларак кулланылган лексик берәмлекләрнең өйрәнелеше.

Халык шагыйре Г. Тукайның кабатланмас сурәтләү чараларына, үзенчәлекле стильгә ия булуы узган гасыр башында ук галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди, Г. Камал кебек күренекле шәхесләр Тукайның тел мөмкинлекләреннән оста файдаланып, халыкка җиңел аңлаешлы телдә тирән эчтәлекле һәм халыкчан әсәрләр иҗат итүен югары бәялиләр, Г. Тукай әсәрләренең сурәтләү чараларына бай булуын, үткен тел белән язылуын искәртәләр. Шагыйрь иҗатының лексик байлыгын төрле яклап тикшерү алга таба да дәвам итә. Узган гасыр урталарында Г. Тукайның тел-стиль үзенчәлекләрен, лексик байлыгын тикшергән хезмәтләр дөнья күрә башлый. Алар арасында Ш.А. Рамазанов хезмәте аерым урын алып тора. Галим әлеге язмасында, шагыйрь иҗатында кулланылган гади сөйләм, көнкүреш лексикасы, алынма сүзләрне анализлау белән беррәттән, күчерелмә мәгънәдәге лексик байлыкның, мәкаль-әйтем һәм фразеологизмнарның кулланылыш үзенчәлекләренә дә туктала, Г. Тукайның гомумхалык сүзләрен бик оста файдаланып, күчерелмә мәгънәләр тудыруда, гади сүзләрнең яшерен мәгънә төсмерләрен ачып бирүдә осталыгы зур булуын мисаллар белән дәлилләп яза. Ш. Рамазанов әлеге хезмәтендә Тукайның халык авыз әдәбиятына якын булган «яңа поэтик тел, әдәби стиль тудыруын» раслый, шагыйрьнең «идиома һәм фразеологияләрдән гаять оста файдалануына» мисаллар китерә [Рамазанов, б. 144].

1960 елларда исә Ә. Исхак Г. Тукай лексикасын өйрәнү барышында шагыйрьнең иҗатында фразеологизмнар, мәкаль-әйтем, тәгъбирләрнең искиткеч күп очравын игътибарга ала, синонимнарның шагыйрь тарафыннан «көчәйткеч буларак» яратып

кулланылуын искәртә [Исхак, б. 105]. Автор фикеренчә, сурәтләү чарасы сыйфатында татар халык мәкальләрен куллану ягыннан Тукай күпләрдән аерылып тора. Мәкальне ул шигырьгә бөтен килеш алмый, бәлки «әйтергә теләгән фикеренә буйсындырып сүтә, үзгәртә, өсти һәм шигырьнең табигый бер күзәнәге итеп кертеп җибәрә» [Исхак, б. 98]. Г. Тукайның чагыштыру, гипербола, риторик фигуралар һ.б. шундый сурәтләү чараларын образлар тудыруда бик оста файдалануы хакында да Ә. Исхаков хезмәтендә берникадәр мәгълүмат бирелә.

Ә. Исхак хезмәтендә бик аз гына телгә алынган синонимия күренеше 1971 елда шактый тулы итеп С.Г. Әмиров хезмәтендә анализлана. Галим шагыйрь иҗатында 5000 чамасы сүзне эченә алган 1300 ләп синонимик оя булуын искәртә һәм рус галиме М.Ф. Палевская хезмәтенә таянып, аларны өч зур төркемгә бүлеп бирә:

а) семантик синонимнар – стилистик нейтраль сүзләр: *абзый – агай – ага – абый* һ.б.

б) стилистик синонимнар. Мәсәлән, *алпавыт – бояр – дворян – помещик* һ.б.

в) семантик-стилистик синонимнар: *акыру – кычкыру – бакыру* һ.б.

Галим семантик синонимнарны, сүз төркемнәрен нигез итеп алып, дүрткә (исем; сыйфат; фигыль; рәвеш һәм сыйфат) бүлеп тикшерә. Мисалларга нигезләнеп, автор югарыда телгә алынган өч төркем арасында стилистик синонимнарның күләм ягыннан зур урын алып торуын искәртә. Чөнки стилистик синонимнар, беренче чиратта, гарәп-фарсы һәм рус алынмалары исәбенә баеса, икенчедән, диалекталь һәм гади сөйләм сүзләре дә бу төр синонимнар рәтен баета [Амиров, 1971, б. 51–52]. Әмма, галим фикеренчә, Г. Тукай иҗатында кулланылган синонимнарның кайсы гына төре алынса да, аларның төп нигезе булып татар теленең көнкүреш, фольклор әсәрләрендәге лексик берәмлекләр белән баетылган үз сүзлек хәзинәсе тора. Г. Әмировның әлеге мәкаләсендә Г. Тукай иҗатында кулланылган синонимик ояларның шактый бай сүзлеге дә китерелә [Амиров, 1971, б. 55–61].

Синонимнардан соң С.Г. Әмиров омонимия, антонимия күренешләренә туктала, аларны сан ягыннан ачыклый, төркемнәргә бүлеп анализлый. Омонимнарга килгәндә, галим бу төр лексик берәмлекләрнең чагыштырмача аз булуын билгеләп уза: 200 ләп чамасы омонимик берәмлек булуы телгә алына, антонимнарның

исә шактый күп булуы ачыклана. Г. Әмиров бу күренешне шагыйрьнең җәмгыятьтәге тигезсезлек, хәерче һәм бай, надан һәм укымышлы һ.б. бик күп күренешләрне каршы куеп сурәтләвенә бәйләп аңлата. Дөрес, бүгенге көндә татар телендә синонимия, антонимия күренешләре галимнәр тарафыннан, инвариант һәм инвариантның парадигмаларына нигезләнеп, яңача аңлатыла. Мәсәлән, тел галиме И.Б. Бәширова хезмәтләрендә синонимия күренеше денотат-сигнификат белән бәйле теориягә нигезләнеп тасвирлана һәм язма чыганаклардан китерелгән күпсанлы мисаллар белән дәлилләнә [Бәширова, 2010, б. 265–314].

Г. Тукай иҗатында синонимнарның кулланылыш үзенчәлекләре соңгы елларга караган хезмәтләрдән Э.Н. Денмухаметова мәкаләсендә дә барлана. Автор Тукай шигырьләрендә очраган синонимик берәмлекләрне абсолют, парлы, семантик (идеографик) һәм мәгънәсе буенча якын торган синонимнар дип, берничә төргә бүлеп анализлый, шагыйрь иҗатыннан мисаллар китерә. Автор фикеренчә, шагыйрь синонимнарны фикерен төгәлрәк җиткерү, образлар-вакыйгаларга төрле яклап бәя бирү, персонажларның шәхси сыйфатларын тулырак ачу һәм, әлбәттә, кабатлаулардан арыну максатларында кулланган [Денмухамметова, б. 242–244].

Югарыда телгә алынган чаралардан тыш, Г.С.Әмиров шагыйрь иҗатында киң кулланылган башка тел чараларын да аерым-аерым тукталып анализлый. Чагыштыру, эпитет, метафора, аллегория, гипербола, символ, җанландыру, градация, гротеск һәм анафора, эпифора кебек стилистик фигуралар, инверсия, риторик сорау, риторик өндәү кебек синтаксик чаралар – барысы да Г.С. Әмиров хезмәтендә чагылыш таба. Галим әлеге сурәтләү чараларын ясауда катнашкан лексик берәмлекләрне күпсанлы мисалларга таянып анализлавы белән Г. Тукай иҗатының кабатланмас булуын дәлилләргә омтыла.

Шагыйрьнең бер үк сүзне төрле мәгънә төсмерләре бирү өчен файдалана белү осталыгы тел галиме В.Х. Хаков хезмәтләрендә югары бәяләнә. Г. Тукай әсәрләрендәге полисемия, контекстуаль синонимнар, фразеологик әйтелмә, чагыштыру, кабатлау һ.б. лексик-фразеологик чараларның кулланылышы галим тарафыннан мисаллар белән тасвирлана. Автор лексик берәмлекләрнең күчерелмә мәгънәдә кулланылышы барыннан да бигрәк шагыйрьнең сатирик әсәрләрендә зур урын алып торуын искәртә [Хаков, б. 285]. Ф.С. Сафиуллина Г. Тукайның, башка лексик чаралар

белән беррәттән, кабатлауларны бик оста куллануын игътибарга ала: «Алар ярдәмендә шагыйрь фикерне үстерә, көчәйтә, актуальләштерә, сөйләмне интонацион яктан баета, төрлеләндерә, халыкның җанлы сөйләменә якынайта» [Сафиуллина, б. 263]. Тукай телендәге аерым лексик берәмлекләрнең кабатлануын, кулланылу ешлыгын тикшерү барышында галимнәр, шагыйрьнең теге яки бу лексик берәмлекне кабатлау аша шигырьнең эмоциональлеген, поэтик җанлылыгын арттыруга ирешүен дә раслыйлар. Теге яки бу сүзнең төрле мәгънәләрдә килә алуы да аның ешлыгы артуына китерә һәм бу шагыйрь иҗатының лексик үзенчәлеге булып тора, диләр авторлар [Сафиуллина, б. 297, 303].

Мәгълүм булганча, көлкеле образлар тудыру, үз чорының хакимият органнарын, патша яраннарын, наданлыкны тәнкыйтьләү максатыннан Г. Тукай, башка сурәтләү чаралары белән беррәттән, чагыштыруларга да еш мөрәҗәгать иткән. Шагыйрьнең сатирик әсәрләрендә кулланылган чагыштырулар Ф.А. Абдуллина мәкаләсендә тикшерелә. Автор фикеренчә, «Китмибез», «Мужик йокысы» һ.б. шигырьләрдәге чагыштырулар Тукайга капиталистик дөньяны төрле яклап сурәтләргә, халыкны ачлыкта басылып яшәргә мәҗбүр иткән сәбәпләрне ачарга ярдәм итә [Абдуллина, б. 226–228].

Г. Тукай тарафыннан мул кулланылган лексик берәмлекләрнең тагын берсе – фразеологизмнар. Бу төр лексик берәмлекләр узган гасыр башында ук галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Күренекле галим Г. Шәрәф 1913 елда 170 кә якын афористик берәмлекне туплап, «Тукаев сүзләре» дигән җыентык бастыра. Әлеге җыентыкта Тукай кулланган канатлы гыйбарәләр галим тарафыннан 13 тематик төркемгә аерып бирелә. Г. Тукай иҗатының афористик берәмлекләрен туплау юнәлешендә бу хезмәт беренче тәҗрибә булган дисәк тә ялгышмабыз. Соңрак, XX гасыр урталарына таба, Тукай әсәрләрендәге халык авыз иҗаты үрнәкләрен башка телче галимнәр дә игътибарга ала. Мәсәлән, шагыйрьнең фразеологик берәмлекләр белән мәкаль-әйтемнәрне әсәр тукымасына үтемле итеп кертеп җибәрә белү осталыгы Ш.А. Рамазанов тарафыннан күрсәтелә, «Шүрәле», «Төрекчәдән», «Катиле нәфескә» һ.б. шигырьләреннән мисаллар китерелә [Рамазанов, б. 66]. Шагыйрь иҗатындагы барлык фразеологик әйтемнәрне туплап, тирәнтен анализлау юнәлешендә исә Г.С. Әмиров зур эш башкара. Аның докторлык диссертациясенең тулы бер бүлеге фразеологик әйтелмәләрне тикшерүгә багышланган. Галим Тукай фразеологи-

ясенең төп чыганаклары итеп, беренче чиратта, халык сөйләмен, икенчедән, «Йосыф вә Зөләйха», «Кисекбаш» әсәрләреннән килә торган китап фразеологиясен күрсәтә. Автор Г. Тукай фразеологиясен, В.В. Виноградов хезмәтенә нигезләнеп, ике зур төркемгә бүлеп анализлый. Галим искәрткәнчә, Тукайның зур осталыгы халык фразеологиясен үзгәртеп куллануда, яисә үз әйтемнәрен ясауда ачык күренә. Автор фикеренчә, шагыйрь канатлы гыйбарәләрне куллану җәһәтеннән аеруча соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләрендә зур осталыкка ирешә [Амиров, 1968, б. 42–49]. Хезмәтенең соңгы бүлекләрендә галим Тукай фразеологиясен төркемнәргә бүлә, аларның поэтик-стилистик функцияләрен күрсәтә, метафора, метонимия, чагыштыру һәм җанландыру кебек чаралар ролендә кулланылуын мисаллар белән дәлилли. Шагыйрьнең фразеологизмнарга еш мөрәҗәгать итүен галим болай дип аңлата: «Фразеологизмы привлекли поэта особенно и тем, что в них содержится осуждение, критика и осмеяние различных пороков, против которых он активно боролся» [Амиров, 1968, б. 51]. Галим Тукай фразеологиясен анализлау белән генә чикләнмичә, аларның сүзлеген дә төзеп, кушымта буларак тәкъдим итә.

Г.С. Әмировтан соң Г. Тукай иҗатындагы канатлы гыйбарәләрне махсус алып анализлаган хезмәтләр юк. Дөрес, В.Х. Хаков, Ф.С. Сафиуллина хезмәтләрендә, башка лексик берәмлекләр белән беррәттән, фразеологизмнарга да күзәтү ясала. Мәсәлән, В.Х. Хаков Тукай иҗатында очраган канатлы әйтемнәргә мисаллар китереп, шагыйрь иҗатында әлеге лексик чараларның зур роль уйнавын искәртә: «Г. Тукайда фразеология югары яңгырашка һәм гадилеккә ирешүгә хезмәт итә...» [Хаков, б. 284].

«Шагыйрь иҗатында татар халык мәкальләре, фразеологиясенең гаять бай чагылышын күрергә мөмкин» дип, Ф.С. Сафиуллина да шагыйрь иҗатының афористик берәмлекләргә бай булуын әйтеп уза [Сафиуллина, б. 266].

Югарыдан күренгәнчә, Г. Тукай иҗатында сүз-сурәт яисә образ тудыру чарасы буларак кулланылган лексик берәмлекләр татар тел белемендә шактый өйрәнелгән, бу юнәлештә аеруча Ш.А. Рамазанов, Г.С. Әмиров, В.Х. Хаковның хезмәтләре ихтирамга лаек.

4. Г. Тукай иҗатында кулланылган лексиканы тематик яктан анализлау.

Г. Тукай шигырьләренең лексикасын тематик яктан өйрәнү әле соңгы елларда гына башланды дисәк тә ялгыш булмас.

Шагыйрь иҗатының лексик хәзинәсен тематик-семантик төркемнәргә бүлеп системалы тикшергән монографик хезмәтләр булмаса да, бу өлкәдә кайбер тикшеренүләр күзәтелә. Мәсәлән, шагыйрь иҗатындагы соматик берәмлекләр Ә.Т. Шәмиголова һәм Г.Р. Абдуллина мәкаләсендә анализлана. «Г. Тукай әсәрендә соматик берәмлекләр» дигән язмада шагыйрьнең иҗатында *баш, күз, колак, кул, корсак, йөз* лексемаларының яратып кулланылуы искәртелә һәм алар катнашында ясалган фразеологик бермәлекләр тикшерелә [Шәмиголова, Абдуллина, б. 224–225]. Ләкин китерелгән мисаллар семантик яктан аңлатылмый, шигырьдән мисаллар китерү белән чикләнелә.

Шагыйрьнең зоонимик лексиканы актив куллануы О.Н. Галимова тарафыннан өйрәнелә. Автор үзенең мәкаләсендә Г. Тукай иҗатында кулланылган *көчек, сарык, дуңгыз, куян, эт, бүре* һ.б. зоонимнарын анализлый. Автор фикеренчә, шагыйрь зоонимик лексиканы башкаларга үзенең мөнәсәбәтен белдерү, теге яки бу геройга характеристика бирү максатларыннан кулланган [Галимова, 2011, б. 252–254].

Тукай шигъриятендәге орнитологик лексиканың кулланылыш үзенчәлекләре Э.И. Сафина мәкаләсендә тасвирлана. Автор үзенең язмасында шагыйрьнең кош образларын яратып, аларга төрле мәгънәләр салып куллануын, орнитологик лексиканы кешеләргә бәя бирүдә, образлы сурәтләр, чагыштырулар китерүдә оста файдалануын, кош атамалары белән бергә алар чыгарган тавышларга да еш мөрәҗәгать итүен анализлый, халык авыз иҗаты, аеруча мәкаль-әйтемнәр белән параллельләр үткәрә. Шагыйрьнең иҗатында аеруча *карга, сандугач, былбыл, чыпчык, тургай, күркә, әтәч, былбыл* һ.б. кебек кош атамаларының еш очравын искәртә [Сафина, б. 254–256].

5. Г. Тукай иҗатындагы ономастик лексиканың кулланылышын тикшерү.

Шагыйрь әсәрләрендә кулланылган лексик берәмлекләрнең зур бер төркемне тәшкил иткән ялгызлык исемнәре дә галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Шагыйрь иҗатында кулланылган ономастик берәмлекләр Г.С. Әмировның докторлык диссертациясендә чагылыш таба. Хезмәттән аңлашылганча, галим гарәп-фарсы һәм рус теленнән кергән сүзләрне анализлау барышында шул телләрдән алынган ономастик берәмлекләргә дә аерым-аерым туктала, антропонимнар, географик атамалар, вакыт-

лы матбугат исемнәре – барысы да автор тарафыннан игътибарга алына, төркемләнә. Әмма алар турында бик аз мәгълүмат бирелә [Әмиров 1968, б. 35, 39]. Ономастик берәмлекләр тулырак итеп 1969 елда Г.С. Әмировның «Ономастика произведений Габдуллы Тукая» дигән мәкаләсендә анализлана. Галим Г. Тукай шигырьләрендә 600 дән артык кеше исеме, 100 дән артык топоним һәм 150 ләп китап, басма матбугат атамасының кулланылуы, шагыйрьнең аеруча татар һәм рус мәдәниятендә күренекле урын тоткан шәхесләрнең исемнәре зур ихтирам белән телгә алынуы турында яза [Әмиров, 1969, б. 69–72]. Кайбер әсәрләренең тулысынча диярлек кеше исемнәре һәм вакытлы матбугат атамаларыннан торуын аңлатып, автор «Керешу хөтбәсе» памфлетын, «Дөнья бу!», «Нәрсәдән», «Минһаҗ», «Ник, нигә?» һ.б. шигырьләрен мисалга китерә. Г.С. Әмиров фикеренчә, шагыйрь иҗатында ономастик лексика, чагыштыру, фразеологик берәмлекләр составында килеп, үзенчәлекле сүз-сурәтләү буларак та, реаль образлар тудыру чарасы итеп тә файдаланыла [Әмиров, 1969, б. 68–74].

Шагыйрь иҗатында телгә алынган географик атамаларның, мәсәлән, *Казан, Әстерхан, Кырлай, Кушлавыч, Идел, Агыйдел* һ.б. кебек шәһәр, авыл, елга исемнәренең кулланылыш үзенчәлекләре Ф.Г. Гарипова мәкаләсендә яктыртыла, әлеге атамаларның килеп чыгышы аңлатыла [Гарипова, б. 213–215]. Шагыйрьнең кеше исемнәренә мөнәсәбәте, татар милли антропонимнарының мәгънәсенә игътибар итүе, исемнең тәрбияви роле, милли рухка туры килергә тиешлеге белән бәйле мәсьәләләр Г.Р. Галиуллина хезмәтендә яктыртыла. Автор Тукайның «Гаҗәп түгелме?», «Исемнәребез хакында» һ.б. мәкаләләренә нигезләнеп, шагыйрьнең кеше исемнәренә мөнәсәбәтен, татар антропонимик системасында милли традицияләрнең формалашуына зур өлеш кертүен анализлый. Шулай ук галим шагыйрьнең әйтелеш өчен артык катлаулы һәм телебез өчен чит-ят булган исемнәргә карата әйтелгән фикерләренең бүгенге көндә дә актуаль булуына басым ясый [Галиуллина, 2011, б. 217–218]. Тукай шигъриятендә кулланылган тарихи шәхесләрнең исемнәре, документаль антропонимнарның кулланылышы М.З. Вәлиева мәкаләсендә чагылыш таба. Автор шагыйрь кулланган тарихи шәхес исемнәренең Тукай иҗатында нинди вазыйфа башкаруын җиде төркемгә бүлеп анализлый, бу төр ялгызлык исемнәрдә Тукайның рухы, дөньяга карашы да чагылыш табуын раслый [Вәлиева, б. 256–258].

6. Г. Тукай иҗатындагы лексик байлыкны лингвокультурологик яссылыкта тикшерү.

Язучы, шагыйрьләрнең иҗатында кулланылган лексик байлыкны лингвокультурология фәне кысаларында тикшерү татар тел белемендә актуаль юнәлешләрнең берсе булып тора. Г. Тукай иҗатын әлеге юнәлештә өйрәнүнең кайбер нәтиҗәләре Ф.К. Сәгъдиева, Ф.Р. Сибгаева, А.З. Хәбибуллина мәкаләләрендә чагылыш таба. Ф.К. Сәгъдиева үзенең «Эш (работа) в творчестве Г. Тукая» дигән мәкаләсендә шагыйрь иҗатында урын алган «Эш» концептын анализлый. Автор фикеренчә, *эш* сүзе Г. Тукай әсәрләрендә төп урынны алып тора. Шагыйрь өчен эш халыкка хезмәт итү, уңышка ирешү, алга китү буларак күзаллана һәм ялкаулык, хәерчелек, булдыксызлык һ.б. мәгънәләргә каршы куела [Сагдеева, б. 258–260]. Ф.Р. Сибгаеваның «Г. Тукай шигъриятендә «мәхәббәт» концепты» дигән мәкаләсендә «Мәхәббәт» концепты шагыйрьнең эчке, хисси дөньясы белән бәйләп аңлатыла. Автор аның төп семантик төрләрен күрсәтә*, мәхәббәт* лексемасы белән бәйле синтагматик күренешләрне билгели [Сибгаева, б. 260–261]. «Күңел» концептын анализлаганда исә, А.З. Хәбибуллина Тукайның *җан / күңел* белән бәйле күзаллауларын рус шагыйрьләреннән Лермонтов, Пушкин, Тютчев, татар әдипләреннән С. Рәмиев, Дәрдмәнд кебек шагыйрьләрнең карашлары белән чагыштырып бирә. Автор фикеренчә, Тукай шигъриятендә «күңел» концепты, рус поэзиясенә хас булганча метафоралар, чагыштырулар аша түгел, ә күбрәк фигыльләр ярдәмендә ачыла (*җан арый, күңел сызлый* һ.б.) [Хәбибуллина, б. 261 – 263].

Татар милли телен баету һәм үстерүне максат итеп яшәгән Г. Тукайның һәрбер әсәре, ул әсәрдә кулланылган һәрбер сүзе эчке яңгырашы, милли моңы белән зур көчкә һәм бары тик бөек шагыйрь генә куллана белгән кабатланмас мәгънәгә ия. Моңа югарыда телгә алынган хезмәтләр дәлил булып тора. Шуңа да карамастан, Г. Тукай шигъриятенең тел байлыгын яңа фәнни карашлардан чыгып тикшерү татар тел белемендә бүгенге көндә дә актуаль булып кала бирә.

**Әдәбият**

*Абдуллина Ф.А.* Сравнения в сатирических произведениях Г. Тукая // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни бағланышлар. Казан, 2011. Б. 226–228.

*Амиров Г.С.* Язык Тукая (Лексика и фразеология): автореф. дис. ...докт. филол. наук. Алма-Ата, 1968. 72 с.

*Амиров Г.С.* Синонимы в произведениях Г. Тукая // Тюркская лексикологи и лексикография. М.: Наука, 1971. С. 47–60.

*Амиров Г.С.* Ономастика Тукая // Ономастика Поволжья: Сборник материалов 1-ой Поволжской конференции по ономастике. Ульяновск, 1967. С. 68–74.

*Ахунзянов Э.М.* Русские кальки в татарском литературном языке // Вопросы татарского языкознания. Казан: Тат. книж. изд-во, 1965. С. 38–49.

*Бәширова И.Б.* Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр. Казан, 2006. 192 б.

*Бәширова И.Б.* XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле һәм Г. Тукайның башлангыч чор иҗаты / Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни баганышлар. Казан, 2011, - Б. 207–210.

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле. Семасиология. Казан, 2010. 532 б.

*Валитова Ю.А.* Иноязычные элементы в поэтических произведениях Г. Тукая (турецко-огузский элементы и арабские масдары): автореф. дис. ...канд.филол.наук. М., 1966. 23 с.

*Вәлиева М.З.* Г.Тукай иҗатында тарихи шәхес исемнәре / Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 256–258.

*Галимова О.Н.* Зоонимы в художественном дискурсе Г. Тукая / Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 252–254.

*Галиуллина Г.Р.* Татар антропонимиясендә милли традицияләр формалашуда Г. Тукайның роле // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 217–219.

*Гарипова Ф.Г.* Г.Тукай иҗатында географик атамалар кулланылышы // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 213–216.

*Денмухеметова Э.Н.* Синонимы в поэзии Г. Тукая // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 242–245.

*Исхак Ә.* Тукайның шигъри осталыгы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 126 б.

*Йосыпов А.Ф.* Г. Тукай әсәрләренең стиль үзенчәлекләре (суфичыл әсәрләр мисалында) // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 232–234.

*Йосыпова Ә.Ш.* XIX гасыр икетелле сүзлекләре һәм Тукай теле // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 219–222.

*Миннуллин Б.К.* Г. Тукай и языковая ситуация начала XX века // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 234–236.

*Рамазанов Ш.А.* Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле // Габдулла Тукай: шагыйрьнең тууына 60 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан: Татгосиздат, 1948. Б. 136–170.

*Рамазанова Д.Б.* Г.Тукай һәм XX гасыр башы әдәби теле // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 204–207.

*Сагдеева Ф.К.* Эш (работа) в творчестве Г. Тукая / Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 258 0 260.

*Сафина Э.И.* Г. Тукай шигъриятендә орнитологик символика // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 256–258.

*Сафиуллина Ф.С.* Тукай әсәрләрендә җанлы сөйләм теле // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Казан, 1997. Б. 254–258.

*Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М.* Тукай теленең ешлык сүзлеген төзү тәҗрибәсеннән // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Казан, 1997. Б. 297–303.

*Сибгаева Ф.Р.* Г. Тукай шигъриятендә «мәхәббәт» концепты // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 260–261.

*Хабибуллина А.З.* Концепт «душа» в творчестве Тукая и русских поэтов XIX–XX веков // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 261–264.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле тарихы. Казан: КДУ нәшр., 1993. 325 б.

*Хәбибов Л.Г.* Г. Тукай әсәрләрендә рус һәм Европа алынмалары // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 230–232.

*Хисамова Ф.М.* Тукай шигъриятендә әдәби тел яңарышы // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Казан, 1997. Б. 254–257.

*Юсупова А.Ш.* Татар теле үзөйрәткечләре һәм Тукай теле // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Казан, 1997. Б. 309–314.

*Миләүшә Вәлиева,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов Тел, әдәбият сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

## ТОТАЛИТАР ДӘВЕР (1917–1956) ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЕ Г. ТУКАЙНЫҢ ДИНИ КАРАШЛАРЫ ХАКЫНДА

1917 елгы Бөек Октябрь инкыйлабы китергән үзгәрешләр, җәмгыятьнең сәяси һәм иктисади ягына гына түгел, әдәбият һәм сәнгать өлкәсенә дә зур йогынты ясады. Әлегә кадәр иҗтимагый тормышта төп роль уйнаган дин кануннарын совет хөкүмәте, коммунистлар тарафыннан игълан ителгән күп төрле закон-актлар алмаштырды. Шуның белән динне дәүләттән аеру, аның җәмгыять үсешенә тискәре йогынтысын дәлилләү, гомумән, дини идеологияне бөтенләе белән кире кагып, аның урынын марксистик идеология белән тутыру эше җәелдерелде.

Дөрес, татарлар арасында ислам дине фәлсәфәсенең кайбер якларын яңа иҗтимагый үсеш югарылыгыннан торып аңлату, дингә тиешле реформалар үткәрү юлы белән аны кешелек җәмгыятенең яңа этабына әзерләү эшен XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башларында Габдерәхим Утыз Имәни, Габденнасыйр Курсавилар ук башлап җибәргән иде. Соңгарак ул Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани һ.б. дини реформаторларыбыз тарафыннан дәвам иттерелә. Алар ислам диненең иҗтимагый прогресс, кеше иреге, акыл эшчәнлеге белән каршылыкка кергән өлешләрен үзләре яшәгән чорның аң дәрәҗәсе югарылыгыннан торып кабул итәргә чакырдылар. Ислам дине мөселман халыкларының икътисади, мәдәни, рухи үсешенә, җәмгыятьтә шәхеснең күпкырлы эшчәнлегенә юл ачуга хезмәт итәргә тиеш дип карадылар. Димәк, ислам диненең кешелек җәмгыяте өчен зур әһәмияткә ия булган өйрә-

түләрен саклаган хәлдә, аңа кайбер үзгәрешләр кертергә дә мөмкин дип санадылар. Әмма марксизм тарафдарлары динне социалистик җәмгыятьнең дошманы дип игълан итеп, аны ахыргача юк итү максатын куйды. Инкыйлабтан соң башланып киткән атеистик көрәш, идеология өлкәсендә алып барылган үзгәртеп коруларның асылы да шуңа барып тоташты.

Дингә каршы оештырылган һөҗүмнәр ягыннан, тоталитар дәвер әдәбиятында 20–30 нчы еллар аралыгы аерым урын алып тора. Бу еллар – Татарстанда дингә каршы хәрәкәтнең аеруча кискенләшкән чоры. 1927 елда «Дини хәрәкәтнең торышы һәм дингә каршы пропаганданың куелышы турында» яңа карар кабул ителә. Дингә каршы юнәлтелгән әдәбият бастырып тарату эше үзгәртеп корылып, татар совет әдәбияты һәм сәнгате дә атеистик идеологиягә хезмәт итәргә тиеш дигән күрсәтмә чыгара. [1, б. 18, 19]

Дингә булган мөнәсәбәтнең тискәре якка үзгәрүе Коръән һәм ислам дине белән берегеп үскән әдәби һәм мәдәни мирасыбызны юкка чыгу куркынычы алдына куя. Атеистик идеологияне пропагандалау уңае белән башланып киткән «чистартулар» рухи мирасыбызга да зыян сала.

Дәһрилек урнашкан чорда Габдулла Тукай иҗатындагы дини мотивларга да мөнәсәбәт тамырдан үзгәрә. Тукайның иҗтимагый-сәяси карашларын җентекләп, аның кайсы сыйныфка хезмәт итүен билгеләргә тырышу, иҗатындагы дини мотивларны, ислам һәм Коръәнгә мөнәсәбәтен ачыклау Октябрь инкыйлабыннан соңгы әдәби тәнкыйтьнең аерылгысыз бер өлешен тәшкил итә. Шагыйрь иҗатын бәяләү буенча бәхәсләр башлана. Әлегә кадәр «халык шагыйре» исеме белән танылган Тукайга «динче», «милләтче», «вак буржуа шагыйре» кебек төрле ярлыклар тагыла. Бигрәк тә, шагыйрьнең дингә уңай мөнәсәбәтен чагылдырган әсәрләре Тукай шәхесен һәм иҗатын бәяләүдә күп каршылыклар тудыра. Берәүләр аны «динче», «милләтче» дип, бөтенләй кире кага, икенчеләре, төрле дәлилләр табып, шагыйрь мирасын саклап калырга тырыша.

20 нче елларда Тукай иҗатын бәяләүдә Фәтхи Бурнаш белән Фатих Сәйфи-Казанлы тоткан ике юнәлеш күзгә бәрелеп тора. Ф. Бурнаш Тукайның дингә булган уңай мөнәсәбәтен артык күпертеп тормастан, аны буржуазия милкенә бирмәү өчен көрәшә. Ф. Сәйфи-Казанлы исә моңа ачыктан-ачык каршы чыга. Ә өченче төркем, Тукайны теге яки бу кысаларга көчләп кертүне

кирәксенмичә, аның иҗатындагы дини эчтәлекле шигырьләргә бөтенләй игътибар бирми. Бу үзенә күрә шагыйрьне дәһри чор җәнҗалларыннан саклап калуның бер чарасы булып тора.

Әлеге заман вакыйгаларын күңелендә яңартып, Афзал Шамов түбәндәгеләрне яза: «Ул елларда (1923 еллар. – *Д.А.*) матбугатта Тукай турында ике төп караш яши иде: берәүләр аны вак буржуа шагыйре дип, икенче берәүләр халык шагыйре дип атый. Моннан тыш тагын өченче караш та туып, баш калкытып килә иде. Сул киселгән кайбер тәнкыйтьчеләр ... шәрә политиканнар Тукай үлүенә 10 ел тулу уңае белән аның иҗатын тикшергән булып, урыны туры килүдән файдаланып, «Тукай безнең шагыйрь түгел, аның социалистик революциягә дә, пролетариатка да мөнәсәбәте юк, ул либераль буржуа шагыйре, ул аларга хезмәт итте», дип төрле урыннарда сафсата сатарга керешәләр иде». Афзал Шамов шунда ук әлеге тойгыга бирелгән университет рабфагында укучы яшьләрнең:

– Буржуа шагыйрен искә алырга, аңа багышлап кичә уздырырга ирек бирмәбез» [12, б. 3], – дип каршы чыгуларын да әйтә. Болар һәммәсе бу елларда Тукай мирасына тискәре мөнәсәбәтнең аеруча кискенләшкәнлеген күрсәтеп тора. А. Шамов Тукайның үлеменә 10 ел тулуга багышланган кичәдә төп докладчы Ф. Әмирхан булуын, аның Тукайны «халык шагыйре» дип атавын, моңа җавап йөзеннән Ф. Сәйфи-Казанлы күтәрелүен һәм «Фәтхи Бурнаш белән бер үк җырны җырлыйсың. Фатих Әмирханнар һәм аның иптәшләре миңа күпме ачулансалар да, Тукайны коррективсыз, шартсыз халык шагыйре дип кабул итә алмыйм. Тукай шигырьләрендәге мотив – сыйнфый көрәш мотивы түгел, бәлки вак буржуаз милләтчелек мотивы. Ул – вак буржуа шагыйре. Ул Аллага, Аның яратучы булуына ышана. “Иң дөрес дин – Коръәндә күрсәтелгән Ислам”, – ди» [12, б. 6], – дип кычкыруын да искә ала.

«Вак буржуачылык» дигәндә, егерменче – утызынчы еллар тәнкыйтендә, әлбәттә, пролетариат әдәбияты өчен ят дип саналган күренешләр күздә тотыла. Менә шулардан соң, әлбәттә, А. Шамов үзе тасвирлаган өченче төркемдә Ф. Сәйфи-Казанлы кебекләрне күзаллагандыр дип нәтиҗә ясарга кала.

20 нче елларда Ф. Әмирхан, Г. Гали, Ф. Бурнашлар, каршылыкларга да карамастан, Тукай иҗатының абруе өчен көрәшүчеләрдән булалар.

Илдә барган вакыйгаларны күзәтеп, анализлап кабул иткән Ф. Әмирхан дусты һәм иҗатташы Тукайга биргән бәясендә «ана-

литик фикер йөртүче булып кала. Ул Тукай исемен вак буржуа гайбәттән саклый, аның тормыш юлына объектив һәм тәнкыйди анализ ясый. Гомумән, тәнкыйтьче буларак Ф. Әмирхан Тукай иҗатын ялган бәя алудан саклап килә», дип яза әдәбиятчы, тәнкыйтьче, галим Мөхәммәт Мәһдиев [4, б. 61].

Бу шаукымлы елларда Тукай иҗатын халыкка җиткерү һәм аны «буржуаз милек»кә әйләнүдән саклап калучыларның иң күренеклесе, иң зур хезмәт куючысы, әлбәттә, Фәтхи Бурнаш була.

1926 елда Фәтхи Бурнаш «Гажур» нәшриятында Тукайның сайланма әсәрләрен бастырып чыгара. Бу китапка барлыгы 158 әсәр урнаштырыла. Дин белән бәйләнешле шигырьләр бу җыентыкка бөтенләй кертелми. «Туган авыл» шигырендәге дингә мөнәсәбәтле юллар кыскартыла. Җыентык авторы моны «Тукай иҗаты өчен характерлы булган, Тукайның хосусиятләрен ачып бирә алырлык әсәрләрен чүпләп җыйдык» [2, б. 232], дип аңлата.

Фәтхи Бурнаш, Тукайның дингә, суфичылык әдәбиятына бәйле карашларын булдыра алган кадәр эчкәрерәк яшереп, игътибарсыз гына үткәреп җибәрергә җыена. Моның үз сәбәбе бар: шагыйрь тирәсендә бәхәсләр кыза барып, Тукайга «динче», «милләтче», «вак буржуа шагыйре» дигән ярлыклар таккач, аның иҗатын яңа җәмгыять өчен кирәксез дип тамгалаулар башлангач, Ф. Бурнаш әлеге карашлар белән килешми. «Без үзебезнең уяну дәвере көрәшчеләреннән Тукай, Мәҗит абзыйлар кебек шагыйрьләрне һичбер буржуазия милкенә бирәсебез килми» [2, б. 96] дип, әлеге гаепләүләргә каршы чыга. Ф. Бурнаш фикеренчә, шагыйрь иҗатының чор идеологиясенә яраклы якларын гына кабул итәргә, «башлангыч чорда язган, кайбер милли, кайчак дини хисләргә кагылган шигырьләрен, Тукай өчен бөтенләй характерлы булмаганлыктан, алып ташларга гына кирәк. Ул: «Тукай үзенең шигърияте белән революциягә кадәр килгән татар шагыйрьләренең атасы булып калачак шагыйрь» [2, б. 150], – дип, шагыйрь мирасының яңа җәмгыять шартларында да яшәргә тулы хокукы булуын раслый.

Ф. Бурнаш: «Тукай татар арасында тәсбих төймәсе урынына күкрәкләргә асылган динчелек лирасына каршы ачыктан-ачык сугыш ачты. <...> Дини хәрәкәтнең бер генә тыпырчынуы да аның каләме тирәсеннән тыныч үтеп китә алмады» [2, б. 123], – ди. Кайбер шигырьләренең өслүб ягыннан «Газизә», «Бәдәвам» кебек дини-суфичыл әдәбиятка охшашлыгын да ул бу әсәрләрнең «халык арасында нык үзләшкән, гавамләшкән калыпларга салынып

эшләнүе», нәтиҗәсе итеп карарга куша. «Шәрекъ әдәбияты тәэсиреннән бик тиз арынды. <...> Каләменең үткенлеге, фикеренең житезлеге, мәүзугъларының көндәлек тормышка җавап бирә баруы рус әдәбиятыннан <...> сабак ала белүен күрсәтә» [2, б. 137, 138] дип, аның Шәрыктан баш тартуын, совет идеологиясенә хуш килгәнчә, Европа һәм рус әдәбияты йогынтысына тартылуын аеруча ассызыклый. Боларның һәммәсе дә Тукай иҗатын заман идеологиясе таләпләренә якынайту өчен эшләнә.

Димәк, Фәтхи Бурнаш Тукай иҗатын «динче», «милләтче» дип халык күзеннән ычкындырмаска тырыша, моның өчен ул аның әсәрләрендәге партия күрсәтмәләренә туры килмәгән якларны икенче плангарак кичереп, кирәклерәк урыннарын өскә калкытып, көн таләпләренә яраклаштыруны хата дип санамый. Ләкин Фатих Сәйфи-Казанлы аның бу эшен «сәяси һәм иҗтимагый хыянәт» [6, б. I] дип атый.

Атеистик тәрбия иң кызган 1929–1931 елларында Тукайның Ф. Сәйфи-Казанлы тарафыннан тупланган өч томлык әсәрләре дөнья күрә. Тукай әсәрләрен матбугатка тәкъдим итү һәм бәяләү дә дәһрилек шаукымы басымы астында башкарыла. Тукайның дингә мөнәсәбәте турындагы Фатих Сәйфи карашлары вульгар социологизмның классик бер үрнәге булып тора. Тәнкыйтьче пролетариат диктатурасы һәм сыйнфыйлык күзлегеннән чыгып, Тукай иҗатындагы дини мотивларга уңай бәя биргән язучыларга, тәнкыйтьчеләргә каты-каты гаепләү сүзләре ыргыта, Фәтхи Бурнашның «Тукай өчен динчелек характерлы сыйфат түгел» дигән фикерен кире кага.

«Тукай динне милләт белән бәйләп йөри, динне милләткә хезмәт иттерә, шуның белән бергә аны һич онытмый» [6, б. XIX], – ди.

Ф. Сәйфи-Казанлыча, Тукай – башы-аягы белән мәдрәсә җимеше, милләтче, вак буржуа шагыйре, ә милләтче вак буржуа шагыйре Алланың барлыгына ышанамы, юкмы – дингә каршы булырга тиеш түгел. Тукай Коръәнне белгән, хәдис белән гамәл кылган «муллаларга, динчеләргә каршы түгел, Бохара муллаларына, Төркия пүркиләренә каршы сугыш ачу – динчелеккә каршы сугыш ачу түгел, бәлки, феодализм калдыгына каршы көрәшү иде» [6, б. XX]. «Тукай – социалист! Тукай – панисламист!» – дип әйтү Тукайга яла ябу булыр иде» [6, б. XIX], ди. Һәм нәтиҗә ясап түбәндәге сүзләрне әйтә: «Тукай ышанган дин, милләт идеясенең гегемониясе көнләп, сәгатьләп сүнә бара. Пролетариат идеологи-

ясе социализм төзү энтузиазмы астында тәрбияләнә торган татар яшьләре өчен язылган ноталарда җырларга Тукай шигырьләре һич яраклы түгел» [6, б. III].

Фатих Сәйфи-Казанлы Тукай иҗатының киләчәгенә шик белдерә, аның әһәмиятен бары «үз вакытында феодализм калдыклары белән ригаясез көрәшүендә» генә күрә. Ул Ф. Әмирханның Тукайны «халык шагыйре» дип атавын да, Ф. Бурнашның Тукай иҗатын бүгенге көн идеологиясенә яраклаштырып кабул итәргә тырышуын да, динчелеген күрмичә, дин әһелләрен генә сүгә дип бәяләвен дә кабул итә алмый. Шагыйрьнең үлеменә 10 ел тулу уңаеннан уздырылган кичәдә әйткән фикерен тәнкыйтьче еллар узгач та үзгәрешсез калдыра. Тукайның дин белән берегеп үсүен ул: «Иң дөрес дин – Коръәндә күрсәтелгән Ислам», дигән сүзләрендә күрә» [6, б. XXXII, XXXIII]. Аның төп нәтиҗәсе – «Тукай динне милләт белән кушып барган, яза башлаган моментыннан вак буржуа идеологиясе шагыйре булып, үлгәнгә кадәр шуннан аерыла алмаган»; «чын мөселманлыкны, чын милләтчелекне, чын социальлекне барысын да бергә бутап йөргән» [6, б. XVI]. Шул ук вакытта Ф. Сәйфи-Казанлы күпмедер дәрәҗәдә Тукай иҗатының әһәмиятен дә таный. Ул аны «Руссия татарларының уяну чорында дөньяга чыгып, шул вакытларның дулкыны, хәрәкәте эчендә үскән шагыйрь һәм шул хәрәкәтне үзенең әсәрләрендә гәүдәләндергән әдип» [6, б. VII], дип атый.

Тукай иҗатын бәяләүдә Габдрахман Сәгъди кебек күренекле әдәбият галименең дә совет чорында большевистик идеология тәэсиренә бирелүе бик тә ачык сизелә. 1923 елда ул Тукайны чын мәгънәсендә шагыйрь җанлы шәхес буларак тасвирлый, ә инде партиянең 1925 ел 18 июнь резолюциясеннән соң, әдәбиятчылар алдына сыйнфый карашларны эстетик кануннардан өстен кую мәҗбүрияте килеп баскач, 1926 елда «Татар әдәбияты тарихы» дигән хезмәтендә Тукайны шагыйрь булудан бигрәк идеолог итеп сурәтли: «Тукай, чыннан да, идеолог бер лирик иде. Ул үзенең шигырьләре аркылы татар либераль буржуазиясенең дини, милли идеологиясенә ачык бер систем биреште» [5, б. 121] .

Күрүебезчә, Г. Сәгъди инде Тукайны халыкның бер катлавына – вак буржуазиягә генә нисбәт итә. Шушы ук хезмәтендә ул, шагыйрьнең әдәби-эстетик эволюциясен дә дин һәм милләт сызыгына гына салып, фикри үсеш баскычларын түбәндәгечә билгеле:«Тукайның фикри кузгалышы: 1) динчелек, исламчылык белән

башлап, 2) шуннан татар милләтчелегенә, аннан соң 3) милләтчелектән, милләтчелектән йөз дүндерү сызыгына каерылып алып, милли һәм дини өметсезлеккә төшеп алуны, иң соңында янә 4) реакция чагында бөтен йөз белән дингә, «Алла»га, милләтчелеккә кайтып, бөтен шигырьләренең динчелек белән сугарылганын күрсәтәләр; хәтта ул соңыннан әүвәлге кебек, шаяру юлы белән генә булса да, муллаларга тел тидерүдән дә туктады. Тукай лирикасындагы фикри үсү һәм үсү баскычлары әнә шулар иде» [5, б. 219].

Димәк, Г. Сәгъди Тукай иҗатының башлангыч чорыннан алып, ахыргача дини-милли идеология белән сугарылган булуына игътибар итә. Аның фикеренчә, «инде шагыйрьнең «Тәәссер», «Ана догасы», «Туган тел», «Туган авыл», «Ана илә бала» кебекләр шигырьләре яшүсмерләрне «Алла», «фәрештә», «дога» кебек нәрсәләргә өндәүче, Илаһият һәм исламият белән бәйләүче, тел һәм эчтәлек ягыннан яраксыз булып калганнар» [5, б. 123,124]. Шулай итеп, ул Тукай иҗатындагы ислам дине белән бәйләнешле шигырьләрнең киләчәк өчен кирәксезлеген искәртә. Мулла гаиләсендә туган, Төркиядә белем алган Габдрахман Сәгъди, Тукай шигърияте турында теләсә дә, бу елларда башкача чыгыш ясарга җөрьәт итә алмас иде.

Тукайның дингә мөнәсәбәте тәнкыйтьчеләрнең үзләре арасында да кайбер бәхәсләр тудыра. Мәсәлән, «Безнең юл» журналында «Магис» тәхәллүсе белән «Сынган кылычлар һәм каргалар белән былбыллар турында» исемле мәкалә бастырган Мәхмүд Максуд Тукайны халыкныкы, халык шагыйре итеп күрсәтүчеләрне, ислам динен танучы икәнлегенә шик белдерүчеләрне бары «яшелле-кызыллы “марксистлар”» [3, б. 18], дип кенә атый. Аның фикере ачык – Тукай Аллага ышанучы, җәмгыятьтәге үзгәрешләрне Алладан көтүче, мистикага кереп баткан динче.

«Дөньядагы мәлганәтьне һәм пычракны бетерү өчен, – ди М. Максуд, – Алладан йөз чөерү кирәклегенә яки иң кимендә шул теләккә Алла ярдәменнән башка да ирешү мөмкинлегенә Тукай кайчан да булса бер иман китердеме? Тукайның җиде ел буена язган шигырьләре бу сөальгә ачык итеп һәм саңгыраурак кешеләр дә ишетелерлек дәрәҗәдә кычкырып:

– Юк! – җавабын бирәләр»[3, б.19].

Мәхмүд Максуд Тукайны динле итеп күрсәтүче тәнкыйтьче Җ. Вәлиди фикере белән килешә. Ә менә Тукайны «динчелек лирасына, дингә каршы көрәш ачты, диннең якасына ябышты», дип

сөйләүчеләргә ул катгый каршы чыга. Мондый кешеләр, аның фикеренчә, Тукайның ачык әйткән васыятен – «Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем: күр нә рәсмә тулган иман берлә Коръән садремә!» шигырен оныталар һәм әдәбиятка «аю хезмәте» күрсәтәләр» [3, б .20].

Илебездә әдәби һәм мәдәни мираска вульгар социологизм күзлегеннән карап бәя бирелгән, милли, дини рухы өчен Тукай иҗатын өлешчә кире каккан дәвердә чит ил матбугатында шагыйрьнең бөеклеген раслаган, аны халык шагыйре, милләтнең җаны дип атаган мәкаләләр дөнья күрә. Бу яктан 1928–1939 елларда Гаяз Исхакый мөхәррирлегендә Берлинда басылган «Яңа милли юл» (баштарак «Милли юл») журналы аеруча игътибарга лаек. Журналда Тукайның тууын, үлемен искә алу уңаеннан язылган мәкаләләр белән янәшә Совет дәүләтендә шагыйрьгә булган мөнәсәбәтне яктыртканнары еш басылган. Мәсәлән, 1932 ел, 11 санда Г. Исхакыйның «Тукай истәлеге» 1938 ел, 6 санда авторы А.Т. дип күрсәтелгән «Большевик матбугатында Тукай» һ.б. мәкаләләр, моннан тыш Сәгадәт Чагатай, Солтан (Әхмәд Виргаз), Хөсәен Габдүшләр Тукайның милли рухы, иҗтының үлемсезлеге турында язмалары шундыйлардан.

Нәтиҗә ясап 20–30 нчы еллар Габдулла Тукай иҗатындагы дини мотивларны бәяләү өлкәсендә катлаулы көрәш барган чор дип әйтә алабыз. Бу, беренчедән, инкыйлабка кадәрге әдәбиятны яңа идеологиягә хезмәт иттерергә омтылудан, әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр арасында төрле карашлар барлыкка килүдән булса, икенчедән, шагыйрь иҗатының тематик яктан да, идея-фикер ягыннан да гаять бай булуы үзе үк капма-каршы бәяләргә, бер чиктән икенче чиккә ташлануларга сәбәп була.

Бер нәрсә бәхәссез: бу елларда Габдулла Тукай мирасын бәяләүдә бер-берсенә капма-каршы булган ике фикер юнәлеше ярылып ята. Берәүләр, Тукай иҗатының әһәмиятен бәяләп, аның пролетариат әдәбияты эчендә урын алырга һәм аның белән бергә киләчәккә атларга хокукы бар дип саный. Икенчеләре, аның иҗатындагы дингә, миллилеккә уңай мөнәсәбәт, Коръәннән килгән образ-сурәтләр, фәлсәфи уртаклыкны күреп куркып кала һәм мондый иҗатны социалистик җәмгыять төзүче укучыга тәкъдим итүне җинаять дип саный. Ә менә Ф. Әмирхан, Ф. Бурнаш, Җ. Вәлиди, Г. Рәхим кебек тәнкыйтьчеләр, бу ике юнәлеш бәхәсләрен кабул итмичә, Тукайның халык шагыйре булып калуына шик белдермиләр.

Шулай итеп, 20–30 нчы еллар тәнкыйтендә Тукай иҗатындагы дини-милли мотивларга басым ясалып, шагыйрьнең мирасын халыкка тәкъдим итү өлкәсендә каршылыклы фикерләр урнаша. Әлбәттә, болар үз заманында Тукай иҗатын өйрәнүдә бүлгәләнүләр, төрле бәхәсләр тудырып, аның әсәрләреннән бөркеп торган рухи сафлык, садәлек һәм ихласлыкка күләгә төшерәләр. Тик икенче яктан, алар Тукай иҗатындагы миллилек һәм динилекне коммунизм пәрдәсе белән каплап куюдан саклап калырга ярдәм итәләр. Бу елларда барган бәхәсләрнең Тукай иҗатының дин, милләт мәсьәләләренә кагылышлы өлешенә төенләнүе үзе генә дә әлеге мәсьәләнең чишелеш көтеп ятуын күрсәтә.

30 нчы еллар ахырында Тукай иҗатын бәяләүдә зур әһәмияткә ия булган хезмәтләрнең тагын берсе – Гали Халитның «Халык шагыйре Тукай» [9, б. 92] (1939) исемле китабы. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә әле чагыштырмача яшь булуына карамастан, Г. Халит бу хезмәтендә вульгар социологизм вәкилләре юнәлешенә дә кушылып китми, Тукайдан чын мәгънәсендә дәһри шагыйрь ясауны да максат итеп куймый. Аның җиңел кулы һәм акыллы хезмәте белән Тукай, XX гасыр башы әдәби тәнкыйтендәгечә, үзенә лаек урынга кайтарыла, яңадан «халык шагыйре» дип атала башлый. Шул рәвешчә, Тукай иҗатын бәяләү партияле һәм пролетариат әдәбиятын тудыру чорындагы катлаулы көрәш, вульгар социологизм дәверен үтеп, үзенең башлангыч ноктасына, инкыйлабка кадәрге Җамал Вәлиди кебек тәнкыйтьчеләр биргән бәясен кире кайтаруга ирешә.

Икенче бөтендөнья сугышы алдыннан Тукай иҗатындагы дини мотивлар турындагы бәхәсләр, уңга-сулга чайкалулар беркадәр тынып калгандай була, аның шигырьләрендә гәүдәләнгән дини-милли хисләргә күз йомыбрак карап, шагыйрь лирикасындагы социалистик җәмгыятькә хезмәт итәрлек сыйфатларны калкытып өйрәнү гадәткә керә. Әмма шагыйрьнең дингә булган уңай мөнәсәбәтен идеологик ялгыш, чикләнгәнлек дип тамгалау, аның дини эчтәлекле әсәрләренә сак килергә кирәк дигән партия күрсәтмәсе үз көчендә кала. Илдәге атеистик атмосфера аркасында Тукай һәм дин мәсьәләсе әле тиз генә уңай чишелеш таба алмый. «Динче», «милләтче» «вак буржуа шагыйре», «либераль буржуа шагыйре» дигән исемнәр тагылган, әсәрләре читкә тибәрелгән шагыйрьдән әкренләп «мәсләге чын социаллардай» булган шагыйрь ясала һәм җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителә башлый. Алга

таба да Тукай шигырьләрен халык күзенә чыгару аеруча сакчыллык белән башкарыла. Бу эш Алланың барлыгын, берлеген тануга мөнәсәбәтле әсәрләрне укучы күзеннән яшерү юлы белән эшләнә.

40 нчы елларда, СССРдагы барлык халыкларны, барлык милли республикаларны дошманны җиңүгә туплау зарурияте аркасында булса кирәк, дини кысу бераз йомшарып ала. 1943 елда Сталин Ташкентта мөселман руханиларының съездын үткәрергә рөхсәт бирә, шунда ук дини мәктәп-мәдрәсәләр дә ачыла. Бәлки, илдәге шул сәбәпләргә бәйле рәвештәдер, 1943–1948 елларда Тукай әсәрләренең Академик басмасында гаҗәеп бер адым ясала: аңа шагыйрьнең дингә мөнәсәбәтле бер төркем әсәрләре кертелә. Ләкин шагыйрь иҗатына кыскача күзәтү рәвешендә язылган кереш мәкаләдә (җаваплы редактор Х. Ярмөхәммәтов) Тукайның «кешенең кешене эксплуатацияләвен ныгытуда иң әшәке коралларның берсе булган дингә мөрәҗәгать итүе аның иҗатының көчсез ягы булды» [7, б. 30], дигән каты сүзләр әйтелә. Иҗатында дини мотивларга байтак урын бирелүнең сәбәбен әдәбиятчы Тукай рухының крестьян психологисе белән якынлыгында күрә, ә иҗат ысулы ягыннан аларга «Тукай иҗатындагы романтизм элементларының чагылышы булдылар» [7, б. 31], дигән фәнни аңлатма бирә, ягъни моның сәбәпләрен шагыйрьнең дөньяга карашлары һәм иҗат ысулы белән бәйләп аңлата.

Тәҗрибәле Х. Ярмөхәммәтов дин һәм Тукайның дингә мөнәсәбәте турында каты сүзләр әйтсә дә (ул заманда башкача була да алмый иде), нәтиҗәне: «Тукай поэзиясендә буржуазиягә, буржуаз милләтчеләргә, мулла, ишан, суфиларга – гомумән, кадимче көчләргә карата юнәлдерелгән әсәрләр иң күренекле урынны алып тора» [7, б. 35], дип ясый һәм бу сүзләре белән ул шагыйрь иҗатын динчелеккә нисбәттә өелгән гаепләрдән шактый реабилитацияли. Шунысын да истән чыгарырга ярамый: бу басма Сталин дингә лояльлек күрсәткән, Икенче бөтендөнья сугышының иң кызган елларында хәзерләнә. Бу исә Тукайның дини шигырьләре басылган Академик басманы да, аның төзүчеләрен дә, редакторларын да эзәрлекләүләрдән саклап кала.

40–50 нче елларда Тукай иҗатының ислам фәлсәфәсе белән бәйләнеше һәм андагы дини мотивларны өйрәнү күләгәдәрәк калдырыла. Шагыйрьнең тууына алтмыш ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары басылып чыккан җыентыкны (1948) бу еллардагы Тукай иҗатын өйрәнүдәге төп фикер

юнәлешен билгеләүче хезмәт дип карарга була. Җыентыктагы мәкаләләрдә шагыйрьнең «Көнчыгыш йогынтысыннан бик тиз арынуы», «рус классик әдәбияты тәэсирендә тиз арада демократлашып китүе», «милли буржуазия, өстен катлауларга, дини-феодаль фанатизмга, мещанлык, ишанлыкка каршы көрәше»нә төп игътибар юнәлтелеп, Тукай иҗатының революцион-демократик, марксистик-ленинчыл идеяләр белән сугарылганлыгына басым ясала. Мәсәлән, Гали Халит шагыйрьнең «Шагыйрь һәм һатиф» (1906) шигыреннән «Заманың инкыйлабатыйнә бән һәр дәмдә калканым, Бәхак бән нар сачәр әтрафә бер атәшле вулканым» («Заманның үзгәрешләренә мин һаман да калканмын; Чын-чыннан мин тирә-якка утлар чәчәр вулканмын») юлларын мисал итеп ала, һәм «шагыйрь үзен «революциянең утлы вулканы» дип юкка гына атамады дип нәтиҗә ясый [10, б. 9]. Әмма галим анда совет чоры идеологиясенә туры килмәгән, дингә, милләткә мөнәсәбәтле түбәндәге юлларны бөтенләй күрмәмешкә салынып үтә:

Түбәнлеккә төшүенә тугры диннең аһ-ваһ итәм,
Башка милләтнең алга китүенә мин ах-ух итәм [8, б. 61]

Алга таба да Гали Халит: «Реакция елларында милли интеллигенциянең бер өлеше милләтчелек *идеячекләре* (курсив безнеке. – *Д.А.*) – пантюркизм һәм панисламизм белән мавыкканда, Тукай татар халкын үзенең Ватаны – анасы Россиядән, рус халкыннан һәм аның культурасыннан аеруны максат иткән реакция белән көрәшне бер генә минутка да туктатмады» [10, б. 30] дип, шагыйрьне карачкы вазыйфасын үтәгән дини идеологиядән аралый, татар халкын «анасы Россия»гә һәм аның мәдәниятенә мөкиббән киткән кавем итеп күрсәтә.

Дини әдәбиятка булган тискәре мөнәсәбәтне күрсәтергә омтылу тоталитар дәвернең Тукайны өйрәнүче башка әдәбиятчылары хезмәтләрендә дә чагылыш тапты. Тукай иҗатын большевистик идеология күзлегеннән өйрәнү мәҗбүриятен аңлаган әдәбият галимнәре аның дини эчтәлекле әдәбиятка мөрәҗәгате «бары эзләнүләр рәвешендә генә, ул бу әсәрләрнең формаларыннан, шигъри үлчәмнәреннән генә файдалана, аларның дини-мистик эчтәлегенә баштан ук тәнкыйть күзе белән карый», <...> «үз иҗатының идея тирәнлеген, художество көчен баетуда бөек рус язучылары Пушкин, Лермонтов, Кольцов, Некрасов һ. б.лардан үрнәк ала, татар фольклорын тирән мәхәббәт белән җыйнау һәм аны өйрәнүдә

дә шул ук бөек рус язучылары традицияләре буенча бара» [13, б. 112]; «Тукай, Көнчыгыш тәэсирен җиңә-җиңә, татар әдәбиятын рус халкының югары культурасы традицияләре белән баетырга омтыла» [11, б. 130], – дип язарга мәҗбүр булдылар, шуңа мондый фикерләр күп әдәбиятчылар хезмәтләрендә кабатлана.

Дөрес, яңа бер тарихи чорда – XX гасыр башында – мәйданга чыккан шагыйрь үзенең иҗатында рус әдәбияты, аның аша башка Аурупа әдәбиятлары тәҗрибәсен дә үзләштерде. Шул ук вакытта Тукай иҗаты үзенең төрки тамырлары белән шәркый мөселман әдәбиятларына берегеп үскән иде. Татар әдәбиятын түбән дәрәҗәдәге әдәбият итеп күрсәтү, аның милли йөзен югалтып, интернациональләшүгә, ягъни руслашуга этәрү, ленинизм-сталинизм карашларына таянып эш иткән большевиклар сәясәтенә аеруча хуш килгәнлектән, аның бу ягы күләгәдә калдырылып торды.

Күзәтүләребездән чыгып, шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: тоталитар дәвер татар әдәбият белеме һәм тәнкыйте Габдулла Тукайның дини карашларына пролетариат диктатурасы, сыйнфыйлык күзлегеннән якын килә. Социалистик реализм эстетикасының бер принцибы булган сыйнфыйлык шагыйрь иҗатындагы дини мотивларга мөнәсәбәттә бик тә яман вульгар социологизм рәвешен ала һәм аны бәяләүдә кискен бәхәсләр, каршылыклар китереп чыгара. Үз чиратында Тукай мирасын буржуаз милек итеп карау аны дөрес аңлау һәм халыкка тәкъдим итүдә авырлыклар тудыра. Шулай булса да, алда искәртүебезчә, тоталитар дәвер тәнкыйте дә бәхәсләрдән арынып, XX гасыр башында ук әйтелгән, «Тукай – халык шагыйре» дигән бәяләмәне таный.

1941–1956 еллар аралыгында Тукай иҗатындагы дини мотивларны мөмкин кадәр әйләнеп узып, аның әсәрләрендәге Шәрык әдәбиятлары традицияләренә кимсетүле караш ташлап, социалистик реализм эстетикасы таләп иткәнчә, гомум совет әдәбиятына һәм рус әдәбияты белән бagланышларны өйрәнүгә юнәлеш ала.

**Әдәбият**


1. Ислам дине турында. Белешмә-сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр, 1978. 191 б.

2. Бурнаш Ф. Әдәбият һәм сәнгать турында. Мәкаләләр һәм рецензияләр / Кереш сүз: А. Әхмәдуллин. Ф. Бурнаш. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 137–138.

3. Магис. Сынган кылычлар һәм каргалар белән былбыллар турында // Безнең юл. 1928. № 5. Б. 18–24.

4. Мәһдиев М. Әдәбият һәм чынбарлык: XX йөз башы татар әдәбияты тарихына яңа материаллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 304 б.

5. Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы. Казан: Татар. дәүләт нәшр., 1926. 300 б.
6. Сәйфи-Казанлы Ф. Тукай әсәрләренең иҗтимагый һәм сәяси йөзе // Тукай Габдулла әсәрләре: 3 томда: 1 том. Казан, 1929. Б. I–XLII.
7. Тукай Габдулла. Әсәрләр. Академик басма: 2 томда: 1том. Казан: Татгосиздат, 1943. 472 б.
8. Тукай Габдулла. Әсәрләр: 5 томда / Г. Халит редакциясендә. Т. 1. Шигырьләр. Поэмалар (1901–1908). Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 406 б.
9. Халит Г. Халык шагыйре Тукай. Казан: Татгосиздат, 1939. 92 б.
10. Халит Г. Татар халкының бөек шагыйре // Тукай Габдулла. Шагыйрьнең тууына алтмыш ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан: Татгосиздат, 1948. Б. 6–18.
11. Хисмәтуллин Х. Тукайның рус әдәбиятыннан тәрҗемәләре // Тукай Габдулла. Шагыйрьнең тууына алтмыш ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан: Татгосиздат, 1948. Б. 130–138.
12. Шамов А. Бер кичәдә. Истәлек // Казан утлары. 1966. № 1. Б. 3–12.
13. Ярми Х. Тукай һәм халык иҗаты // Тукай Габдулла. Шагыйрьнең тууына алтмыш ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан: Татгосиздат, 1948. Б. 112–120.

*Диләрия Абдуллина,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов Тел, әдәбият сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

## ВЛЮБЛЕННЫЙ ПО УШИ ГЕРОЙ… ТУКАЯ

Тукай – это поэт, чьи любовные истории почти не были предметом обсуждений в массах, когда он жил и творил. Интимную сторону его жизни в основном знали только близкие друзья, другие лишь догадывались, но были наслышаны о том, что Тукай избегает общества женщин. Тем не менее после его смерти, да и сейчас делаются попытки придумывания, приукрашивания, гиперболизации каких-то даже не начавшихся отношений поэта. Мне кажется, что все это строится на догадках, на фантазиях нынешних литераторов. Посвящение кому-либо несколько стихов, единичные встречи, в общем-то, еще ни о чем не говорят.

Не испытавший никогда полноценные отношения, которые происходят между женщиной и мужчиной, Тукай все же писал о любви, писал он довольно много и очень классно. Художественные поиски поэта в этом направлении приводили его к различным истокам: и к народному творчеству, и к собственно художественным текстам. В итоге, Тукай в стихах на тему любви чаще всего продолжил восточные и западные традиции предшествующей

поэзии, а не фольклора. Во время характеристики тех или иных текстов все это и раскроется.

Комплексный филологический анализ художественного текста, особенно поэтического, требует от исследователя глубокого понимания языка автора. Есть особая энергетика стихов, которых сотворил талантливый человек, и ее объяснить только научными понятиями почти нереально. Энергия стиха – в общем-то, это энергия его языка, и читатель при ознакомлении текстом, должен впадать в состояние самого поэта; он должен сгореть в огне, разожженном энергией духа, переживаний; его разум должен находиться под влиянием информации, сообщенной автором. Истинный читатель многим похож на чувствующего партнера любовника – он растворяется каждой своей клеткой в фантазиях поэта. Когда читаешь Тукая, в частности его любовные стихи, вся твоя физика и физиология подчиняются призывам, смыслам и экспрессиям, которых проносят через тебя куда-то вдаль чрезмерно душевные строки.

Энергия стиха это особенная и сильная сторона поэтического текста, созданного лишь избранными, такими как Тукай, Такташ, Дердменд… Только особое чутье читателя, соответствующего уровнем мышления, художественным вкусом, кругозором этим творцам, дает возможность понимать, воспринимать, трактовать то или иное их произведение. Сегодня я не возьмусь за такое сложное дело, которое требует много времени, сил, места в издании, поэтому ограничусь структурно-функциональным анализом любовной лирики Тукая и моей целью будет раскрытие значения символических образов, деталей в передаче, в первую очередь, поэтической идеи, а в какой-то мере и душевных порывов, побуждений, переживаний.

Любое творчество основывается на эксплицитной памяти, памяти, требующей сознательной попытки вспомнить что-либо. Игры разума, иначе говоря фантазии, проникая в глубокие и в поверхностные слои памяти, возрождают те или иные события из прошлого, а их подлинная природа пробуждает наши чувства в настоящем. Иногда мы идем от обратного, переживания заставляют работать наш мозг еще сильнее и в возбужденным состоянии. Поэт начинает творить.

Всевозможные психологи пишут, что творчество не подчинено воле поэта, да и сами писатели любят говорить, что как будто

высшие силы управляют их пером. Хотя я и глубоко верующий поэт, возрожу: все эти объяснения природы творчества – конечно, чушь. Талант хотя и от Бога, но проявления его, а также дальнейшее развитие, результативность – награда Бога за наш труд, за веру, за понимание чаяний народа… Всему этому ярчайший пример – творчество Тукая. Даже борющиеся с низошедшим вдохновеньем с небес поэты понимают, что такое состояние есть результат постоянной работы, работы, в первую очередь, мозга, иногда бодрствующего слишком долго, т.е. думающего в течение беспрерывных бессонных ночей и дней...

Любовной лирике Габдуллы Тукая, получившего в свое время образование в татарских медресе, при помощи частных уроков и самостоятельно, свойственно многообразие лирических форм выражения эстетического идеала, при котором символы-образы возникают чаще всего на основе общечеловеческой культуры, Например, в стихотворении «Горе» («Кайгы»): Азазил и кинжал являются символами смерти, а в «Посиделки» («Утырышу»): ангелочек (фәрештә) – символом святости. Это и понятно, они с такой смысловой нагрузкой встречаются и в фольклоре, и во всех Духовных писаниях разных народов, и в литературе прошлого.

В стихотворении «Ты говоришь…» («Син дисең…»): месяц есть символ спелости, зрелости и красоты девушки, что особенно традиционно для восточной лирики. У Тукая общепоэтические тропы, метафоры и иные лексико-стилистические средства встречаются во всех текстах, где раскрывается тема любви. Культурные и философско-эстетические стороны его поэтических текстов являются ведущими качествами и определяют значимость художественного творчества.

У Тукая также много образов, которые возникли на основе национальной культуры: «Влюбленный» («Гашыйк»): намаз – символ поклонения; а в «Покаяние и мольба о прощении» («Тәүбә вә истигъфар») образ прекрасной девушки Зулейхи означает сильную любовь и трансформирован в поэтический текст из тюркской литературы, в частности из общеизвестной поэмы Кол Гали «Сказание о Юсуфе» («Киссаи Юсуф»).

Все творчество Тукая строится на контрастах. Антитеза, то есть стилистическая фигура в форме противопоставления, у него часто заключается в резком противопоставлении понятий, образов, состояний, связанных между собой не только внутренним

смыслом, но и структурой строф, иногда даже строк, а также общей конструкцией наибольшей литературной единицы.

Многие произведения Тукая, в том числе и стихотворения о любви полностью построены на антитезе. Для его поэзии всегда характерно наличие трех видов фокусов – моментов концентраций противоречий – смыслового, интонационного, тематического в каждом стихотворении. С точки зрения отношения символов к фокусам, эти произведения весьма различны. Если в стихах «Последняя слеза» («Актык тамчы яшь», «Из турецкого» («Төрекчәдән») символы не входят в фокус, а в стихах «После» («Соңра), «Покаяние и мольба о прощении» («Тәүбә вә истигъфар») все символы входят в фокус; то в стихе «Сон» («Төш») символ входит только в один фокус или же в два в «Нет счастья» («Бәхет юк»).

Для определения свойств текстов, которые относятся к интимной лирике поэта, проанализируем стихотворение «После расставания» («Аерылышу соңында»). Говорят, что текст обладает двойственной природой, состоянием покоя и движения. Для поэзии Тукая это очень свойственно. В нижеследующей цитате если первая строка описывает занятия лирического героя, приносящие покой его душе, то вторая опять его возбуждает, напоминанием о причине данного явления:

Бик һәвәсләндем шигырьгә күңелем, җаным белән,
Чөнки аерылыштым мин җаным-җанашым белән.

(Всей душой очень пристрастился к стихам,
Потому что расстался с моей душой-душенькой.)

Поэтический текст формирует в сознании читателя картину мира автора и проецирует его переживания на других языковыми средствами. Что примечательно, в переводе, тем более когда он дословный, воздействия строк на читателя совершенно иные, как будто это уже другой художественный продукт. В дальнейшем состояние покоя и движения опять следуют одно за другим, но уже более объемно:

Ул гүзәлгә гыйшкымны сөйләүне чын йөрәгемнән
Кайгылы күңелем белән юлдашым иткән идем.
Ярым ятларга яр булгач,тар-мар килде бәгърем;
Шуңар инде канлы күз-яшь белән яздым шигырем.

(Чистосердечное рассказывание о своей любви той прекраснейшей
Опечаленная душа избрала себе в путники.
Душа разгромлена тем, что любимая стала возлюбленной чужих,
Вот почему свой стих написал кровавыми слезами.)

Как вы видите, мы начали делить цельный текст на такие структурные части, которые нас постоянно возвращают к услышанной информации первой строфы. Начальная строфа стиха является его вступительной частью. Именно в ней дается тематическое противоречие, и оно в дальнейшем по-разному варьируется. Например:

Син җылатып безне, бер явызга киттең, и явыз!–
Гүзәллегең – күз нурың астында яшәр көндә без.

(О злодейка! Ты ушла к злодею, заставив нас расплакаться
В день, когда нам бы жить под светом твоих очей – красоты твоей.)

Каждому произведению присущи общие принципы композиции. В стихотворении «После расставания» тематическое противоречие, сливаясь с новым текстом, развивает мысль все шире и шире, тем оно протягивает нить к смысловому фокусу. В дальнейшем тема дается в моральном плане: нарушаются этические нормы человеческих отношений.

Читателю дается понять, что не только разлука подружила лирического я, прототипом которого является сам автор, с поэзией, а печаль, которая сопутствовала ему всегда, которая присуща ему изначально – от природы. Измена любимой – лишь повод для прорыва чувств наружу.

С одной стороны – любовь, с другой – его отсутствие, преданность, чему ответила девушка изменой… и горче всего – ушла к недругам… Все это приводит поэта к философским противоречиям: когда жизнь показывает свое истинное лицо, надежды разрушаются.

Поэтическое содержание следующей части говорит о том, что любовь все-таки – вдохновляющая сила. С ее потерей человек теряет все: настоящее и будущее, земное и неземное, почву под ногами и высоту полета души. Дальше тематическое противоречие переходит в социальное: лирический герой повествование ведет от имени своих сторонников. Говорит, что из-за предательского поступка девушки, «они» осмеяны врагами. Тематическое проти-

воречие из социального пласта заново переходит в психологический инвариант.

Это стихотворение ярко доказывает, что именно в момент вершины психологической поэтической мысли, Тукай обращается к символам. На первый взгляд небо-земля (күк-җир), этот мир-иной мир (дөнья-ахирәт) кажутся параллелизмами, но это не совсем так. Күк – мечта поэта, җир – опора осуществления этой мечты. Они разрушены, т.е. не осталось почвы под ногами, почвы всего сегодняшнего и будущего, символами которых являются дөнья-ахирәт. Сложнейшие ассоциации возникают посредством этих знаков. Они для поэта так тесно связаны с именем возлюбленной, что почти сливаются в одно понятие. Любимая – это идеал – гурия; вместе с тем она – и настоящее, земное. Всем известно, что эти два понятия в литературе являются и самостоятельными символами, используемыми для передачи контрастных явлений мироздания, окружающего мира, состояния героя.

Любовь должна быть святой, безгрешной – это и есть эстетический идеал Тукая, но он находит земное воплощение небесной девы или, иначе говоря, поэт любит в земном неземное. Заметить это помогает и основное значение слов жир-күк, дөнья-ахирәт, которые в этом случае передают только добавочный смысл. Идею такого идеала можно встретить также и в других стихах Тукая, т.к. она присуща почти всей любовной лирике романтической литературы, особенно характерно для традиционной восточной поэзии на тему любви.

Чистота чувств, возвышение земной девушки до небес, чуткое к ней отношение даже после разлуки, сдержанность в переживаниях трагического, любви обусловлено и национальной основой эстетического идеала. Поэт труднее переживает не отвержение со стороны любимой, а ее измену, что, по его мнению, аморально и грешно. Посмотрим последнюю структурную часть анализируемого стихотворения:

Җан яндыргыч кыйланышыңа бары тик сокланам,
Синең хәсрәтле аһыңнан һәрвакыт ләззәт алам.
Сер дөньяга фаш була дип, исемең телгә алмадым,
Менә шулай атсыз гына шигырьне тәмамладым.

(Восхищаюсь твоему поведению, которое сжигает душу,
Мне в удовольствие твои горестные переживания (аһания).

Чтобы на раскрыть секрет миру, не упомянул я твое имя,
Вот так безыменно и заканчиваю стих).

На первый взгляд, читателя удивляет этот явно одобрительный возглас автора от имени лирического я, противоречащий всему сказанному впереди. На самом деле это – лишь попытка словесного возмездия. Не верится тому, что лирический герой радуется печальной истории своей когда-то любимой женщины. Он неспособен даже при таких выражениях скрыть силу своих переживаний, также неспособен и хотя бы в какой-то мере отомстить.

Итак, мы выделили в композиции две основные части, между которыми крайняя точка смысловых и психологических противоречий, где говорится о чувстве, отвергнутом разумом и признанном сердцем.

Основными средствами воссоздания художественной картины мира, как мы видим, являются культурные, эстетические, этические, в целом – духовные смыслы единиц стихотворного текста. В любом тексте, а в поэтическом особенно, играют большую роль языковые доминанты. В данном стихе их несколько. Хочется выделить видоизмененный повтор о том, что возлюбленная героя ушла в чужим, к врагам, к недоброжелателям, поэтому это не простое расставание. Константы возлюбленная, стихотворчество, вдохновение, уход, печаль, предательство, горе, огонь, разрушенные небо и земля, потеря земного и неземного, поведение-игра… это базовые единицы картины мира. Следуя за ними, можно проследить за душевными переживаниями героя, понять суть, развитие, разрешение конфликта.

Следующее общеизвестное и яркое стихотворение Тукая на тему любви – «Не будь тебя!». Оно является философскими размышлениями поэта о мире, жизни с любимой, которые находятся в смысловом противоречии, интонационном контрасте с темой, выраженной в заглавии, смысл которого можно принять как опасения поэта, как глубокий трагизм его души. Жаль, что перевод портит лингвистическую природу стиха, то есть фоносемантический текстовой смысл, красоту поэтического звучания.

Привлекает внимание яркий контраст в эмоциональном звучании названия и основного содержания «Не будь тебя!». Поэтический ритм, возрастающийся накал данного произведения показывает общие принципы, приемы функционирования фонетических

единиц. Скажем, в начальных строфах ярко выраженный и часто повторяющийся, особо привлекательный звук это – звук м, а в целом звонкие согласные:

И матур! Мин янмас идем – яндыручы булмасаң;
Таммас иде җиргә яшьләр – тамдыручы булмасаң!

О красавица! Не горел бы я – если б ты не спалила; не капали бы слезы наземь, если бы ты не заставляла, говорит лирический герой. Он не ноет, он счастлив этим состоянием. Но дальше, взрывные звуки т, р, ш, к, которые актуализируются наряду с другими глухими согласными от строки к строке, все больше занимая доминирующие позиции, способны разрушить идиллическое состояние его души:

Дулкынланмас, болганмас та иде гыйшкың диңгезе,–
Көчле җил төсле, әгәр син болгандыручы булмасаң!
/…/
Кыргыйлыкны ташлар идем, мине үзеңә тартып,–
Җир йөзендә бөтен нәрсәгә каршы куймасаң!

В этом стихе, в том числе и в вышеприведенных строфах, лирический я причиной всего, что с ним связано, называет возлюбленную. Из-за нее он противостоит этому миру как одичалый, неуравновешен…

Звукоассоциативный ряд в этом стихе, как видим, охватывает, в первую очередь, рифму, а потом строфу и целый текст. Повторяющийся в составе рифмы слово «булмасаң» – это веха смыслового шифра, который как раз и выражает глубокий трагизм еще не случившегося. Только историческая память о временных ограничениях земного бытия дают нам предчувствовать неизбежную потерю. А пока… возлюбленная, вдохновляющая на все прекрасное, рядом.

Звукосмысловой ряд «яндыручы, тамдыручы, моңландыручы» и т.д. тоже охватывает весь текст и входит в рифмопарадигму, из-за чего усиливается их звучание от начала до конца. В любовной лирике Тукая часто встречаются и лексические, и синтаксические повторы, а строфические не свойственны. К слову сказать, строфические повторы присущи фольклору, например, песенным текстам и более популярны в татарской художественной литературе позднего периода. Кроме звукосмыслового ряда, у Тукая мы

часто наблюдаем повтор композиционных приемов. Строфы данного стихотворения по структуре тоже очень схожи.

В стихотворении «Не будь тебя!» поэт описывает мир с возлюбленной, а читатель наряду с ним, представляет и мир без нее. Мир без любимой пуст, неярок, веет от него холодом, бездействием. Мир с возлюбленной духовно обновляет нашего героя, потому что она не только подобна солнцу, месяцу – символам и внутренней и внешней красоты, – ее облик затемняет или даже полностью покрывает их:

Юаныр идем бераз кояшка я айга карап,–
Матурлыгың белән аларны каплаучы булмасаң!

Возлюбленная поэта – совершенство, идеал женщины, идеал вообще, т.е. Человека с заглавной буквы. В следующей строфе поэт образ ветра использовал в традиционном его значении символа действия:

Дулкынланмас, болганмас та иде гыйшкым диңгезе,–
Көчле җил төсле әгәр син болгандыручы булмасаң!

По мнению Тукая, в море любви взбунтовавшее сердце подобно ветру – оно вызывает героя к проявлению себя или же помогает осознать окружающую среду:

Дәрвиштәй, Аллага чын күңелемнән кол булыр идем,–
Тәшвиш белән күңелемне аздыручы булмасаң!

Оно заставляет героя познать себя:

Хәсрәтемнән кайвакыт үз-үземә кул сузмас идем,–
Үземне-үземә дошманландыручы булмасаң!

Для «лирического я» идеал любви это – тот, кто делится не только чувствами, но и знанием, культурой, всем, что имеет сам. И он в восторге, в упоении от любимой. Мир его наполнен ею целиком. Мы не видим конкретной возлюбленной, недаром поэт не назвал ее именем. Ведь здесь чувства лирического героя – общечеловеческое.

Последняя строфа стихотворения содержит в себе глубокое противоречие: поэт неожиданно объявляет, что не удался ему этот стих – гимн любимой, между тем, как мы видим, автор весьма

оригинален, а муза его прекраснейшая и прекрасных. Заключительная часть «Не будь тебя!» находится в смысловом единстве со всей предыдущей частью. Такая композиция, структура у Тукая – не единичный случай.

В этом стихотворении наиболее яркие образы это: дервиш – символ отрешенности от мира, Меджнун – символ сильной любви. Поэт использует их при противопоставлении любви обывательщине, мещанству, прозе жизни. А если рассмотреть любовную лирику Тукая целиком, то в позициях фокуса ярко выраженных символов очень мало, за исключением традиционных восточных. Например, огонь и бабочка (ут, күбәләк) – символы сильной любви; и данные образы способны даже на гибель из-за сильных, а может быть неразделенных чувств.

Среди таких символов встречаются такие пары как роза и цветочный сад в раю – символы счастья; арслан – символ бесстрашия, аждага – символ зла, перешедшие в поэзию Тукая из национальной и восточной мифологии. В данном же случае мы можем говорить лишь о символических деталях. Символы же имеются в других структурных частях и имеют функцию более глубоко раскрыть внутреннее состояние лирического героя.

Функция символических деталей и символов, в целом, заключается в том, чтобы подчеркнуть силу и красоту любви как прекраснейшего общечеловеческого чувства. Особенно сильное выражение этой идеи видно в стихотворении «Татарским девушкам» («Татар кызларына»). В этом синтетического характера произведении образ любви входит в противоречие с социальной действительностью. Формы любовной лирики Тукая – это газель, китга, касыда и традиционная песенная форма иногда синтезируются с сатирическими. Например, «Твоя рука» («Кулың») – сатирическая касыда, легкий юмор слышится и в стихотворении «Посиделки» («Утырышу»).

Любовная лирика Тукая отличается еще возвышением образа любимой до символического значения самой любви, она – центральная фигура и редко не уступает место даже самому лирическому я. Поэт своими стихами стремится рассказать не только о волновавших его чувствах, но и об их причине, доказать свое право на эти эмоции, различные приливы души. Иначе говоря, Возлюбленная – это песня, рожденная самим поэтом:

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы?!

/…/
Тешләреңнен гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре, – әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?!

Чуть ниже приведу подстрочник первой строфы, а дальше очень неудачный перевод Вс. Рождественского, где полностью отсутствует интонация Тукая, даже смысл отчасти не свопадает со смыслом оригинала. Это и понятно: стихов талантливых поэтов адекватно перевести невозможно, все равно что-то теряется. Например, стихотворение «Мәхәббәт» («Любовь») передает множества оттенков переживаний и чувств, где основная интонация раскрывает гордость поэта за свой стих, творчество, талант; умиление своей же тайной любовью, упрятанными муками и т.п. А у Рождественского стих слишком торжественный, декламативный, полуподростковый…

Земля не помолодеет (позеленеет), цветок не распустится – пока не капнет дождь; / Откуда возьмет поэт стих, если нет у него музы, – пишет Тукай. А теперь прочтем в переводе на русский целый текст:

Не бывать цветам и травам, если дождик не пойдет.
Что ж поэту делать, если вдохновенье не придет?
Всем известно, что, знакомы с этой истиной простой,
Байрон, Лермонтов и Пушкин вдохновлялись красотой.
От зубов твоих слепящих я стихи свои зажег.
Разве жемчугу морскому уступает жемчуг строк?
Ведь пока не искромсает сердца нам любви клинок,
Что такое наше сердце? – Просто мускулов комок.
Всех сородичей-поэтов я оставлю позади.
Бич любви, свисти нещадно и вперед меня веди!
Я б от царства отказался. Что мне толку в царстве том?
Чем над миром быть владыкой, лучше стать любви рабом.
О, как сладки муки эти, муки тайного огня!
Есть ли кто-нибудь на свете понимающий меня?
Нет! Со мной из всех влюбленных не сравнится ни один.
Я люблю стократ сильнее, чем Фархад любил Ширин.

В стихотворении «Любовь» поэт реализует антитезу неприятия внешнего мира вообще, если там нет места любви и приятия той жизни, где Женщина на пъедестале, любима, играет роль музы. Мы видим то, что позиция лирического я в этом стихотворении активна, он уже не выбирает путь мщения, злорадствования,

не довольствуется отрицанием действий возлюбленной и своих недругов. Здесь герой не объясняет свои чувства рационалистически, он не любит за что-то, а просто влюблен по уши как Поэт. Значит любовный идеал Тукая – Муза, способная вдохновлять на лучшие порывы души, на высокие чувства и отношения.

Поэт может любить, он должен любить! Он любит!!! Но любовь у него особая, не просто привязанность к другому человеку или чувство глубокой симпатии к противоположному полу. Любовь у него хотя бы чуть больше, чуть глубже, чуть шире, чем у обыкновенного человека. Она у него выступает не только субъективным индикатором счастья, как объясняют это понятие многочисленные словари, но и несчастья, индикатор всего трагического в нем. Тем более у Тукая, который воспринимает возлюбленную как единицу своего обделенного судьбой народа. Чем ярче у него ненависть недругам нации, тем нежнее чувства к женщине.

Любовь Тукая разная. Мне кажется, она более даёт, чем получает и поэтому иногда похожа на попечение. Чаще всего она как стихийная сила романтического влечения. Поэт размышляет как Платон: влюбленный человек земной мир связывает с божественным, считает, что красота рождает прекрасное. Чувства у него в непрерывном движении, сам он в процессе познания закономерностей межполовых отношений. Порою, в противовес к этому, он начинает философствовать как Аристотель, считая что женщина должна быть не только любимой, но и другом, сподвижником.

Тукай. Любимый миллионами поэт. Влюбивший в себя сотни интереснейших женщин своего времени. Любящий и скрывающий свои чувств юноша, не взрослый мужчина, – таковым он мне представляется. Сразу приходят на ум его слова:

Вот такова и моя любовь:
Сердце к любимой всё тянется вновь,
Грежу красавицей наяву,
В сновидениях стоном зову,
Жить без нее, друзья, не могу,
Но только увижу, как заяц бегу.
Встречусь случайно, зажмурю глаза,
Словно меня опалила гроза;
Стихи напишу о лучах этих бус,
А подписать этот стих боюсь...

(отрывок из перевода И. Сельвинского)

Стихи поэта говорят о том, что он мог бы показать миру прекрасные отношения. Но... Когда много любви в стихах, как обычно, мало бывает ее в жизни! Реальная любовь – удел немногих, мне кажется, как не парадоксально, очень расчетливых людей. Они без ошибок вычислять тех, кого можно любить. Кстати, в одном из стихотворений Тукай тоже говорит об этом. Найти любовь легче, чем сохранить. Тукай мне кажется нашел свою настоящую любовь. Это любовь к нации, которую ничто не заменит. А самые трогательные строфы недолюбленного Тукая к женщине это – строки, посвященные матери, которую он потерял совсем рано:

… Озарившая улыбкой мой начальный путь земной,
мне отрадой ты не стала, скоро с миром разлучась.

Умерев в рыданьях, мама, не осталась ты со мной,
в мир чужого всем ребенка приведя в недобрый час.

Ты одна и утешала — ласки я не знал другой;
страж любви меня жестоко отовсюду гнал, сердясь,

И на твой могильный камень, что теплей души любой,
Боль моя слезой горчайшей и сладчайшей пролилась.
(«Утраченная надежда», пер. Р. Бухараева)

*Рифа Рахман,*
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Центра письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

## ЕРАК СЕБЕРДӘ ТУКАЙ ИҖАТЫ

Билгеле булганча, бөек Тукаебызның тавышы, матбугатта басылган әсәрләре чыккан көне белән үк халык күңелен җәлеп итә, аның авазы Россиянең татарлар яшәгән барлык почмакларында да яңгырый, ишетелә. Чөнки аның язганнары халкыбызның рухына, тормышына муафыйк, якын, иҗаты татар әдәбиятының киләчәге, тәрәккыйсы хакында өметләр тудыра. Халыкчан, җанлы шигырьләре татарның гасырлар буе тутыккан күңелләрен ялтырата, яктырта. Шуңа да ул бик тиз арада үзен милләтенә таныта. Бу хакта мәгълүматлар вакытлы матбугатта да чагылыш тапкан, күпсанлы замандашларының хатирәләрендә, истәлек язмаларында да әйтелгән. Шундый чордашларыннан Ерак Себердә (Ачинск, Чита, Иркутск, Благовещенск, Хабаровск һ.б. шәһәрләрдә) эшләгән, мөгаллим,

педагог, журналист һәм, ниһаять, мәгърифәтче Ризван Алуши һәм аның җәмәгате Фәрханә Алушилар да бар. Сүз алар турында, аларның шагыйрьгә, аның иҗатына мөнәсәбәтләре турында барачак.

Ризван Алуши (Ибраһимов Ризван) (1883–1938), Саратов губернасы Биги авылында (хәзерге Пенза өлкәсе, Неверкин районы) туа. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала (1896–1904). Казанның алдынгы шәкертләреннән, шәкертләрне берләштерү, мәдрәсәләрдә укытуны яңарту максаты белән төзелгән «Әлислах» комитететының Себер шәһәрләрендәге мөгаллимнәр, мәдрәсәләр белән элемтә урнаштыручы сыйфатында Себергә укытучы булып китә. Ачинск (1905–1907), Чита (1907–1912), Хабаровск (1912–1914), Чиләбе (1915–1917) шәһәрләрендә мәдрәсәләрдә укыта. Укытуында яңа ысуллар-методлар файдалана. Ачинск шәһәрендә хатын-кызлар мәктәбе ача, кызлар белән малайларны бергә укыта башлый. Р. Алуши 1906 елдан башлап татар матбугатында мәкаләләр, хикәяләр белән катнаша. «Фикер», «Казан мөхбире», «Сибирия», «Вакыт» газеталарында, «Шура» журналында Себер татарлары, мөселман уку йортларының торышы, укытучыларның тормыш шартлары турында мәкаләләре басыла. Себердә эшләгән чорда дөнья күргән күп санлы мәкаләләрен эчтәлек ягыннан икегә бүлеп карарга була. «Сибириягә даир» (1906), «Сибирия нә халәттә» (1906), «Сибирия тәэссирате» (1915) кебек мәкаләләрендә ул Себер тарихы, аның Россиягә кушылуы, табигый байлыклары, Себердә яшәүче татарларның этник үзенчәлеге, көнкүреше турында яза. Икенче төр мәкаләләрендә: «Сибириядә ир вә кыз балалар бергә укый торган мәктәпләр» (1912), «Мәктәптә тәрбияи бәдәния илә тәрбияи рухания» (1911) һ.б. ул мәгариф, уку-укыту методикасы, тәрбия мәсьәләләрен күтәреп чыга.

Фәрханә Алуши (Фәрханә Рәхимгәрәй кызы Бәхетгузина) (1886–1958) Себердәге Ачинск шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туа, заманы өчен киң кырлы белем ала һәм соңыннан үзе дә бөтен гомерен укыту-тәрбия эшенә багышлый. 1906 елда Фәрханә Фатих Әмирханның якын дусты, фикердәше, Ачинскидагы татар мәктәбендә укытучы булып эшләүче Ризван Алушига кияүгә чыга. Шуннан соң алар, кулга кул тотышып, инкыйлабка кадәр Себернең төрле шәһәрләрендә (Ачинск, Чита, Хабаровск һ.б.), ә соңыннан Чиләбедә һәм Уфада мөгаллимлек эшләрен дәвам иттерәләр.

Татар вакытлы матбугаты барлыкка килгәч, Фәрханә һәм Ризван Алушилар икесе дә, кулларына каләм алып, актив рәвештә

газета-журналларга язышалар. 1906 елгы «Фикер» газетасының (Уральск) 14 нче һәм 31 нче июль саннарында Фәрханә Алушиның «Сибирия хатыннарының тавышы» исемле шактый күләмле публицистик мәкаләсе басылып чыга. Бу басмада Г. Тукай актив хезмәт куйган һәм әлбәттә, Ф. Алушиның мәкаләсе аның кулы аша үткән. Ф. Алуши Казанда чыга торган газеталарда да (мәсәлән, «Бәянелхак»та) мәкаләләре һәм нәсерләре белән еш катнаша.

Публицистик мәкаләләрендә Ф. Алуши татар мәгарифен яңача үстерү, мәктәпләр хәле, хатын-кыз азатлыгы кебек актуаль мәсьәләләрне күтәрә һәм аларның һәрберсе хакында үзенең кыю фикерен әйтә.

Ризван һәм Фәрханә Алушиларның педагогик һәм мәгърифәтчелек эшчәнлекләрен таныган, зурлаган язмалар шул чорда «Сибирия» газетасында [Биккулов, 1913; Мөһибуллин, 1913] яктыртыла. Мәсәлән, «Себер мөгаллиме Ризван әфәнденең юбилее мөнәсәбәте илә» дигән мәкаләдә: «1907 елда, август урталарында Ризван әфәнделәр Читага килделәр. Шул көннән башлап Ризван әфәнде мәктәп балаларына белем-тәрбия бирү белән бәрабәр, мәктәп тышында да халык арасында гыйлем таратырга тырышалар иде. Килгән елны ук Ризван әфәнде иҗтиһады илә мәктәп янында китапханә дә ачылды. Китапханәгә яше-карты ябырылып йөри башладылар. Милли әдәбият белән мәшгуль булдылар. Күбесе газета-журнал яздырып ала, өйләренә алып та китап укый башладылар, үзе укый белмәгәне кеше укыганны тыңлап тора иделәр. Янә дә Читада хатын-кызларның күзен ачучы, аларның кеше төсле дөньяга чыгып йөри башлауларына Ризван әфәнде илә рәфикасы – мөгаллимә Фәрханә ханым сәбәп булдылар. Үзләрен ирләр кәефе өчен генә яратылган дип уйлаган, өйдә тоткынлыкта саргаеп ята торган абыстайлар да бераз уяндылар. Үз кирәкләрен кайгырта башладылар.

Фәрханә ханым исә хатыннарны җыеп укытты. Өйдә генә ябылып яту ярамаганлыгын, дөньяга чыгып, ирләренә булышлык кылу кирәк икәнлеген аңлатты» [Мөһибуллин, 1913] – дигән юллар белән очрашабыз. Әлбәттә, бу эшләр аларга җиңел бирелми, адым саен киртәләр дә булып тора.

Р. Алуши Казанда «Мөхәммәдия»дә укыган елларында Ф. Әмирхан белән сабакташ дуслар булалар һәм бу дуслык гомерләренең азагынача дәвам итә. Алар арасында туктаусыз хатлар алышу, бик еш булмаса да очрашулар булып торган. Читтә йөргән дусларына хат язганда Ф. Әмирханның Г.Тукай турында әледән-

әле хәбәр биреп торуы мәгълүм. Р. Алушиның Ф. Әмирхан аркылы Г. Тукай белән дә очрашкан, танышкан булуы да ихтимал. Һәрхәлдә, үзе дә матбугатта катнашып яшәгән Р. Алуши Г. Тукайның иҗаты белән даими таныш булган. Ф. Әмирхан аңа Казанда чыккан «Әлислах» (1907–1909) газетасын Себер шәһәрләрендә тарату өчен күпләп җибәреп торган. Шул рәвешле Алуши Г. Тукайның матбугатта дөнья күргән әсәрләрен Себер халкы арасында тарата. Тукай иҗатын мәктәп балаларына өйрәтә, милли тәрбияне Тукай әсәрләренә таянып алып бара. Үзе оештырган китапханәләрдә аның әсәрләрен булдыра.

Г. Тукайның үлемен Ризван Алуши авыр кичерә. «Сибирия» газетасының 1913 елгы 15 май санында «Габдулла әфәнде Тукаев» дигән мәкалә язып бастыра. Биредә ул шагыйрьне гасырлар буе торгынлыкта изелеп яшәгән татар милләтенең күзен ачучы, киләчәккә өметен уятучы, рухын күтәрүче, Аллаһ тарафыннан җибәрелгән даһи, олуг зат дип бәяли.

Тукай иҗатының асылын ассызыклап, халык күңеленә якынлыгының сәбәпләренә туктала: «Ул татар милләте арасында җитлеккәнгә күрә, аларга нинди сүз әйтергә кирәк икәнен белгәнгә, ачы хәсрәтле шигырьләре милләтне уятты, моңлы шигырьләре илә кальбемезнең иң нечкә кылларына тәэсир итте. Җәһаләт йокысына талган, изелеп, рухы зәгыйфьләнгән татар милләтенә яктылык, нур сибеп күзен ачты, алга барыр дөрес юлны тәгаенләде» [Ибраһимов, 1913], – ди.

Халыкның Тукайга мөнәсәбәтен, сөекле шагыйрьне югалтуның ачысын, фаҗигасен гомумиләштереп чагылдыра: «Рухыбызга тәэсир итә торган моңлы музыкабыздан бер кылы өзелде... ачы хәсрәтебезне җырлый-сайрый торган бер былбылыбыз очты ... Менә ул даһи, менә ул нур – инде бездән китте – Габдулла әфәнде Тукаев үлде! Шуның илә яшь татар әдәбиятының нигезеннән иң кирәкле бер терәге ауды – дип, Тукай иҗатының әһәмиятен, татар әдәбиятындагы урынын югары бәяли. – Аның үлеме бөтен милләтнең калебен сызлатты. Чөнки ул бик аз яктырды, бик аз сайрады. Ләкин шулай да хәзер инде һичбер күздән аның нуры бетәчәк түгел, һичбер татар күңеленнән аның татлы шигырьләренең тәме китмәс. Ул үлде, ләкин милләтне кабат йокламаслык итеп уятып үлде» [Ибраһимов, 1913], – дип яза.

Шагыйрь үлеменә бер ел тулганда Р. Алуши «Тормыш» газетасында күләмле мәкалә [Ибраһимов, 1914] бастыра. Биредә ул

Тукай иҗатының Себердә дә киң таралышын, төрле катлам халык арасында яратып кабул ителүен дәлилли. Бу иҗатның мәңге актуальлеген, халыкка һәрвакыт кадерле булачагын моннан 100 ел элек үк күрә алган һәм шулай буласына чын күңелдән инанган.

Менә ул мәкаләдән өзек:

«Сибир элек татарлар каршында каторга урыны, җинаятьчеләр оясы булып аңлана иде. Татарлар өчен ул бик куркыныч булып күренә иде ... Заманнар кичте, даһили Русиядә инкыйлаб булып үтте (1905). Шуның нәтиҗәсе буларак, мәдрәсәләрдә егермешәр ел яткан шәкертләр күзләрен ачтылар, муллалыктан башка кәсеп эзләп төрле җирләргә таралдылар; менә шулардан бер төркеме, батырраклары, салкын Сибирдән өркеп тормыйча, шәрекъка таба юл ачтылар. Тиз арада Сибириянең төрле тарафына тулдылар. Менә шул тарихта Сибириядә укыган сыйныф барлыкка килде. Алар белән бергә Сибиргә татар әдәбияты да күчте. Хәзер Сибириянең күп җирләрендә татарча сөйләшүче вә татар мәктәбе очратырга була. Аз булса да газета-журнал вә төрле китаплар да Сибиргә килеп тора. Шул аз вә акрын таралган әдәбиятыбыздан мәрхүм шагыйребез Габдулла әфәнде Тукаевның әсәрләре иң күп урын алган вә иң күп вә иң яратылып укылдылар. Сүзләрем дәлилсез, коры рия өчен генә булмасын өчен берничә мисал вә фактлар илә дә күрсәтәм:

1912 елның май аенда Иркутскиның Лотфый әфәнде Исхаков илә Русиягә карап бара идек. Күңелле берәр нәрсә очрамасмы дип 3нче класс вагоннарына чыгып йөргәндә бер төркем узелчеләрнең (вак-төяк белән сәүдә итүчеләр) иң сөекле эше булган «карта» уеннарын ташлап, бик ихлас белән бер татарның нәрсәдер укыганын тыңлап баруларын күреп, яннарына туктадык. Укыган китаплары «Әлгасрелҗәдид» журналы иде. Шунда, тәмләп-тәмләп, Габдулла әфәнденең «Мөридләр каберстанынннан бер аваз» дигән шигырьләрен укыйлар иде. Шуннан соң, агайлар, тагы берничә номер журнал күрсәтеп, һәр кайсысыннан Тукай шигырьләрен яратып укыганнарын белдерделәр. Бу – 1906 ел иде – димәк, тиңсез шагыйребезнең тавышы, шигырьләре чыккан көне илә ерак Сибиргә кадәр ишетелде, яңгырады.

Читада торган чагыбызда, әдәбият сөюче яшьләр яңа чыккан китап вә рисаләләрне минем аша алдыра иделәр. Шунда иң күп сораган нәрсәләре Тукай шигырьләре була иде. Читаның картлары-яшьләре, ханым вә туташлары Габдулла әфәндене сөяләр, яра-

тып укыйлар. Шигырь мәҗмугалары чыкканын түземсезләнеп көтәләр иде.

1912 елның яз айларын Благовещенскида үткәрдем. Шул заман татар әдәбиятын да гаять сусадым. Ләкин шунда да Габдулла әфәнденең шигырьләрен күрүгә аптырау булмады, чөнки күп кешенең йортында аның китаплары бар иде.

Шул елны Благовещенски белән Хабаровски арасында һөнәре «карта» уйнап йөрү булган бер татарга очрадым. Танышкач ук, Тукаевның «Күңел җимешләре» исемле шигырь мәҗмугасын бирде һәм үзенең Тукай шигырьләрен сөеп укуын сөйләде. Благовещенски һәм Амур буйлары елның күбрәк өлешен Урта Россиядән аерылып, киселеп торалар. Шулай булса да анда Г. Тукай шигырьләрен очрату мөмкин булуы, аның бик сөекле, яратылган булуына үзе бер дәлил булса кирәк.

Соңгы еллар бик күп яшьләргә вә ханым-туташларга очрадым, күбесе Г. Тукайның шигырьләрен күңелдән беләләр вә сөйлиләр, көйгә салып җырлыйлар.

Габдулла әфәнде язган әсәрләрендә татар рухына муафыйк, татар аңларлык өслүбтә тәгъбирләр куллану өстенә, акрын-акрын иске төшенчәләрдән татарчага күчерү сәбәпле тиз танылды вә сөекле булды.

Габдулла әфәндедән без аерылдык – ләкин вакытсыз аерылдык. Ул безгә кирәкле зат иде. Чөнки ул чын мәгънәсендә шагыйрь иде. Халык шагыйре иде... Ул илһамлы шагыйрь иде, олуг талант иде ... Әмма аның кадерле әсәрләре безнең арада, без шуларны күреп юанабыз. Ул үлде – әмма аның мөкаддәс хезмәтләре терек, шуңа да ул милләт үскәнчә үсәр – милләт яшәгәнчә яшәр диеп ышанабыз» [Ибраһимов, 1914]. Күренгәнчә, соңгы җөмләдәге шигарь рәвешендә яңгыраган сүзләр дә Ризван Алуши каләме белән язылган.

**Әдәбият**

Биккулов И. Сибириядә кечкенә генә юбилей// Сибирия. 1913. 10 март.

Ибраһимов Р. Габдулла әфәнде Тукаев// Сибирия. 1913. 15 май.

Ибраһимов Р. Сибирия татарлары каршында мәрхүм Габдулла әфәнде Тукаев // Тормыш. 1914. 2 апрель.

Мөһибуллин К. Сибир мөгаллиме Ризван әфәнденең юбилее мөнәсәбәте илә // Сибирия. 1913. 12 май.

*Әнисә Алиева,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

## ФОТОГРАФ КЫЯМ КАРЫЙ ЗӨЛФОКАРОВ ТУРЫНДА

XX гасыр башында Казанда Тукай дәверендә татар халкының мәдәни күтәрелеше төрле юнәлешләрдә күзәтелә. Әдәбият мәйданына күп талантлы язучылар, шагыйрьләр, фәлсәфәчеләр, мәгариф мәйданына талантлы педагоглар, тәрбия буенча фикер ияләре, артистлар, музыкантлар, спортчылар, табиблар, рәссамнәр, скульпторлар, картографлар, хәтта фотограф профессиясен үзләштергән кешеләр күренә башлый. Бу урында әлеге озын исемлекне искәрмәләр белән баетырга максат куймыйча, фәкать фотографиягә төшерү осталыгын үзләштергән шәхесләрнең берсенә игътибар итәрбез.

XX гасыр башында яшәгән каллиграфия сәнгате осталарыбыз арасында Кыям карый (Кыйвам карый) Камалетдин улы Зөлфокаров исеме күпләргә таныш түгел. Ләкин аның исемен белү, эшчәнлеген өйрәнү, сәнгать тарихыбызны баерак күрергә ярдәм итә.

Кыям карый Зөлфокаров 1870 елда Төгәлбәй авылында туган (хәзерге Татарстанның Әлки районында). Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган. Ул шәкерт чагыннан ук каллиграфия сәнгате белән кызыксынган. XX гасыр башында татар матбагалары тагын да киңәеп киткәч, аның сәнгатенә дә юл ачыла. К.Зөлфокаров кулы белән язылган «Мәүлед китабы», «Әмали гакыйдәсе», «Хөсне хат», «Хуш хат», «Үтәк шәҗәрәсе», шәмаилләр һ.б. басылып чыгалар.

Моннан тыш, Кыям карый фотография белән дә шөгыльләнгән. Ул бу һөнәрен халкыбызның тарихын баетуга файдалана.



Кушлавыч авылының гомуми күренеше

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукай үлгәч, К. Зөлфокаров, үзенең улы Салихны ияртеп, Казан артының Тукай белән бәйле урынnарына чыгып китә: Кушлавычта, Өчиледә, Кырлайда була. Әлеге авылларда Г. Тукайга бәйле тарихи йортларны рәсемгә төшереп калдыра. Хәзерге көнгә кадәр ул төшергән рәсемнәр Тукай тормышын өйрәнүчеләргә кыйммәтле иллюстрацияләр булып хезмәт итәләр.



Кырлай авылында Г. Тукай укыган мәктәп күренеше

Кыям карыйның тумыштан ук сәнгать нечкәлегенә, музыка нәфислегенә табигый таланты була. Бу талантын замандашлары аның «Коръән» укыганда мәкамнәргә керткән мелизмнарында ук тотып, тоеп алганнар. Шушы шәхси сыйфаты белән ул Габдулла Тукай иҗатына да килеп керә. Дөрес, шагыйрь аның мәкамнәр буенча булган талантына тискәре караган, чөнки ул мәкамнәрнең дә музыкаль профессионализм югарылыгында үзләштерүгә чикләнгән караштa торган. Хәлбүки, «Сәйяр» артистлары Кыям карыйдан бу очракта консультацияләр алган булганнар.

Кыям карыйның музыкаль мәкамнәргә сизгерлеге нәселдән килгәнлектән, аның нәселеннән оныклары композитор Мәсгут Латыйпов һәм музыкант Ләйлә Латыйпова һ.б. иҗатында да чагылмый калмаган.

Урта гасырлардан бирле мөселман төрки арасында, аны укыганда мәкамнәрнең бай мелодия формалары белән башкарыла торган «Мәүлүден-нәби» әсәре бик киң танылган булган.

Кыям карый бу әсәрнең текстын, хәттат осталыгы белән язып, ташбасма ысулы белән бастырып та чыгарган. Аның каллиграфия өлкәсендәге бу таланты, балаларга хәттатлык осталыгына өйрәтүне күз алдына тотып басылган дәреслек әсбабында һәм дә «Әлгали» китабын шулай күчереп бастырган китапларында да теркәлеп калган.

Татарның каллиграфия һәм декоратив сәнгатенең бер үзенчәлеген чагылдырган шәмаилләр иҗат итүдә дә Кыям карыйның хезмәтләре сакланган.

Лəкин бу кешенең татар тарихына калдырган мəңгелек истəлеге, югарыда əйтеп үтелгəнчə, аның шагыйрь Габдулла Тукай истəлеге белəн бəйле урыннарны фоторəсемнəргə алып калдыруында.

Сакланып калган истəлек-сурəтлəрнең тарихы хакында Габдулла Тукайның əнисе белəн бертуган Кəшфелкəбир Əмировның кызы Нурания ханым (1909 елда туган) һəм Кыям карый оныклары белəн очрашулар вакытында да ачыкландылар.

**Əдəбият**

*Əхмəтҗанов М.* Татарлардан беренче фотограф // Татарстан хəбəрлəре. 1992. 21 апрель. № 79.

*Латыпова Л.* Они в моей памяти. Казань: Изд-во Еникеевой, 2003. 86 с.

*Марсель Əхмəтҗанов,*
*филология фəннəре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, əдəбият һəм сəнгать институтының*
*Язма һəм музыкаль мирас үзəге баш фəнни хезмəткəре*

## КИНЕМАТОГРАФИЯ, ТЕЛЕВИДЕНИЕ ҺƏМ ТУКАЙ

### *Кинематография һəм Тукай*

Язманы шулай атар өчен фактик нигезлəр юк дисəк тə, шагыйрьнең иҗаты реаль тормышны чагылдырганлыктан, ə кино сəнгате чынбарлык белəн хыялны тоташтыручы күпер функциясен үтəгəнлектəн, бу өлкəдəге иҗади эш шагыйрьгə əле сүз буларак кына таныш булса да, дөньяга ул, вакыйгаларга камера аша карагандай, якынайтып караган һəм тормышны эрелəндергəн образлы эпизодларда күргəн.

Шагыйрьнең кайсы гына əсəренə тукталып карасак та, алар буенча хəрəкəтлəнүче рəсемнəр тезмəсе ясап, яисə кино төшереп булыр иде. «Кисекбаш»ны, «Шүрəле», «Су анасы»н, «Өч хакыйкать», «Кəҗə белəн сарык» əкиятен, мəсəллəрен һəм балалар өчен хикəялəрен фильм төшерү өчен əзер сценарийлар дисəк, телəсə кайсы лирик шигыре буенча да сценарий язып булыр иде, дип ышандырып əйтергə мөмкин. Мисал өчен, «Өзелгəн өмид» шигыренə генə игътибарлы караш ташлыйк: шушы кинодан бик ерак яткан бер шигыре генə дə Тукай кинематографистларча уйлаган, язган дип əйтергə хокук бирə. Моны бүген без – шагыйрьгə рəхмəтле варислары шиклəнмичə əйтə алабыз.

Шагыйрь үзе, ихтимал, «нинди кино?» дип шикләнер иде. Чөнки Тукай әсәрләрен фильм итеп күргән, күрергә теләгән, дип расларга бер документ – тәзкирә дә юк. Күзе күпне күреп, колагы күпне ишеткән шагыйрь өчен һәр язганының тиз арада укучыга ирешүе генә мөһим. Ул үз заманының иң оператив, иң елгыр, иң актив һәм иң үтемле шагыйрь булуын үзе дә тойганлыктан, җәмгыятьтәге һәр вакыйгага үз бәһасын иҗатында чагылдырып барган.

Аның күңелендәге кинематография чаткылары җемелдәвен Галиәсгар Камал (1879–1933) белән берләшеп, «Яшен» журналы чыгара башлавында күреп була.

Үзенең бу өлкәдә сәләте барлыгын сизенгәндер дияргә безнең дәлилләребез юк, әлбәттә. Бу – бер фаразлау гына.

Тукайның актив язу иҗаты 7 ел дәвам итә. Бу чорда әле кино үзе дә чын сәнгать статусында түгел. Аңа әле «хәрәкәтләнүче сурәтләр» могҗизасы, экзотика, яңа төр тамаша дип кенә карыйлар.

Рәсәйдә «кино төшерү» дигән төшенчәнең «кабынуы» Тукай «сүнә» башлаган елларга туры килә. Төшенчәсе булсын, йөресен дә ди, әмма фильм төшерү учаклары Мәскәү, Петербург, Киев кебек шәһәрләрдә генә дөрли.

Татарларда кинофильмнар төшерердәй кадрлар юклыктан түгел бу. Кинематография белгечләре татарлар арасында да булган һәм алар, милләт интересларыннан чыгып, аларны фильм итеп күрү җәһәтеннән йөреп караганнар.

Әхмәт Таҗетдин Рәхманкулов исеме астында мәгълүм драматург «Упкын», «Боз астында дулкын», «Үлмәс ханым», «Җиһан тетрәгәндә», «Килмешәк», «Сафура», «Аферист», «Тигәнәк» дип аталган берничә сценарий язып тәкъдим итә. Мәскәү осталары алмагач, кайберләрен үзбәкләргә, азәрбайҗаннарга бирә. Бер әсәрен Казах театрында да уйныйлар. «Упкын» әсәре буенча «Ленфильм» студиясе нәфис фильм төшерүне планлаштыра һәм ул 1928 елда гына «Мулланың өченче хатыны» исеме астында тамашачыларга тәкъдим дә ителә. Ләкин сценарий авторы Люсиль Сквайр, режиссеры Вильямс дип күрсәтелә (кара: Совет нәфис фильмнарның белешмә каталогы № 677).

«Узбекфильм» студиясендә «Джалилов» фамилиясе астында 1925–1928 елларда «Минарет смерти» һәм «Шакалы Ривата» фильмнарында Хәлил Әбҗәлилов төшә.

Моннан тыш «Потомок Чингисхана» фильмында татар ролендә уйнаган Валерий Инкиҗанов режиссерлыгында «Койрыклы

йолдыз» («Комета») фильмы, Иван Грозный баскакларының Казанны яулап алуы турында «Булат батыр» фильмнары төшерелә. (Татарстанда республика акчасына.) Ләкин боларның берсе дә милләт язмышын, халык тормышын, чынбарлыкны чагылдырган фильмнар түгеллеген исемнәре үк әйтеп тора. Алар экзотика эзләү, баскакларны җиңүче итеп күрсәтергә теләү «фокуслары» гына. Аларны «татар киносы» дип, шартлыча да әйтеп булмый. Төрле студияләрдә төшерелсәләр дә, кайсы еллардагы фильмны алып карасак та, татарлар миллилек эффекты бирү өчен генә катнаштырыла. Тукай мотивларының, Тукай күрергә, ишетергә теләгәннәрнең эзе дә, исе дә юк.

Сценарий авторы татар милләтеннән Роза Хөснетдинова булып, героинясын татар сәхнәсенең йолдызы Вера Минкина уйнаган фильмны да, Гариф Ахуновның «Хәзинә»се буенча Свердловск киностудиясе төшергән фильмны да (гәрчә анда татар театрының корефейлары төшсә дә), милли рухның, татар мохитенең сизелмәве, нефть исе аңкуы белән генә хәтерлисең.

Болардан тыш төшерелгән кайбер нәфис фильмнарга татар артистлары чакырылса да, бары тик төрләндерү, интернациональлек эффекты бирү өчен генә.

«Узбекфильм» студиясендә төшерелгән фильмнарда Хәлил Әбҗәлилов кебек артистларыбыз җаваплы үзәк рольләрне башкарганнар. Ул фильмнарны да татар киносы дип әйтеп булмый. Алар бары тик талантлы татар артистлары катнашы белән төшерелгән эклектика-экзотика, басмачылар-кызыллар сугышына «агитка»-иллюстрацияләр генә.

Язмабыз «Кинематография һәм Тукай» дип атала. Ә үзебез исә әллә кайдагы, әллә кайчангы, Тукай иҗатына һич катнашы булмаган фильмнарны искә төшерәбез. Ул фильмнарга Тукай әсәрләренең йогынтысы булган дип тә әйтеп булмау безне кино сәнгатенең «сабыйлыгы» чорыннан, «ир-егет» булып, сәнгать статусы алган чорына, теләгәнеңне туры Тукайча, милли мәнфәгатьләрне цензурадан курыкмыйча әйтергә рөхсәт ителгән чорга этәрә.

Ирек, хөррият, тигезлек дип, шулар турында, шуларны яклау фильмнары төшерергә кирәк дип, этәчләнүләр булып тора, киләчәктә дә булырлар. Тик алар акча сораугa гына кайтып калмасын иде.

Фильм төшерү өчен, идея өчен, фикер әйтү өчен көрәш булудан да бигрәк, коммерсия проектларының җиңүе (табыш өчен көрәш) икәнен «Болгар җилләре» мисалында ачык күренә. Әсәр

түгел, сәнгать түгел – әрсез эшмәкәр җиңә бүген көрәштә. Шулар мәйдан тота, кыйбла билгели, сайлый вә сайлана. Тукаебыз нәкъ менә шушы алым белән агым ясаучы, милләт прогрессына тышау булган катлам белән көрәшкән дә инде. Бүген кемнәр соң алар, дигәндә, һич икеләнмичә, әнә шул «милләт, милләт, азатлык» дип кычкыручы милләт хадимнәре, дияргә була.

«Азатлык» дигәндә, алар нәрсәдән азат булу кирәген күз алларына да китермиләр, кычкыру гына кирәк аларга. Шулай урталыкта булып, урталыкта калып, ике якка да хезмәт итә мондый хадимнәребез.

Бу хәл Тукайның ачуын чыгарган хәлләрнең иң куркынычы, ягъни халыкка хезмәт итәбез лозунгасы астында милләткә каршы бару.

Үзләрен кинематографистлар рәтенә бастырып, татар фильмы кирәк дип чаң сугучылар милләтебезнең һәлакәтен, аның рухы сындырылганлыгын танымыйча, үз-үзләрен дә, потенциаль тамашачыларын да ялган өметләр белән юатучылар гына түгелме? Җавап «түгел» икән – кая аларның шушы фикерне юкка чыгарырлык сценарийлары, сценарийга әверелдерү көткән проза әсәрләре? Классикамы?! Нәрсә бар соң безнең соцреализм мирасы классикада инкыйлабка мәдхиядән башка?

Татар киносы кирәклек турында сүз барганда, әлбәттә, бәйсезлек идеясен авангардка куялар. Ул идеянең хәлен чуер таш белән чагыштырып карарга кирәктер: әгәр ташны кесәдә, яки кулга тотып күп йөртсәң – ул шомара; кирәге чыгар әле, дип яшерсәң, ул мүкләнә. Шомарган таш та, мүкләнгәне дә – кирәксез. «Мөстәкыйльлек» дип күршеләрдән ишеткән сүзне телдә, сүздә әйләндерә-тулгандыра, төрләндерә торгач, «шомартып» бетерсәк тә, аның чынбарлыкта нинди булырга тиешлеген тасвирлаган әсәр бүгенгә кадәр язылганы юк һәм язылачагы да шикле... (Күпләр инде тапкан ташларын ташладылар, ул кайдадыр мүкләнеп күгәреп ятадыр.) Бәйсезлеккә омтылган нинди көчләр бар? Кемнәр алар? Безнең заманда бармы алар? Булса, кая алар? Кемнәр алар? «Юк» дияргә ашыйкмыйк. Әгәр без «юк» дигәнгә ышанабыз икән, киләчәктә аны кинофильмнар төшерү белән генә булдырып булмаячак. Бүген без татар киносы кирәк дип, чат саен тәкърарлаганда, милләтнең оешкан булуын, тәвәккәллегенә, гаделлегенә өндәп, тамашачыны милләтебезнең дөньяда, һичшиксез, үз урынын табарга тиешлегенә инандырырга тиешбез. Шул хакта язарга,

шул хакта фильмнар төшерергә тиешбез.Ул фильмның төп каһарманы, әлбәттә, безнең Тукаебыз булырга тиеш! (Тукай булмаса – Тукайчы!) Чөнки Тукай иҗатында дөньяда милләтнең үзенә лаек урыны булырга тиешлекне даулаган әдипләрнең иң якыны, иң үтемлесе. Чөнки ул иң элек һәркем үз урынын табарга һәм шул урынның чын хуҗасы булып, аны сакларга тиешлекне дә әйткән... Бу безнең милләт өчен бик мөһим өндәү.

...Әлегә без үз йортыбызда сыңар аякта гына басып торабыз.

...Коммунизмга барабыз дип яши-яши, без һаман шулай «коммуналка»да яшәп ятабыз. Иң кызыгы, «мөстәкыйльлектә яшибез, мөстәкыйльлекне саклыйк!» дибез. Кызык, юкны ничек саклап була икән? Әллә бәйсезлек идеясен саклау авыр булып, аны «кикладыкмы»? Шомарган яки мүкләнгән таш кына түгелме ул идея? Бу сорауларга җавапны фильмда Тукай авызыннан ишетү, шиксез, һәр татар өчен кызык та, мөһим дә булыр иде. Татар өчен генә түгел. Бу эш безнең татар әдипләренең милләт каршындагы фаразыдыр.

Ерак узганнарга чигенмичә, соңгы елларда иҗат ителгән кинофильмнарга мөрәҗәгать итсәк, Тукайга бәйле, Тукай исеме кергәннәренә генә туктала алабыз. Темабыз шуны сорый.

Андый фильмнардан иң саллысы һәм «Тукай турында төшерелгән беренче тулы метражлы фильм» статусын дәгъвалаучы Рабит Батулла сценарие буенча төшерелгән «Күк капусы ачылганда» фильмыдыр. Абруйлы әдип, күп пьесалар авторы, үзе дә профессиональ режиссерның шагыйрь шәхесе белән рухланып язган бу әсәре, даһиебызның кыска иҗат юлында булган яки булуы ихтимал эпизодлар фаразлауга корылган. Сценарист шагыйрьнең тормыш эпизодларына үзенчә карап, үзенчә күреп, үзенчә шәрехли, үзенчә яза. Кинорежиссерның эше кабатланмас, бердәнбер булуы белән аерылып тора. Аның эш коралы да, материалы да – персонажлар бәрелеше. Персонажлар мөгамәләсенең символик эпизодлары аша кино режиссеры үз сәнгатен тудыра. Тәкъдим ителгән фильмның персонажлары Тукай белән бәхәскә кererлек тарихи-социаль, әдәбият-сәнгать кондициясендә кебек, шагыйрь образын тудырырга тиеш персонаж та авторның хыялы тудырган безнең чор артисты.

Ул нинди җаваплы эшкә алынуын аңлый, икеләнә, эзләнә, эшли. Нәтиҗәдә, ышандыруга ирешәме соң? Тамашачы төрле холыклы, төрле таләпле кешеләрдән тора бит – ышанганы бар, ышанмаганы.

Фильм турында «Мәдәни җомга» газетасының 2012 ел 14 сентябрь санында чыккан мәкаләсендә рецензия авторы «ышандырмады», ди. Билгеле булуынча, фильмның конструкциясе каһарманнар күплеге һәм төрлелеге белән түгел, ә шәхес-персонажларның рухи көчлелеге белән төзелә һәм ныклы була. (Йомшак материал белән каты нәрсә эшләп булмый.) Бу фильм, нинди булуына карамастан, Тукай турындагы беренче нәфис фильм буларак, яшәргә, каралырга тиеш.

Шагыйрь исемен кертеп, аңа багышлап, аның әсәрләрен һәм исемен катнаштырып төшерелгән документаль һәм музыкаль фильмнарны Татарстан тамашачысы күп күрде һәм күрер. Әмма алар арасында кино сәнгатенә кертер кондициясендәгеләре бик аз.

Шул азчылыкка кинодраматург Риорита Рубцова белән берлектә Виктор Беспалов төшергән «Кырлай» документаль-музыкаль фильмын кертергә була.

«Кырлай» фильмы өчен режиссер В.И Беспалов 1977 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Аның 2006 елда төшерелгән «Тукай төшләре» дигән фильмы да профессиональ югарылыкта эшләнгән.

Оператор Станислав Ярошның (режиссер буларак) Тукайның 100 еллыгына тәкъдим иткән «Озари мне душу песней» фильмы музыкаль кинофильмнар арасында яхшы бәя ала һәм шагыйрьгә багышлап, Мәскәүнең колонналы залында үткәрелгән бәйрәм кичәсендә күрсәтелә.

Тукай: «Күктә ни булмас, чиксез күк бит ул», – дип язса, аның милләттәшләре һәм варислары шагыйрьнең үзе турында: «Тукай йолдызлыгы бик киң, чиксез күп төрле, рухи хәзинәләргә бай дөнья ул», – диләр. Аның турындагы фильмнар кайда гына, кем тарафыннан гына төшерелсә дә, ялыктырмас, мавыктыргыч, кызыклы һәм көтеп алынган тансыклар. Кинематографистлардан бары тик Тукайга ышану, язганнарын үзгәртмәү генә сорала. Чөнки Тукай иҗаты үзен-үзе якларлык һәм сакларлык потенцияле иҗат.

***Экраннарда Тукай образы***

... Әгәр исән булса, Тукай – иң көтеп алынган, иң тансык телеведущий булыр иде... Тукай шигырьләрен өстәл тартмасында саклар өчен язмаган. Тукайның иҗаты, язганнары – шагыйрьнең яшәү, көрәшү рәвеше. Ул акча эшләү максатында язмаган, ул язар өчен, яшәр өчен акча эшләгән.

Бүген телевидение, тормышыбызның түренә үтеп, хәкимнәрчә тәхеткә менеп утырды. Ул хәллелек билгесе, йорт җиһазы булудан узып, тормыш-көнкүреш ихтыяҗына, иң көтеп алынган информация чыганагына әверелде. Бүген бик күпләр телевидение «вәсвәсәсе»нә бирелмәскә тырышып караса да, бирелми булдыра алмый. Чөнки телевизион тапшыруның иң гади дигәне дә, язучының гомере буе язганнарының тиражын бер кичтә «бәреп ега». Әгәр китап, күп дигәндә, 10 мең данә басылса, телевидениенең бер тапшыруын бер үк вакытта бер миллион тамашачы карау да аздан санала.

Бусы – үзе бер прогресс. Икенчедән, телевидение ул сәнгатьнең үзгә, яңа бер төре: мөстәкыйльлек мөмкинлекләргә бай, төрле үзенчәлекләргә ия, режиссерларга үз таләпләрен дә куючы төре. Без телевизорга төрле театрларның спектакльләрен «өйгә китереп күрсәтүе» өчен генә дә олы рәхмәтлебез. Ләкин шул изге эшен параллель эшләп, телевидение үзе куйган спектакль яки фильмнарны да юмартларча күп күрсәтте. Татарстанда да. Бездә бу изге эшләрнең башында Гали Хөсәенов дигән режиссер тора. Аның куюында тамашачы Шәйхи Маннурның «Муса»сын, Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры»н, Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»ен күрә. Гали Хөсәенов заманында телевизион спектакльләрне тасмага төшереп алу, аларны саклау һәм кабаттан күрсәтү мөмкинлеге булмау гына кызганыч.

1972 елда, Академия театрыннан режиссер булып, актер Әхтәм Зарипов күчеп килгән чорда инде телевизион фильм-спектакльләрне тасмага төшереп саклау, монтажлау, үзгәртү-төзәтү һәм иң мөһиме, кабаттан күрсәтү мөмкинлекләре туа. Нәтиҗәдә, «Яз сулышы», «Тукай», «Каргышлы балачак» кебек күп серияле фильм-спектакльләр тәкъдим ителә.

...Театр сәхнәсеннән аермалы буларак, телевидение сәхнәсе үзен төрле кысалардан бәйсезрәк хис итә, действие-хәрәкәт мөмкинлекләрен киңәйтергә ирек бирә, персонажларны бер мохиттән икенчесенә тоткарлыксыз күчереп, узганнарга яки киләчәккә китә ала.

Шушы мөмкинлекләрдән һәм үзенчәлекләрдән Татарстан телевидениесе бүген ничек файдалана соң? Ике сүз, бер җөмлә белән – «булдыра алганча» дип әйтә алабыз.

Элек тасмага төшерү һәм монтажлау мөмкинлекләре белән тәкъдим ителгән фильм-спектакльләрнең күбесе проза әсәрләренә

иллюстрация функциясен үтәсә, бүген, фильмны студиядән тыш шартларда да төшерү мөмкинлеге тугач, тамашачы оригиналь сценарийлар буенча милли фильм-спектакльләр көтә.

Кызганычка каршы, иҗади активлык техника прогрессыннан күпкә түбән булу сәбәпле, заманга лаек оригиналь сценарийлар да, инсценировкалану көткән проза әсәрләре дә юк бүгенге арсеналда. Ә сәхнә әсәрләре нигезендә телефильмнар төшерергә... алары берсеннән икенчесе сайрак-сыеграк булулары өстенә, асылда, елыйсы килгән тамашачыны ничек тә көлдерергә дип кенә язылганнар; тетрәндерерлекләре дә, уйландырырлыклары да әлегә язылу көтә.

Әлбәттә, телевидение беренче көннән алып Тукайсыз яшәмәде. Эфирда аның шигырьләре, әкиятләре әледән-әле яңгырап, милләткә кирәклеген, яшәвен сиздереп торды.

Юбилей көннәрендә генә түгел, тансыкка гына да түгел, ә кирәктә ситуация сораганда, вакыт Тукай шигырьләрен таләп иткәндә шагыйрь һәрчак «постында» булды. Тансыкка укыла торган шигырьләр һәм шагыйрьләр була. Ә Тукай һәрчак тансык булды һәм шулай кала да. Шагыйрьнең әсәрләре никадәр күп яңгыраса да, тамашачының эфирда аның үз образы белән очрашасы килү теләге беркайчан да сүрелмәде һәм сүрелмәс тә.

Татарстан телевидениесе («Яңа гасыр»га әверелеп, башка чыкканчы) шагыйрьнең һәр юбилеена я документаль, я нәфис фильм-спектакль әзерләде. Аларның саны дистәгә җыела. Шулар арасында әйтеп узган шагыйрьнең 100 еллыгына өлгертелгән 5 серияле «Тукай» фильмы, 110 еллыгына тәкъдим ителгән 7 серияле «Каргышлы балачак» һәм 2 серияле «Без китәбез, сез каласыз» фильмнары игътибарга лаек.

«Яз сулышы» – И. Нуруллинның Габдулла Тукай турындагы хикәяләре нигезендә куелган беренче телевизион спектакль. Сценарий авторы һәм режиссеры – Әхтәм Зарипов. Тукай ролендә Илдус Әхмәтҗанов, С. Рәмиев – Әсгать Хисмәтов, Сүнчәләй – Рәсим Сәләхов, Бәшири – Хәлим Җәлилов. (Спектакль архивта сакланмаган.) Бу спектакльгә кадәр режиссер Әхтәм Зарипов И. Нуруллинның «Тукай Петербургта» дигән әсәре буенча (1973 ел, апрель) спектакль куя, Тукай ролен академия театры артисты Николай Дунаев башкара. Спектакль тамашачыга ошаса да, автор – И. Нуруллин: «Игътибарны Тукайның авыруына юнәлтеп, аның шигырьләрен, үз идеалларына тугрылыклы максатчыллыгын күрмәгәнсез», – ди. Моңа каршы режиссер: «Димәк, шулай

язылган», – дип аклана. Шушы сөйләшүдән соң И. Нуруллин режиссерга шагыйрь тормышыннан алып язылган үз хикәяләре җыентыгын бирә, «чагыштыр, уйлан», – ди. Бу китап режиссерга Тукай шәхесенә, иҗатына һәм тормышына карашын тамырыннан үзгәртү кирәклегенә ышандыра. Моңа кадәр Тукай иҗатына бәһа биргәндә, аны замана идеологиясенә яраклаштырырга тырышып, социалист ясап, дәһри итәргә тырышып язсалар, И. Нуруллин хикәяләрендә шагыйрь үз халкын сөйгән, күзе күпне күреп, колагы күпне ишетүче, милләтне яклаучы һәм саклаучы, шигырьләрендә реаль чынбарлыкны чагылдыручы әдип буларак тасвирлана.

Ул дәһри дә түгел, дини фанатик та, коммунист та түгел. Ул – шәхес, кеше! Барыннан да элек ул – үз милләтенең улы! Аның дуслары күп булган кебек, дошманнары да бар. Ул сызлана да, моңлана да, елый да, көлә дә торган бер татар баласы. «Яз сулышы» шагыйрьнең тууына 90 ел тулган көннәрдә күрсәтелә.

Шагыйрьнең тууына 100 ел тулуны билгеләп үткәндә телевидение 5 серияле «Тукай» фильм-спектаклен күрсәтте. Тукай ролен Минзәлә театры артисты Фирдәүс Җәмилев башкарды.

Бу киң колачлы 5 исемле фильм-спектакль турында минем үземә язу уңайсыз да, килешмәгән эш тә.

Студиянең эш расписаниесе белән театрның гастроль графикасы туры килү съемкаларны оештыруны катлауландырса да, Фирдәүснең үҗәтлеге җиңде. Бу – яшь артистның Тукайга мәхәббәтен күрсәтсә, тамашачылар яңа Тукай тууга аңа рәхмәтле һәм бәхетле иде.

Студия һәм төрле редакцияләр адресына килгән хатлардан өзекләр китерү урынлы булыр. Хатларның мактаганнарында да, ризасызлык белдергәннәрендә дә Тукаебызга олуг хөрмәт, табыну һәм мәхәббәт хисләре. Өзекләр «ошаттык – ошатмадык» тәртибендә бирелә:

«Тукай бәхетле булды. Аның иҗатын, тормышын өйрәнеп күпме хезмәтләр, әдәби әсәрләр, картиналар язылды. Шул исәптән «Тукай» телевизион спектакле дә бу өлкәдә зур өлеш булды. Аның 100 еллыгына олы бүләк бу... Зур фикерләр, эзләнүләргә таянып эшләнгәнлеге күзгә ташлана. Әмма... бу мин күрергә теләгән Тукай түгел иде...

Без укып, рәсемнәрдә күреп гадәтләнгән Тукай андый түгел. Гомер-гомергә рәхәт, бай тормышта яшәгән бай баласына охшый

төшә. Болар артистның гаебе түгелдер: режиссер нидер карап җиткермәгән. Яшьрәк вакытта кайберәүләр, сүз үтемле булсын өчен, салкын канлы, хәтта тупасрак булып күренергә тырышалар, кычкырып сөйләүне, кеше фикере белән исәпләшмәүне өстенрәк күрәләр. Фирдәүс тә шул алымга таянып эш итә кебек.

Төпле, акыллы кеше бервакытта да тавышын күтәрми, сүзен акрын, әмма саллы итеп әйтә. Андый кеше һәрвакыт гади булып кала белә. Тукай, минемчә, нәкъ шундый булган.

«Яз сулышы»нда Илдус Әхмәтҗановны күреп, мөхтәрәм картларның:

– «Мин Тукай белән исәнләшәмме?» – дип, олы башларын кече итеп күрешүләре турында ишеткәнем бар. Халык таный белә ул. Фирдәүс Җәмилев белән дә шулай олылап сөйләшерләрме соң?

(Әмирхан Еники. Түбән Камадагы «Җидегән чишмә» берләшмәсендәге очрашу чыгышыннан.)

«Үзенең иҗатын шундый катлаулы Тукай образын тудырудан башлаган артист – ул инде киләчәктә үсә торган өметле артист».

(Хисмәтуллина, Казан.)

«Спектакльне тикшергәндә республиканың иң яхшы тәнкыйтьчеләре, сәнгать белгечләре катнашсын иде. Ә Ф. Җәмилев тәнкыйтькә үпкәләмәсен. Ул сәнгатьтә артык кеше түгел, таланты да җитәрлек, әмма аңа үз рольләрен дөрес табарга кирәк».

(Фәсиев, Әлмәт районы, Кәшер авылы.)

«Тукаебыз усал да булган икән бит. Фирдәүс Җәмилев тере шагыйрь образын күреп, мин аңа тулысынча ышандым».

(Гыймранов, Чирмешән районы.)

«Җәмилев шагыйрьнең бик үк билгеле булмаган портретына охшашлыктан чыгып сайланган, күрәсең. Тукайны күбрәк өйрәнгән саен, аның яңа яклары ачыла бара, диләр. Менә шуны күрсәтергә теләп, сәнгать эшлеклеләребез, каш ясыйбыз дип, күз чыгара түгелме?»

(Һидиятуллина, Казан.)

«Бөек шагыйребезнең 100 еллыгын дөньякүләм билгеләп үткәндә, Тукай образын экранлаштыру шатлыклы факт. Һәр кайсы үз урынында, ышандыра. Тукайның жор сүзләре, шигъри җаваплары ятышлы, отышлы. Артистның тышкы кыяфәте шик тудырмый.

Шагыйрь горур, көчле, сагышлы. Мәдхиянең иң олысы сценарист-режиссер Әхтәм Зариповка».

(Роза Козлова, Казан.)

«Телефильм әйбәт, Тукай ышандыра. Тик шунысы бар: ул кеше алдында шигырьләрен сөйләмәгән диләр бит. Гомерендә бер мәртәбә «Сәйяр»гә кушылып шигырь укуын иң зур хаталарыннан берсе итеп санаган».

(Туктаров, Куркачи.)

Бу хатлар (саклнганы 63) укучыларыбыз күңелендә Тукайның образы матур, гади һәм олы җанлы булып саклануына шаһитдәлилләр. Күңелләрдәге чиста образга ят, ятышмый торган сыйфатларның гәүдәләнүе ризасызлык уята икән – болар барысы да шагыйребезгә мәхәббәттән.

Татарстан телевидениесе 1996 елда шагыйрьнең тууына 110 ел тулу көннәрендә күрсәткән 7 сериядән торган «Каргышлы балачак» телефильмы турында «Мәдәни җомга»да басылып чыккан «Шагыйрьнең балачагына сәяхәттән соң» мәкаләсенә өстәп әйтер сүз юк.

Телефильмнардан «Без китәбез – сез каласыз» (Тукай ролендә Фәрит Бикчәнтәев) турында үз вакытында республика газеталарында хуплаган мәкаләләр чыкты. Бу ике телефильм әле «репертуарда» булганлыктан, экраннарда Тукай образы дигән язмабызны шушы урында өзү дөрес булыр. Чөнки шагыйрь образы турында сәнгатькәрләребезнең эзләнүләре дәвам итә.

*Әхтәм Зарипов,*
*актер, режиссер,*
*ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе*

## К ВОПРОСУ О ФОРТЕПИАННЫХ ПЕРЕЛОЖЕНИЯХ МУЗЫКИ Ф. ЯРУЛЛИНА К БАЛЕТУ «ШУРАЛЕ»

Балет Фарида Яруллина «Шурале» – одно из выдающихся художественных воплощений бессмертной поэзии Габдуллы Тукая в музыке. Озаренное ярким талантом и неиссякаемым обаянием личности композитора, глубоко национальное по духу произведение стало достоянием мировой музыкальной культуры. Чудесная музыка Ф. Яруллина – живой источник проникновенного лиризма

и жизнеутверждающей силы, вновь и вновь привлекает внимание профессионалов и вдохновляет на создание различных творческих интерпретаций. Оркестровые сюиты, а также многочисленные обработки музыки балета для различных музыкальных инструментов являются и убедительным подтверждением непреходящего значения творчества нашего выдающегося соотечественника, и замечательной возможностью его дальнейшего распространения.

Одна из особенностей фортепианных переложений музыки «Шурале» непосредственно связана с историей создания балета. Речь идет о вариативности их базовых источников.

Известно, что премьера спектакля готовилась к открытию Декады татарского искусства и литературы в Москве в августе 1941 г. Для его постановки был приглашен балетмейстер Большого театра Леонид Якобсон, который подверг первоначальное либретто Ахмеда Файзи существенному пересмотру. С учетом внесенных изменений Ф. Яруллин к июню 1941 г. завершает клавир[1] балета. Переписанный еще при жизни композитора с черновых рукописей и содержащий пометки, сделанные рукой автора, он хранился в личном архиве Н.Д. Юлтыевой[2].

Начавшаяся война не только обрушила все творческие планы, она оборвала жизнь ушедшего на фронт композитора. Премьера балета состоялась в марте 1945г. в новой редакции Л.А. Жукова и Г.Х. Тагирова, содержащей отдельные купюры (сокращения) и иной порядок следования номеров. Инструментовка была поручена знатоку оркестровки, преподавателю института им. Гнесиных Фабиану Витачеку. На базе материалов первой постановки балета в 1951 году был составлен и переписан второй вариант авторского клавира[3].

Таким образом, два авторских клавира, партитура Ф. Витачека и сохранившиеся черновые рукописи Ф. Яруллина из архи-

---

[1] *Клавир* – фортепианное изложение музыкально-сценического произведения.

[2] Юлтыева Нинель Даутовны – артистка балета, балетмейстер, Народная артистка РСФСР, РТ. С 1967 года занималась постановкой балета Ф. Яруллина «Шурале», выступила с инициативой восстановления его первоначальной, довоенной версии.

[3] Второй вариант авторского клавира балета «Шурале» хранится в библиотеке Казанской государственной консерватории, а сделанная с него в 1971 г. копия – в библиотеке Татарской государственной филармонии им. Г. Тукая.

ва Г.Х. Тагирова[1] стали основой для опубликованного Татарским книжным издательством в 1987 году клавира к тому времени уже прославленного балета.

Огромная заслуга в том, что подлинные тексты композитора стали достоянием широкой общественности, принадлежит композитору Л. Батыр-Булгари (Л. Батыркаевой). По ее словам, она «как редактор, на долю которого выпала большая честь работать с авторскими оригиналами и как бы войти в творческую лабораторию талантливого художника,...имела возможность в полной мере и по достоинству оценить талантливость музыки Ф. Яруллина именно с первых черновых набросков» [1]. При подготовке издания ею была проведена кропотливая работа по реставрации черновых рукописей, «реанимированы» не вошедшие в первый клавир фрагменты балета, сверены все источники для устранения неточностей, внесенных рукой переписчика, скрупулезно восстановлены опущенные элементы фактуры, расставлены образные сценические пометки автора и балетмейстера... Словом, сделано все возможное для максимального воссоздания первозданного варианта авторского текста.

Однако шестнадцатью годами раньше, в 1971 г., центральным издательством «Музыка» был выпущен клавир «Шурале» под редакцией В. Власова и В. Фере, основанный на постановке Ленинградского академического театра оперы и балета им. С.М. Кирова (ныне Мариинский) 1950 года, а также на сценической версии Государственного академического Большого театра Союза ССР. В соответствии с новой концепцией балета композиторами В. Власовым и В. Фере были обработаны и дописаны отдельные номера, заново инструментована партитура. В предисловии к клавиру авторы новой редакции отмечали, что работали над текстом, «движимые чувством глубокого уважения к памяти талантливого композитора, ...ощущая серьезную ответственность перед татарским музыкальным искусством» [2]. Данная постановка, с триумфом обойдя сцены ведущих мировых театров, получила широкое признание и увековечила имя Ф. Яруллина, а клавир 1971 года на то время стал первым изданием, обеспечившим свободный доступ к изучению музыки выдающегося балета.

---

[1] Тагиров Гай Хаджиевич – артист балета, балетмейстер, Народный артист ТАССР. Первый постановщик балета Ф. Яруллина «Шурале».

Как видим, в силу исторических причин основой для различного рода инструментальных переложений послужили не только оригинальные авторские тексты, но и их отредактированная версия, возникшая в связи с пересмотром сценического решения балета.

В различные годы к творческому переосмыслению музыки Ф. Яруллина обращались известные пианисты: Ф. Хасанова (1984), Э. Бурнашева (1987), Р. Урасин (2003), Р. Шакиров (2005), З. Муштари (2007). Их обработки для фортепиано и фортепианных ансамблей, отразившие трепетное, исключительно бережное, вдумчивое отношение к авторскому тексту, вместе с тем запечатлели разнообразие подходов к его интерпретации, обусловленных в каждом конкретном случае сугубо индивидуализированной художественно-исполнительской концепцией.

Так пьесы «Вальс птиц» и «Танец Огненной ведьмы и Шайтан» в обработке Э. Бурнашевой являют собой классический пример четырехручных переложений. Уплотнение фортепианной фактуры, четкое, акустически оправданное распределение музыкального материала между партиями двух роялей позволяет добиться более эффектного, приближенного к оркестровому, объемного звучания. Слитность и слаженность игры в ансамбле как особом виде творческого сосуществования предполагает наличие соответствующих исполнительских навыков, чувства включенности в целостное звуковое пространство музыкального произведения, единства в понимании и техническом воплощении его идейно-художественного замысла.

Яркое преломление балетных номеров «Шурале просыпается», «Баллада Сююмбике», «Пляска Огненной ведьмы и Шайтана» с позиций виртуозной трактовки фортепиано мы видим в обработках Р. Урасина. Блистательно выполненные в лучших традициях мировой транскрипционной литературы (Ф. Лист, С. Рахманинов, М. Плетнев), они раскрывают богатейший потенциал выразительных возможностей фортепианного звучания. Техническое усложнение фактуры (гармоническая и мелодическая фигурация, различные приемы крупной техники, вставные каденции и др.) (пр. 1а, 1б) в пьесах не носит самодовлеющего, чужеродного характера, отторгающего ее от самой сути музыкального первоисточника. Напротив, в таком богатом, изысканном обрамлении еще ярче высвечивается красота и величие яруллинских творений.

Пр. 1а




Пр.1б




Если за основу обработок, описанных выше, были взяты целостные самостоятельные балетные номера, то в других работах

мы наблюдает примеры создания новых, отсутствующих в оригинале, музыкальных форм, образованных в результате объединения различных тем и фрагментов балета.

Так в фортепианной сюите, составленной Ф. Хасановой[1], помимо деталей исполнительской редакции (сопровождение нотного текста указаниями на характер звукоизвлечения, фразировки, артикуляции, педализации и.т.д.), можно выявить и отдельные приемы структурирования музыкального материала. Один из них – прием моделирования целостного музыкально-художественного образа. К примеру, если основной раздел пьесы «Шурале», открывающей цикл, целиком соответствует первоисточнику, то во вступлении вместе с оригинальной витиеватой темой просыпающегося лешего, проводятся еще два ее варианта из других эпизодов балета, что в совокупности дает разностороннюю, целостную музыкальную характеристику грозного владыки леса (пр. 2а, 2б, 2в).

Пр. 2а



Пр. 2б




[1] Сюита состоит из 6 частей: 1. Шурале; 2.Дуэт Сююмбике и Болтыра; 3. Пляска Огненной ведьмы и Шайтана; 4. Детский танец; 5. Сююмбике; 6. Сцена. Пьесы 3, 4, 5 не отступают от оригинала

Пр. 2в




Тот же метод соединения родственных по смыслу тем (тема отчаяния Сююмбике из Адажио с нечистью из 1 акта и начальная фраза драматического Дуэта Былтыра и Сююмбике из 2 акта балета (пр. 3)) используется в пьесе «Сцена» для экспрессивного насыщения кульминации крайних разделов.

Путем смыслового объединения, не только тем и мотивов, но и целых эпизодов по принципу родства либо контраста в сюите моделируются пьесы «Дуэт Сююмбике и Былтыра» и «Сцена».

Первая из них имеет стройную трехчастную форму (с кодой), построенную на материале лирических дуэтов героев:

А (1 раздел) – В (средний раздел) – А (реприза) – В$^{1}$ (кода), где

А – тема Заключительного адажио,

В – Дуэт после схватки Былтыра с Шурале из 1акта.

Пр. 3



Так же трехчастную форму, но с контрастной серединой имеет драматургически более сложная заключительная пьеса сюиты «Сцена». В ее основу легли полное смятения «Адажио Сююмбике с нечистью» (пр. 3) и «Сцена возвращения в деревню» из 2 акта, где звучит печальная, простодушная тема, имитирующая наигрыш курая. Изумительная вариация на тему, выписанная в конце среднего эпизода и стилизованная в духе импровизационных, богато орнаментированных народных напевов, усиливает национальный колорит и искренность музыкального высказывания (пр. 4).

Пр. 4




Цементирует форму лейттема Шурале. Целиком она проводится во вступлении «Сцены», отдельными репликами напоминает о себе в связующих эпизодах. На базе ее основной интонации построен и низвергающийся, неистовой силы заключительный пассаж, таким образом формируя композиционную арку не только финального номера, но и цикла в целом (пр. 5).

Пр. 5



Своеобразием композиционных решений отличается и Сюита из балета «Шурале» известного пианиста из Санкт-Петербурга Р.Шакирова. Она, по признанию самого исполнителя, создана по настоятельной рекомендации Мирсаида Яруллина (брата Ф. Яруллина) и составляет неотъемлемую часть программ его концертных выступлений в стране и за рубежом. Цикл, состоящий из исполняемых без перерыва (*attacca*) 4 частей,( «Вступление», «Шествие нечисти: Марш, Русалки, Карлики, Марш», «Шурале», «Дуэт Былтыра и Сююмбике»), представляет собой своеобразную галерею музыкальных образов и имеет сквозную драматургию, соответствующую сюжетной фабуле балета. Тексты лишь за небольшим исключением (имеются некоторые купюры в «Шествии нечисти» из 3 акта, небольшие фактурные преобразования), не отступают от оригинала.

Особый интерес в сюите представляет оригинальная трактовка образа Шурале. В одном из своих интервью Р. Шакиров приводит следующие доводы такого подхода: «Фарид Яруллин внес свое понимание в образ обманутого лесного жителя, которое я постарался передать и в своей фортепианной сюите. Шурале со своими болями и страданиями по неразделенной любви – ...единственный отрицательный персонаж в татарском эпосе, ставший главным героем произведения» [3].

Для характеристики отвергнутого лешего взяты 2 фрагмента балета: тема бесноватого хохота из «Торжества Шурале» (пр. 2в) во вступлении и «Вставная вариация Шурале из 3 акта» в основном разделе. Эта музыка лишена гротесковости и угловатости причудливого танца злобного фантастического существа, она несет черты чувственного, даже где-то элегантного вальса (пр. 6а, 6б).

Пр. 6а



Пр. 6б




Элементами сотворчества отмечена и работа З. Муштари, определяемая ею как свободная обработка для двух фортепиано. Естественно вплетены в канву музыкального повествования сочиненные ею контрапункты, связующий и разработочный материал (пр. 7).

Пр. 7




В основу драматургического развития «Фантазии на темы из балета “Шурале”» З. Муштари положен принцип контраста, прием сопоставления противоборствующих сторон: это – силы тьмы (Шурале и прочая лесная нечисть), с одной стороны, с другой – Сююмбике и птицы – олицетворение красоты мироздания. В пьесе разрабатывается материал 1 акта балета. Компоновка эпизодов, тематическое развитие, все имеет смысловой подтекст – неотвратимость столкновения с проявлениями зла и насилия. Так, например, образ Сююмбике-птицы дан во враждебном окружении (размещен между разделами «Шурале» и «Пляска Огненной ведьмы и Шайтана»), будто находится в самом логове лесных чудищ.

А в кульминационной точке развития ее темы властно вторгается лейтмотив Шурале как предвестник беды (пр. 8).

Пр. 8




Своеобразное обобщение дается и в коде произведения: нежно и трогательно звучит недопетая, будто обрывающаяся «на полуслове» мелодия из «Баллады Сююмбике», следом – жесткое, категоричное проведение тем Огненной ведьмы, Шайтана и Шурале. Красота беззащитна перед натиском грубой силы.

Фортепианные обработки на темы «Шурале» – лишь небольшая толика произведений, созданных по мотивам поэзии Тукая и музыкального шедевра Ф. Яруллина. В них выдающиеся творения национальной культуры обретают новое звучание и благодарную память потомков.

**Литература**

1. Яруллин Ф. «Шурале». Балет в 3 действиях. Либретто А. Файзи и Л. Якобсона. Клавир. Казань: Татар. кн. изд-во, 1987.

2. Яруллин Ф. «Шурале». Балет. Редакция, обработка и инструментовка В. Власова и В. Фере. Либретто А.Файзи и Л.Якобсона по одноименной поэме Г. Тукая. Переложение для фортепиано. М.: Музыка, 1971.

3. http://muzkarta.info/novost/rinat-shakirov-v-bryussele

*Аниса Абдуллина,*
*кандидат педагогических наук, заслуженный деятель искусств РТ,*
*старший научный сротрудник Центра письменного и музыкального наследия*
*Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

ЭЧТӘЛЕК

Кереш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

***Һаман мин яктырырмын...***

Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Бәйрәм бүген . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Китап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Милли моңлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Татар яшьләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Тукай мирасын өйрәнгәндә... . . . . . . . . . . . . . . 22
Табигать һәм инсан . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Казан шәһәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Пожар вакытында кызгану . . . . . . . . . . . . . . 25
Дүнә вә Мишә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Тукаев сүзләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Габдулла Тукай хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . 47

***Фитрәттә гали булган ул...***

Габдулла Тукай фондында саклана торган материалларның тасвирламасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Казанда Габдулла Тукай әдәби музее . . . . . . . . . . . .105
Габдулла Тукай әдәби-мемориаль музей комплексы . . . . .109
Уральскида Габдулла Тукай музее . . . . . . . . . . . .115
Памятники Тукаю . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .117

***Әгәр мине милләт, илтифат итеп, искә алса...***

Совет чорында язылса да... . . . . . . . . . . . . . . . 120
Хат [Г. Кәлтиевнең Ә. Фәйзигә язган хаты] . . . . . . . . 122
Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем [М. Төхфәтуллин. ] . . . . . . . . . . . . . 134

Г. Тукайның бер фоторәсеме тарихына карата . . . . . . . . 142
Габделкаюм Мостакаевның «Тукай турында исемдә калганнар»ыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Г. Мостакаевның үзендә сакланган Г. Тукай фоторәсеме тарихы турында «Аңлатма»сы . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Вафа Бәхтияров истәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Шакир Мөхәммәдъяров истәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Ибраһим Бикколов истәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Воспоминания о жизни Г. Тукая в Астрахани . . . . . . . . . 162
Шакир Мостаев истәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
«Ерак Шәрык» журналында дөнья күргән кайбер язмалар . . 173
Тукай кичәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Габдулла әфәнде Тукай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177

***Шигырьләрдән килер миңа кирәк җылы***

*Фәйзи М.* Тукай кабере янында . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
*Габиди И.* Мәрхүм шагыйрь Тукаев рухына . . . . . . . . . . 182
*Айманов Я.* Хөрмәтле шагыйремез Тукаевка . . . . . . . . . . 183
*Җәлал М.* Инна лиллаһи вә иннә иләйһи раҗигун: Мәрхүм Тукайга матәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
*Хамадов К.* Габдулла Тукай хәзрәтләре өчен . . . . . . . . . 185
*Агиев Ф.* Шагыйрьнең соңгы аһлары . . . . . . . . . . . . . . 186
*Сәмигуллин Г.* 2 нче апрель тәәссефе . . . . . . . . . . . . . . 187
*Нияз Г.* Габдулла әфәнде Тукаев җәнапләренең вафат хәбәрен ишеткән чакта миндәге әрнелү . . . . . . . . . . 188
*Сәгыйди Ә.* Шагыйрь Габдулла Тукаев дарелбакайа рихләт итү мөнәсәбәтилә 4 нче апрель киченең матәме . . . . . 189
*Акчурин Г.* Мәрхүм иптәшем шагыйрь Габдулла Тукаев хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
*Юнусова Г., Барышева Ф.* Тәгъзия: Мәрхүм Габдулла әфәнде Тукаевка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191
*Киләчи Б.* Мәрхүм остаз шагыйрь Г. Тукаевка ядкәр . . . . 192
*Җәлал В.* Тукаев вафатилә мосыйбәт . . . . . . . . . . . . . . 193
*Җәлал В.* Тукайга дога . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
*Еникеев Г.* Нинди көн бу? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
*Ибраһимия Р.* Китте шагыйрь! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196
*Әхмәтшаһ угылы М.* Хатирә (Габдулла Тукаевка багышлыйм) . 198

**Үзем үлсәм дә, гаҗиз исемем үлмәсен, югалмасын...**

*Рәмиев З., Шәйхелисламов З.* Китаби басмалар . . . . . . . . 200
*Вәлиева М.* Г. Тукай теленең өйрәнелү торышы . . . . . . . 205
*Абдуллина Д.* Тоталитар дәвер (1917–1956) әдәби тәнкыйте Г. Тукайның дини карашлары хакында . . . . . . . . . . 220
*Рахман Р.* Влюбленный по уши герой… Тукая . . . . . . . . . 232
*Алиева Ә.* Ерак Себердә Тукай иҗаты . . . . . . . . . . . . . 244
*Әхмәтҗанов М.* Фотограф Кыям карый Зөлфокаров турында 250
*Зарипов Ә.* Кинематография, телевидение һәм Тукай . . . . . 252
*Абдуллина А.* К вопросу о фортепианных переложениях музыки Ф. Яруллина к балету «Шурале» . . . . . . . . . . 262

**ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ**
**поиски и открытия**

Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А. Булатова*

В оформлении титулов использованы цитаты из стихоторений Г. Тукая:
«Яңгыр илә Кояш», «Милләткә», «Өмид», «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре», «Шагыйрь»

Подписано в печать: 14.04.2016 г.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная, печать офсетная
Усл.-печ. л. 16,1. Уч-изд. л. 10,8. Тираж 300. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. Лобачевского, 2/31